**Министерство образования и науки РФ**

**ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет»**

**Филологии и межкультурной коммуникации**

**отделение татарской филологии и межкультурной коммуникации им. Г.Тукая**

**Кафедра татарской литературы и методики преподаванияи**

[illegible]

[illegible]

[illegible]

[illegible]

## Конспект лекций

**Казань– 2014**

**Направление подготовки:**032700 «Филология» (профиль подготовки «Прикладная филология (Татарский язык и литература, английский язык)» бакалавр», «Отечественная филология (Татарский язык и литература)» бакалавр»)

**Учебный план:** «Филология»(татарский язык и литература) (очное, 2011), «Филология»(татарский язык и литература, английский язык) (очное, 2011).

**Дисциплина:** «Современная татарская литература», (4 курс, очное).

**Количество часов:** количество часов – **72**, (в том числе лекции – **22**, практические занятия – **22,** самостоятельная работа – **28)**, форма контроля – экзамен.

**Аннотация:** главной целью курса является ознакомление студентов современным литературным процессом в его взаимосвязи с развитием культуры, спецификой интерпретации литературного текста. Задачи курса предусматривают прежде всего погружение в теоретические проблемы курса и особенности творчества современных писателей, поэтов и драматургов. Наибольшее внимание уделяется выделению художественного значения литературного произведения в связи с ситуацией в общественной жизни и культурой эпохи, определению художественного своеобразие произведений и творчества писателей в целом.

**Темы:** 1. Основные тенденции развития современной татарской поэзии. 2. Творчество Р.Хариса в контексте современной татарской поэзии. 3. Творчество З.Мансурова в контексте современной татарской поэзии. 4. Творчество Р.Зайдуллы в контексте современной татарской поэзии. 5. Основные тенденции развития современной татарской драматургии. 6. Основные тенденции развития современной татарской прозы. 7.Постмодернизм в современной татарской прозе (на примере произведений М.Кабирова). 8. Интеллектуальная тенденция в современной татарской прозе. 9. Концептуализм в современной татарской прозе.10.Неомифологизм в современной татарской прозе. 11. Жанр романа в современной татарской прозе.

**Ключевые слова:**современная литература, литературный процесс, стилевые тенденции, литературные направления и течения, творчество.

**Дата начала использования:** 1 сентября 2014 г.

**Авторы:Юсупова Нурфия Марсовна**, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, email: Faikovich@mail.ru, Nurfija.Jusupova@ kpfu.ru; **Гайнуллина Гульфия Расилевна**, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания КФУ, тел.:(843) 2-21-33-51, email: gulfiarasilevna@mail.ru, Gulfia.Gaynyllina@kpfu.ru

**URL электронного курса в MOODLE**: http://tulpar.kpfu.ru/course/view.php?id=1871

**Доступность:** записанные на курс пользователи

**Язык интерфейса:** татарский

**Эчтәлек**

Тема 1. Хәзерге татар шигъриятенең үсеш-үзгәреш юллары.......................4

Тема 2. Р.Харис иҗаты (1943).................................................................16

Тема 3. З.Мансуров иҗаты (1949) ..........................................................23

Тема 4. Р.Зәйдулла иҗаты (1962)............................................................33

Тема 5. Хәзерге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре......................................................................................................38

Тема 6. Хәзерге татар прозасы: стиль тенденцияләре, жанрлар төрлелеге: реалистик, романтик юнәлешләр, интеллектуаль тенденция, экзистенциаль фикерләү төре, неомифологизм........................................................................52

Тема 7. М.Кәбиров әсәрләрендә постмодернистик алымнар.................. 55

Тема 8. Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция. (М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте)..................................................67

Тема 9. Хәзерге татар прозасында концептуализм күренеше (Г.Гыйльманның “Оча торган кешеләр” әсәре мисалында)................................68

Тема 10. Хәзерге татар прозасында мифологик катламның вазифасы. (Н.Гыймадинова повестьлары) ........................................................................77

Тема 11. XXI йөз башы татар прозасында реалистик роман жанры. (З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романында экзистенциаль мотив).................... 83

Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар.................................................................................92

Терминологик сүзлекчә.................................................................................96

## Тема 1. Хәзерге татар шигъриятенең үсеш-үзгәреш юллары

**Лекция 1**

**Аннотация.** Хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш юллары турында мәгълүмат бирелә, төп үсештенденцияләре ачыклана. Хәзерге татар шигъриятендә реализм, романтизм иҗат юнәлешләре белән янәшәдә модерн агымнар, стиль тенденцияләре ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:** поэзия, стиль тенденциясе, реализм, романтизм, интеллектуаль тенденция.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Хәзерге татар поэзиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре, алшартлары.
2. Хәзерге татар поэзиясендә реалистик юнәлеш.
3. Хәзерге татар поэзиясендә романтик юнәлеш.
4. Соңгы еллар татар поэзиясендә интеллектуаль тенденция.
5. Соңгы еллар татар поэзиясендә модерн алымнар.

XX-XXI гасыр чикләре татар поэзиясендәге үсеш-үзгәреш, бер яктан, 1990 нчы еллардагы рухи һәм милли яңарышның, икенче яктан, 1960-80 нче еллардагы шигъри күтәрелешнең матур нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Сиксәненче елларның икенче яртысыннан милли мираска мөнәсәбәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә халыкның үз үткәне, мәдәни байлыгы белән кызыксынуы арту, моңа кадәр күләгәдә калып, күренми яткан әдәби катламнарның ачылуы, татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңарыш шигъриятtә яңа сыйфатларның алга чыгуына юл ача. Туксанынчы еллардагы фикер төрлелеге,

азатлык, хөррият җилләре һәм төрлечә карашлар сыешуы шигъриятьтә күренешләрне яңачарак бәяләргә, сурәтләргә, матурлыкны үзгә эчтәлектә, калыпта яктыртырга мөмкинлек бирә. Болар, сүз сәнгатенең башка төрләре кебек үк, поэзиянең дә бөтен яссылыкларда – эчтәлек һәм форма ягыннан – эзләнүләр юлына керүенә этәргеч була. Яңарыш традицияләрне дәвам итеп үсү-үзгәрү, тема-проблематик яктан төрлеләнү, яңа сукмаклар эзләү, иҗади тәҗрибәләр ясап карау, фәлсәфи яктан тирәнәю, иҗтимагый тормыштагы күренешләрне дә кешелек, яшәеш кыйммәтләренә бәйләнештә ачарга омтылу белән билгеләнә. Әлеге дәвер шагыйрьләрнең иҗат принципларын, кыйммәтләрне яңадан тагын бер кат күздән кичерүе ягыннан да үзенчәлекле.

Нәкъ шушы ике гасыр чигендә XXI гасыр башы татар шигъриятендә урын алачак, сүз сәнгатен үсеш-үзгәрешкә китерәчәк стиль тенденцияләре аермачык билгеләнеп җитә: романтик, лирик-эмоциональ башлангычның дәвам ителүе; милләт тормышына, җәмгыятькә бәя бирүгә йөз тоткан тәнкыйди башлангычның көчәюе; җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен әдәби материалда чишәргә омтылган интеллектуаль тенденциянең үсүе; модернистик эзләнүләрнең алга чыгуы. Бу сыйфат-хасиятләр хәзерге чор татар поэзиясендә, реаль чынбарлыкны бәяләү белән генә чикләнмичә, кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгарган, кешене олы кыйммәт итеп күтәргән яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган яңа әдәби модельнең төзелүенә китерә. Шуның нәтиҗәсендә татар шигърияте чын мәгънәсендә милли рухлы, укыган саен яңа мәгънә, үзгә яклары белән ачыла бара торган лирик-эмоциональ, үзенчәлекле, бер үк вакытта модерн алымнарны да чит итмәгән, алымнар синтезына нигезләнгән шигъри әсәрләрне мәйданга чыгара.

Чор шигъриятендә реализмның әйдәп баручы буларак үз позициясен саклап калуы күзәтелә. Мондый шигъри әсәрләр, традицияләрне дәвам итеп, иҗтимагый тормышка, җәмгыятьтәге вазгыятькә, милләт тормышына аерым игътибар бирә, заманга, милли сәясәткә хас проблемаларны калкытып куя.

Реалистик юнәлешкә мөнәсәбәтле шигырьләрнең бер бәйләмен татарның киләчәге, милләт язмышы, үткәне өчен сызлану берләштерә, традицион төстә

милли эчтәлек алга чыга. Шуңа бәйле төстә күп шигырьләр гражданлык лирикасына карый.

Мондый әсәрләрдә татар халкының ачы язмышы (лирик герой язмышы еш кына милләт язмышына берегеп китә), татар халкы кичергән фаҗигаләр яки җәмгыятьтәге хәл-халәт хиснең төп сәбәбенә әверелә, шәхес-система, лирик герой – җәмгыять каршылыгы, иҗтимагый детерминация саклана, кешенең үз-үзен танып-белү мәсьәләсе төп проблема буларак күтәрелә, әсәрләрнең үзәгенә “без нигә мондый, тормыштагы гаделсезлеккә ничек җавап биреп була?” кебек сораулар куела. Н.Әхмәдиевнең “Хатирәләр үлми, искерми”, Г.Әхтәмованың “Изгелектә безнең бар ният”, Р.Идиятуллинның “Энҗе сүз эңгердә балкый”, Р.Шаһиеваның “Ана теле – гүзәллек”, И.Гыйләҗевның “Җаным ирек, хөрлек тели”, Ч.Мусинның “Дөнья иркен – җанда кысанлык” кебек шигырь бәйләмнәрендә, М.Кәримовның “Ватан”, “Рәшәткәләр”, С.Гәрәеваның “Без – татарлар”, Ә.Мәхмүдовның “Китәбез...”, Ф.Тархpraнованың “Нигез”, “Бетеп бара татар авылы” һ.б. шигырьләрендә җәмгыятьтәге, милләт тормышындагы вакыйга-хәлләр нәтиҗәсендә туган хис-кичереш аша авторларның җәмгыятьтәге тәртипләргә яки милли мәсьәләләргә мөнәсәбәте, ягъни гражданлык позициясе ачыла. Мәсәлән, Н.Әхмәдиевның “Хатирәләр үлми, искерми” шигырьләр бәйләме Г.Тукайның “Кыйтга” шигыреннән алынган юллар белән башланып китә. Әлеге эпиграф шигырь структурасында метафора вазифасын үтәп, бүгенге вазгыятьне бәяләүгә юнәлтелә, Такташ иҗатыннан үстерелеп килгән традицияне дәвам итеп, җил, давыл символик образлары да шул ук эчтәлектә шигырь тукымасында урын ала. Татарларның буйсынып яшәргә мәҗбүр ителүе, татар халкы кичергән фаҗигаләр лирик герой күңелендә сагыш хисен уята.

Әлеге шигырь бәйләмендә урын алган “Сагыну” шигыре гомуми фонда лирик геройның татарның язмышына бәйле сызланудан юануы кебек кабул ителә.

М.Кәримовның “Рәшәткәләр” шигырендә рәшәткәләр ачкыч сүзе уйнатылып, “рәшәткәле язмыш” варианты алга чыга. Төрле эчтәлектәге

рәшәткәләр арасында бәргәләнгән йөрәк образында бәйсез, хөр булып яшәргә хыялланган кеше һәм татар халкы гомумиләштерелә, рәшәткәләр яшәп килгән вазгытьне символлаштыра. Шундый халәттәге тормыш-яшәеш, үз чиратында, лирик герой күңелендәге сызлануга сәбәп төсен ала.

Г.Бәйрәмованың "Ил кадерен белер – илсез калган" шигырендә татар авылларының юкка чыга баруы милли фаҗиганең бер сәбәбе төсен ала, шул юлда авыл татар милләтен саклаучы югарылыгына күтәрелә. Шулар аша автор фикере төгәлләштерелә: кешене үткәндәге якты хатирәләре яшәтә, милләтне дә авыл саклап калырга сәләтле.

Х.Мөдәррисованың "Тамчы суга бу җәй дөнья мохтаҗ..." шигыре реалистик яссылыкта кеше фәлсәфәсен тәкъдим итә. Шигырь структурасында тамчы су – кеше яшәеше өчен кирәкле рухи азык, иман, күңел байлыгы кебек кабул ителә. Шуңа бәйләп, автор кешенең иманга килү аша гына сакланып кала алу мөмкинлеген билгели. Яшь шагыйрә Г.Корбанованың "Офык читләрендә ышык таулар" шигырендә милләтләр бердәмлеге сакланып калу юлы кебек тәкъдим ителә.

Аерым бер шигырьләрдә милли тема танылган шәхесләр образларына мөнәсәбәтле формалаша. Бу алым татар шигърияте өчен шулай ук традицион. Мәсәлән, Л.Шәехның "Без сайлаган юллар хата түгел" шигырьләр бәйләмендәге "Спартанларның батырлыгын..." шигырендә Спартанларның батырлыгы / Җәлилләрнең батырлыгы янәшәлеге укучыны "теләсә кайсы халыкны каһарманнары саклап кала" дигән фикерне аңлауга китерә. Шушы ук мотив Л.Шәехның "Ике Салих", Р.Низаминың "Хөрмәтле Шамил ядкяре" кебек шигырьләрендә дә дәвам итә, үстерелә, иҗат кешеләре халыкның рухи яшәешен тергезүчеләр, телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклаучылар югарылыгына күтәрелә, традицион төстә аларга хөрмәт милләтне бәяләүче бизмән кебек тәкъдим ителә. Соңгысында бу фикер сәнгати алым – Г.Тукайның "Хөрмәтле Хөсәен ядкяре" шигыре белән ассоциация – аша тирәнәйтелә. Шундый ук мотивлар М.Мирзаның "Борынгыдан килгән Идел-Йортта...",

мәхәббәт лирикасы остасы буларак танылган шагыйрә Ф.Тархpraнованың “Туфан” кебек шигырьләрендә дә урын ала.

С.Әхмәтҗанованың “Арча капкасы” шигырьләр бәйләмендә үзгә күренеш – ерак тарих аша бүгенгене бәяләү сыйфаты – алга чыга. Милләт азатлыгы, татар телен үстерү, гадәт-традицияләрне саклап калу мәсьәләсенә мөнәсәбәттә тарихи-мәдәни хәтерне торгызу мотивы калка, милли хәтер милләт сакчысы кебек тәкъдим ителә. Гомуми планда караганда бу юнәлештәге шигырьләрдә публицистлык сыйфатының көчле булуы күзгә ташлана, хәтта ул бер стиль тенденциясе буларак билгеләнә ала.

Шуның белән янәшәдә аерым бер шигырьләрдә җәмгыятькә бәя, милли хәл-халәткә мөнәсәбәт метафора-символлар, эзоп теле аша ачыла. Шунысы үзенчәлекле: алар хәзерге татар поэзиясендә кабат эзоп теле алымының актуальләшүен, лирик герой кичерешләрен яки автор позициясен җиткерү барышында алга чыгуын күрсәтә. Гомумәдәби фонда “яшерен эчтәлек” алымның кабат яңаруы шигъриятнең “үз” традицияләренә әйләнеп кайтуы буларак кабул ителә, чөнки милли әдәбият өчен икенчел эчтәлек тудыру алымы традицион.

Р.Сәләховның “Таш өстендә үскән куаклар” шигыре шушы яктан кызыклы. Бер караганда шигырьдә идеологик укыла торган яки идеологик эчтәлеккә ишарә ясаган образлар юк. Әмма шигырь тукымасында кабатлана килгән “таш өстендә үскән куак” образы, кабатлау алымы аша, символик югарылыкка күтәрелә. Шуңа мөнәсәбәттә куак / кеше, таш / иҗтимагый вазгыять янәшәлекләре пәйда була һәм яшерен эчтәлекне ачарга ярдәм итә: горур калганда, яшәүгә өметне җуймаганда алга таба яшәргә көч табып була! Шушы ук фикер символик эчтәлек аша милләт язмышына бәйле дә аңлашыла ала. Шундый ук мотив Р.Низаминың “Мин китәм...” шигырендә дә урын ала. Р.Сәләховның “Яшел күзле яз” шигыре дә образның мәгънәләрен уйнату аша мәгънә тирәнлегенә йөз тотып язылган. Яз, традицион эчтәлеген дәвам итеп, якты киләчәк мәгънәсендә урын ала. Шушы ук шигырь кысаларында аның идеологик эчтәлеген (җәмгыятьнең, илнең киләчәге), фәлсәфи мәгънәсен

(кешелекнең язы), лирик-психологик эчтәлеген (яшьлек) аңлау мөмкинлекләре дә калдырыла.

Ф.Гыйззәтуллинаның “Яну дәверләрендә” роман-поэмасы бу елның гына түгел, гомумән, татар поэзиясенең уңышы буларак бәяләнүгә лаек. Гомумән, соңгы елларда мәйданга чыккан татар поэмаларының бер хасияте булып төрле катламнарның синтезына омтылыш тора. Ул синтез еш кына дини-мифологик образлар, гыйбарә-әйтелмәләр аша уздырылган фәлсәфи уйланулар: кеше һәм гомер, яшәү һәм үлем, вакыт агышы, кеше гомеренең бәясе, яшәү мәгънәсе; сәяси-иҗтимагый фикерләр: идеология һәм милләт язмышы, система алып килгән фаҗига, милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге кебек мәсьәләрнең бер әсәр чикләрендә очрашуына бәйләнә. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша – интертекстуальлек ярдәмендә ирешелә.

Жанр таләпләре ягыннан шигъри повесть буларак кабул ителгән әлеге әсәрдә дә мондый сыфатлар чагылыш таба, алар милли тема-проблеманы үзенчә бәяләү һәм чишүгә ярдәм итә. Милләт язмышы лирик герой фаҗигасе аша җиткерелә һәм метафорик, шартлы-символик образ-детальләр нигезендә тирәнәйтелә, нәтиҗәдә реалистик әсәр интеллектуаль алымнар белән байый. Композицион җәһәттән үзенчәлекле төзелгән поэма төгәл ике – вакыйгалар һәм хис катламына аерыла. Беренче – вакыйгалар катламы – лирик геройның ятим тормышы, туган җиреннән аерылуы хакында хәбәр итә. Әлеге вакыйгалар катламы үзе үк метафорик яңгырашка ия булып, милләтнең ятимлегенә дә ишарә ясый.

Әсәрнең үзәгендә торган милләт фаҗигасе бик күп күренеш, деталь, элементлар аша көчәйтелә: Агыйдел күренеше, ак пароход, кораб образлары, ут, кое һ.б. Лиро-эпик әсәрнең үзәгенә куелган ут образы символик яңгырашка ия. Әсәр структурасында аның күп мәгънәләре уйнатыла, шушы алым хәтта бер әсәр чикләрендә ут / хыялларның юкка чыгуы, ут / хәтерне уятучы, ут / милләт фаҗигасе, ут / иҗат кебек төрле янәшәлекләрне яктырта алуга китерә. Шуның белән янәшәдә автор ассоциация уята алырлык образ-детальләргә дә

мөрәҗәгать итә. Агыйдел – елга – гомер агышы, ак пароход  кеше гомере, тормышы кебек укыла, пароход янәшәсендәге караб образ-детале милли шигърияттәге караб образы белән бәйләнеш урнаштыра, нәтиҗәдә образның мәгънәсе киңәя, ул аерым кеше чикләрендә генә калмыйча, милләт булып гомумиләшә. Шулар аша милләтне саклап калучы көчләр буларак дин, иман күтәрелә.

Л.Янсуарның “Дөньялыктан саркыламы сагыш...” шигырьләр бәйләмендә дә иҗтимагый фикерләрнең фәлсәфи мотивлашуы күзәтелә.

Романтик юнәлешкә мөнәсәбәтле шигъри әсәрләр, кагыйдә буларак, кешелек, яшәеш кыйммәтләрен аңлау-анализлауга йөз тота, фәлсәфи гомумиләштерүләрне үз итә, дини кануннардан читләшүнең мәгънәсез яшәешкә илтүе, яшәү мәгънәсен югалтуның ачылыгы, шуңа бәйле битарафлыкка, ваемсызлыкка чуму мотивлары урын ала,романтик образ-деталь, алымнарга таяна, аеруча каен, йолдыз, кояш, ай, болыт образларының актив булуы күзгә ташлана. Бу юнәлештәге шигырьләрдә мәхәббәт темасы алга чыга, шуңа мөнәсәбәтле күңел лирикасына мөнәсәбәтле әсәрләр күпчелекне тәшкил итә. Мәсәлән, С.Гәрәеваның “Сердәшем каен”, “Туган бусагам”, “Җәй уртасы”, Р.Сөләймановның “Елыйсыңмы?”, “Белмимен нишләргә”,  һ.б. шигырьләрдә, яшь шагыйрә Д.Нәгыймуллинаның “Бәхетемне сиңа бүләк итәм” шигырьләр бәйләмендә мәхәббәткә бәйле хис-тойгылар урын ала.

Бу юнәлештә Р.Рахманның шигырьләре уңышлы. “Ә сагышым – моңлы җыр икән” шигырьләр бәйләменә тупланган шигъри үрнәкләрдә мәхәббәт лирикасының фәлсәфи мотивлар белән баюы күзәтелә. Шагыйрә мәхәббәтне ике кеше арасындагы хис-халәт баскычыннан яшәү мәгънәсе, яшәеш гармониясенең чыганагы югарылыгына күтәрә, шушы юлда җир кояшы, якты көн, баеган кояш кебек шартлы-романтик образ-детальләргә мөрәҗәгать итә. Шундый ук мотивлар яшь шагыйрә Л.Вәлиеваның “Урап ала моң дәрьясы” шигырьләр бәйләмендә дә урын ала һәм хатын-кызлар шигъриятенең тагын бер талантлы шагыйрәгә баюы хакында хәбәр итә.

Аерым шигырьләр татар поэзиясе өчен традицион туган як темасына мөрәҗәгать итеп языла. Мәсәлән, С.Гәрәеваның “Туган җиргә торам бәйләнеп” шигырендә хис-кичерешләр үткәннәрнең якты хатирәсе буларак саклanучы ялан кыр, тау, су сукмагы образлары аша җиткерелә, алар туган җир белән бәйләнешне саклаучылар булып тәгалләшә. Х.Мөдәррисованың “Уфа” шигыре дә шушы яссылыкта иҗат ителә, туган як, туган каланы ярату хисе үзәккә куела, ал нур, ак сирень исләре, йолдызлы төн, алтын ай кебек романтик образ-детальләр шушы мәхәббәтне ачуга юнәлтелә.

Аерым шигырьләр романтик материалда кешенең яшәеш кануннарын бәяләргә, яшәеш закончалыкларын аерып куярга омтыла. К.Булатованың шигъри әсәрләре шушы фикерне раслый. Шагыйрәнең “Яшәргә омтылыш шундый нык” шигырьләр бәйләменә тупланып бирелгән шигырьләрендә ата-ана сүзен хаклап яшәү; иҗтимагый кануннарга баш имичә, кешелегеңне саклап калу; матди тормышка түгел, рухи яшәешкә, рухи югарылыкка омтылу; мәхәббәттә тугрылык автор тарафыннан шундый яшәеш кануннары буларак билгеләп куела.

М.Мирзаның “Бербөтенлек хакның таләбендә” шигырьләр бәйләменә тупланып бирелгән шигырьләрендә дә шундый сыйфат белән очрашабыз. Әлеге шигъри үрнәкләр татар поэзиясен экзистенциаль мотивлар белән баета. Кеше гомеренең чикләнгәнлеге (“Бер күк астында яшәп тә...”), язмышны үзгәртеп булмау тойгысы (“Козгын кунды өйнең түбәсенә...”) лирик герой күңелендә сызлану тойгысын тудыра. Бу сызлану аерым кеше тормышыннан башлап, милләт яшәешенә кадәр гомумиләшә. Шушы фонда Ә.Фәйсалга ияреп язылган “Табигый сайланыш – катгый канун” шигыре сызланудан юану буларак кабул ителә.

Шушы ук сыйфат белән яшь шагыйрә Г.Корбанова әсәрләрендә дә очрашабыз. “Юшкыннарны юа вакыт” шигырьләр бәйләмендә иманга тугрылык (“Юктыр синең..”), мәхәббәттә тугрылык (“Хыялдагы бер хатирә булып”) төп яшәеш кануннары кебек билгеләнә. “Язларым...” шигырендә яз / җәй / көз / кыш янәшәлеге кеше гомеренең төрле этапларын тергезеп,

вакытның кешедән өстенлеген раслап куя. Шушы ук автор иҗатында форма эзләнүләре дә күзгә ташлана. Мәсәлән, “Кара болыт” шигырендә кара болыт / ак болыт янәшәлеге тудырылып, һәр икесенең дә мәгънәви трансформация кичерүе күренә. Шигырь тукымасында ак болыт бушлык, билгесезлек төсмерен ала, кара болыт – яңгыр болыты – файда чыганагы итеп куела.

Бу чор шигъриятенә хас сыйфатларның берсе буларак интеллектуаль тенденциянең, шартлы-метафорик юнәлешнең үсеш алуы билгеләнә. Әдәби тәнкыйть шигъриятнең бер үзенчәлеге төсендә уйланучан башлангычның көчәюе, лирик геройның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен һәм фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылышның, эчке уйлану, нәтиҗә ясау рухының үзенә бер агым буларак үсүен, интеллектуаль башлангычның көчәюен билгеләп үтә. Интеллектуаль поэзия җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен әдәби материалда чишәргә омтыла, дөньяның, яшәешнең торышына анализ ясый. Еш кына рухи кризис, иҗтимагый торгынлык вакытында алга чыккан интеллектуаль тенденция авторның игътибарын кешенең күңел кичерешләреннән бигрәк, зиһен, акыл мөмкинлекләренә юнәлтә, аларга каршы тору юлларын кешенең үз шәхси мөмкинлекләреннән, интеллектыннан эзли. Биредә автор сөйләүче, аралашучы, әңгәмәдәш кенә түгел, ә бәлки эзләнүче, сорау куючы буларак килеп баса, аның уй-фикерләре әсәрнең хис-кичереш халәтен барлыкка китерәләр. Шуңа бәйләнештә анализ рухы көчәя, шигърияттә аналитик уйлану алга чыга, сәнгатьчә фикерләүдә шартлылыкка, вакыт образына еш мөрәҗәгать ителә. Интеллектуаль тенденция вакыт образын, үтә шартлылык алымнарын үз итә. Җ.Сөләйманов, Й.Миңнуллина шигырьләренең шушы алымнарга йөз тотуы күренә.

“Өтүкән җирендә ут яна” поэмасы әдәби тәнкыйтьтә еш кына “йолдызлар белән генә эш итә” дип тәнкыйтьләнүче Й.Миңнуллина иҗатында да үзгәрешләр барганлыгы хакында хәбәр итә. Әсәр структурасында сюжет сызыгы ике вакыт катламын берләштерә. Тарихи вакыт 552 нче елда I Төрки каганлыгы төзелгән, 604 нче елда аның Көнбатыш һәм Көнчыгыш каганлыкларына аерылган вакытына мөнәсәбәтле вакыйгаларны тергезә,

шартлы алымнардан вакытлар кушылуы күзәтелә. Поэма тарихи сюжетка нигезләнсә дә, төп фикер интеллектуаль сюжет чылбырында җиткерелә. Бүлек башларында тәкъдим ителгән эпиграфлар автор позициясен ачу барышында ачкыч хезмәтен үти һәм төркиләргә бирелгән бәя, аларга бәйле вакыйгалар милләтнең бүгенге халәтенә бәйле фикерләрне үткәрергә ярдәм итә. Коллыкның башы һәр халыкның үз холык-фигыленә, үз асылыннан ераклашуга барып тоташа, ягъни халыкларның җиңелүенә, башка бер халыктан бигрәк, иң беренче чиратта ул үзе, аның төрле гамь белән яшәве гаепле дигән гыйбарә ассызыклана (*“Җиде яугир яудан кайта – Җидесендә җиде ятның гаме”*). Бу фикер автор тарафыннан әйттерелеп, алдагы бүлекләрдә көчәйтелә. Таркаулык– *“Күк белән Җир арасында Минем илем, синең илең”*, үз максатына тугрысызлык, матди байлыкка кызыгып, рухи кыйммәтләрдән читләшү– *“Ялангачны киендерсә, Мал-туарга тиендерсә – Шулай булса, безнең халык, татлы сүзгә хәйран калып,Чаптар атын читкә бора, Дошман белән киңәш кора – Сөйгән яры тол була. Оланнары кол була”*, динсезлек, Аллаһ каргышы – *“Дин үзгәртә. Җилкәсенә баса Тәңре каргышы”,* тәхеткә омтылыш нәтиҗәсендә хакимият вәкилләренең тугрысызлыгы – *“Иярлә дә бүз атыңны, Чирү тупла сак кына, Үз халкыңа түгел, Тәгин, Бөек илең хакына”*, ятларга хезмәт итү – *“Елтыр күлмәген сәдәпләп, Үз исемен җуйган бәкләр”*, мескенлек – *“Каганнан ятим калып, Йола алыштырган халык”* кебек тулаем тискәре сыйфатлар татар халкының холыгын ассызыклый, үз чиратында бу сыйфатлар “Аллаһ каргышы” – җиңелүгә – этәрүче көч дип алына. Шушы өлештә әсәр тукымасына автор фикере кушылып, аның үз халкын кисәтүе, әле дә булса дәвам иткән мондый тискәре сыйфатлардан арынырга чакыруы булып яңгырый.

Дәүләтчелекне югалту вакыйгалары белән бәйле халык фаҗигасе хис катламының эчтәлеген билгели: лирик герой күңелендәге әрнү, сызлануга сәбәп төсен ала. Татарларның тискәре холкы тудырган борчылу белән алмашыну аша сызлану үзенең югары ноктасына күтәрелә, киләчәкнең билгесезлеге аны тагын да көчәйтә. Шул рәвешле, төп фикер сюжет үстерелеше ярдәмендә түгел, ә

бәлки, интеллектуаль әдәбиятка хас булганча, фикер сөземтәләре ярдәмендә ачыклана. Бу әсәр Й.Миңнуллинаның матур табышы булып тора.

Интеллектуаль алымнар аша яшәешкә (җиһан) һәм җир тормышына, кешегә бәя бирү омтылышы Сөләйманның "Татар бишегендә татар баласы", "Канатларны – каурый каләм иттем" кебек шигырьләрендә дә көчле.

Тагын бер тенденция төсендә модерн алымнарның активлашуы күзгә ташлана. Әлеге үзенчәлек Б.Ибраһимов, Р.Зәйдулла, Р.Акъегет шигырьләрендә урын ала. Мәсәлән, бу яктан Р.Зәйдулла шигырьләре үзенчәлекле, кызыклы. 1990-2000 нче еллар аралыгында экспрессионистик алымнарга еш мөрәҗәгать иткән, гыйсъянчы лирик геройны әдәби мәйданда яңарткан Р.Зәйдулла шигырьләрендә башка стиль тенденциясе алга чыга. "Чарасыздан җанны бер өн били" шигырьләр шәлкемендә шагыйрь, проза әсәрләренә хас үзенчәлекне яңартып, символларга мөрәҗәгать итә, шулар аша ачылган автор позициясе күпкатламлы төсмер ала. Мәсәлән, "Кирмән" шигырендә кирмән, чәнечкеле гөлләр, үксез кош образлары бүгенге вазгыять шартларындагы милләт яшәешен шәрехләргә мөмкинлек бирә. "Төрек кызы" шигырендә лалә, янып торган пиала кебек суфичылык поэзиясе аша таныла торган образлар һәм яну мотивы ("*Ымсындыра безне гыйшык кичәсе, Пиаладан янар өчен эчәсе, - Актарырлар аннан безнең көлләрне, Һәм ташларлар өскә лалә гөлләрен"*) дөньяви мәхәббәтне ачуга юнәлтелә. Суфиларда шәраб эчеп исерү сурәте актив кулланыла; Аллаһ белән кушылу мотивының көчле булуы билгеле. Шигырьдәге әлеге сурәтләр исә дөньяви контекстта хатын-кызга мәхәббәтне тасвирлый. Лирик герой җир кызына мәхәббәт тотучыга әверелә. Шуларга нисбәтән шигырьнең идеясе дә формалаша: мәхәббәт кеше күңеленә рәхәт бирә, бәхет китерә.

"Җәлил" шигырендә дә символик сурәт алга чыга. Дәрдемәнд шигъриятеннән үстерелә килгән ил карабы, диңгез образлары милләт тормышын, яшәешен гәүдәләндереп килә. Үзенчәлекле образлар системасы ярдәмендә шагыйрь татар милләтенең торышын күрсәтә, шагыйрь һәм милләт язмышын илаһи бердәмлектә сурәтләргә омтыла.Гомумән, бу чор лирикасында

кораб бату, йотылу куркынычын аңлата һәм аның котылуы өчен кирәк булган корбан борынгы риваятьләргә ишарә ясый. Халыктагы ышанулар буенча, бата башлаган корабтан бер җанны диңгезгә ташлау котылу китерә, дип уйланыла. Шигырь тукымасында символның әлеге мәгънәсе урын ала һәм бетү, югалу, үлем мотивын алып керә, “диңгез сораган ясак” карабны коткару өчен кирәкле корбан булып аңлашыла, “диңгез сораган ясак” / Җәлил янәшәлеге тудырыла. Шул рәвешле Җәлил гомеренең милләт язмышыннан аерылгысызлыгы ассызыклана: ул, милләтенең киләчәк бәхете хакына, халкын коткару өчен җанын бирә. Иҗат кешесе – милләт сакчысы, иҗат – рух сакчысы мотивы Р.Зәйдулланың “Җиз кыңгырау”, “Риваять” шигырьләрендә дә үзәккә куела.

Р.Акъегетнең “Күңелем – салават күпере” шигырьләр бәйләмендә үзгә күренеш белән очрашабыз. Биредә янәшәлекләрне үзәккә кую төп алым буларак аерылып чыга, нәкъ менә әлеге үзенчәлеккә, үзгә шигырь калыбына мөрәҗәгать итү, бер яктан, Р.Фәйзуллинның кыска шигырьләре белән ассоциатив бәйләнешләр уздырырга мөмкинлек бирә, икенче яктан традицияләрнең дәвам итүен, алай гына да түгел, 1960 нчы елларда яңалык буларак кабул ителгән бу сыйфат-үзенчәлекләрнең “үз” булып өлгерүен, милли шигъриятькә хас күренеш буларак үзләштерелгәнлеген раслый. “Яшьтәшләрдән…”, “Агачлар биек булганда…”, “Кояш сурәте” шигырьләре шул рәвешле кабул ителә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Хәзерге татар поэзиясе поэзиясе ни рәвешле үсеш-үзгәреш кичерә?
2. Хәзеге татар шигъриятендә нинди мотивлар аерылып чыга?
3. Хәзерге татар поэзиясендә лирик геройга нинди үзенчәлекләр хас, ул нинди үзгәреш кичерә?
4. Соңгы еллар татар поэзиясенең йөзен билгеләүче төп сыйфатларны, стиль тенденцияләрен билгеләгез.

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т. Шигърият офыклары / Т.Н.Галиуллин // Татар шигрияте: 1980-2000 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б.4-30.

2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.428-435

4. Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.3: В конце века (1986-1990-е годы): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 160с.

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

## Тема 2. Р.Харис иҗаты (1943)

**Лекция 2**

**Аннотация.**Лекциядә Р.Харис иҗатының үсеш-үзгәреш юллары билгеләнә, иҗатына хас төп үзенчәлекләр аерып алына. Интеллектуаль тенденция бирелеше ачыкланып, поэмалары һәм лирик әсәрләре мисалында раслана.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, поэма, интеллектуаль тенденция, модерн алым.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

6. Р.Харис иҗатында интеллектуаль тенденция.
7. Шагыйрьнең “Ат иярләү” поэмасына анализ.
8. Р.Харисның “Рәссам” поэмасында шартлы сурәтлелек.
9. Шагыйрьнең “Ант суы” поэмасында вакыт рәтләре һәм алар аша үткәрелгән фәлсәфә.
10. Шагыйрь лирикасында интеллектуаль тенденция алымнары.

Р. Харис поэзиягә алтмышынчы елларда килә һәм тиз арада үз стилен, үзенчәлекле сурәтләү алымнарын эзләүче, фәлсәфи юнәлешле сүз остасы, “кичереш белән бергә акыл, фикер эшчәнлеген ачуга, заманның әхлакый, рухи проблемаларын тарихи үткәннәр аша үзенчәлекле тел бизәкләре, кыю метафоралар ярдәмендә, тормышны фәлсәфи катлаулыклары белән ачуга омтылучы шагыйрьләрнең берсе” булып танылa.

Әдәби тәнкыйть 1970 нче еллар татар шигъриятенең бер үзенчәлеге төсендә шау-шулы эстрада поэзиясенең арткарак чигенеп, уйланучан башлангычның көчәюе, лирик геройның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен һәм фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылышның, эчке уйлану, нәтиҗә ясау рухының үзенә бер агым буларак үсүен, интеллектуаль башлангычның көчәюен билгеләп үтә. XX гасырның 70нче елларында рус прозасында да интеллектуаль башлангычның көчәюе, ягъни дөнья катаклизмнарына каршы тору мөмкинлекләрен кешенең субъектив дөньясыннан эзләү процессының актуальләшүе күзәтелә. И.Р. Ратке әлеге процессның, гомумән, аерым милли әдәбиятлар һәм әдәби юнәлешләрдән өстен булуын күрсәтә. Милли әдәбиятта интеллектуаль поэзия җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен әдәби материалда чишәргә омтыла, дөньяның, яшәешнең торышына анализ ясый. Шушы еллар аралыгында башланган рухи кризис, иҗтимагый торгынлык нәтиҗәсендә интеллектуаль тенденция авторның игътибарын кешенең күңел кичерешләреннән бигрәк, зиһен, акыл мөмкинлекләренә юнәлтә, аларга каршы тору юлларын кешенең үз шәхси мөмкинлекләреннән, интеллектыннан эзли.

Шагыйрь үз күзаллаулары, максатлары, идеаллары булган кеше, шәхес буларак, җәмгыятьнең, тормышның начар якларын җиңәргә сәләтлеме? кебек сорауларга җавап эзли. Шуңа бәйләнештә анализ рухы көчәя, шигърияттә аналитик уйлану алга чыга, сәнгатьчә фикерләүдә шартлылыкка еш мөрәҗәгать ителә.

Интеллектуаль тенденция вакыт образын, үтә шартлылык алымнарын, хикмәтле сүз, фразеологик әйтелмәләрне үз итә, мондый әсәрләрдә фәлсәфи, концептуаль башлангычның көчәюе, бер әдәби әсәр структурасында ике катламның берләшүе күзәтелә, ул алгы – сурәтләү, сюжет катламыннан һәм арткы – метафизик башлангычтан оеша, автор сюжетны табышмакка әйләндереп, укучының үзенә чишәргә калдыра. Моннан тыш интеллектуаль әдәбиятта вакыт рәтләренең үзара катнашуы, реалистик сюжетка мифология яисә фольклор элементларының кертелүе (новелла, легенда, борынгы мифик сюжет, реаль геройлар белән контактка керүче фантастик персонажлар) кебек сыйфатлар да күзәтелә.

Д.Заһидуллина милли җирлектә иннтеллектуаль әдәбиятның фәлсәфи-психологик, иҗтимагый, әхлакый төсмерләр белән баетылуын билгели: “яшәеш, тормыш, кешегә караган универсаль кануннарны эзләп, шуларны барлап һәм укучыга тәкъдим итеп язылган әсәрләрдә автор-хикәяләүче образы беренче планга куела. Интеллектуаль башлангычның гротеск формасына, сатирик пафоска мөрәҗәгать итүе совет җәмгыятенә көчле тәнкыйть белән караган, антиутопик дөнья тудырган әсәрләр китереп чыгара. Ирония кеше тормышының мәгънәсезлеге, кешелекнең юкка чыга баруы хакындагы сызлану фәлсәфәсе белән үрелә”.

Татар шигъриятендә интеллектуаль тенденция нәкъ менә Р. Харис иҗатында алга чыга, аның шигырьләре дә, поэмалары да интеллектуаль алымнарга корыла. Р. Харисның иҗатын әлеге яссылыкта күзәтү-бәяләү аның шигъриятенең генә түгел, ә бәлки, татар әдәбиятының да үсеш тенденцияләрен ачыграк тоярга ярдәм итә, аның дөнья әдәбиятлары белән янәшә атлавын дәлилли.

Р. Харисның иҗтимагый җирлекле, кеше “атының” иң тирәндә качып яткан фикер катлауларына үтеп кергән “Ат иярләү” поэмасында ике катлам аерылып чыга: реалистик сюжет сызыгында Кәрам атының сугышка китүе, аннан качуы һәм Кәрамның, аты качып кайткан көннән соң, сугышка китеп, җиңүче буларак Туган иленә кире әйләнеп кайтуы сурәтләнә. Поэманың төп герое Кәрам сугыш юлыннан качып кайткан атына тирән серләрен ача, улының Украина җирендә ятып калуын хәбәр итә. Ат шунда, нәкъ экияттәгечә, телгә килә һәм сугыш афәтеннән котылып кайтуы турында сөйли. Биредә сюжет канвасына икенче сюжет сызыгы – ирреаль катлам килеп керә: шагыйрь кеше аңында барган фикер үсешен, үзгәрешен сурәтләүгә күчә.

Сюжет канвасының артына яшеренгән әлеге икенче катлам беренчесенең метофорасы буларак аңлашыла һәм ул “ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятар” гыйбарәсе аша ачыла. Татар фольклорында ир-егетнең иң мөһим атрибуты – ат, җайдак батырлык символы, борынгы гуннар заманыннан килгән семантик схема буларак билгеле. Фольклорның һәр жанры бу фикерне раслый: экиятләрдә атын югалткан егет бәлагә тара, халык җырларында “ир канаты - ат” дип җырлана, мәкальләрдә дә ат егет кешенең йөрәгенә тиңләштерелә (“Ир-егетнең йөрәгендә Иярләнгән ат ятар”). Шул рәвешле, ат ир кешене бәяләүче критерийга әверелә. Кәрамның аты белән сөйләшүе асылда үз күңеленең иң тирән төпкелләренә төшүе, үз күңелен битәрләве буларак аңлашыла. Метафорик, ирреаль катлам поэманың башыннан ахырына кадәр реаль сюжет сызыгы белән үрелеп бара һәм кешенең асылына кайту процессына нигезләнә. Үз алдына уйланудан, үз ялгышын, иленә, намусына хыянәтен танудан “ул оят төсле” кызыра, “аптырау төсле” агара һәм үз йөрәгендә бу куркак ат түгел, ә иярләнгән ат ятуы турында нәтиҗә ясый. “Ат иярләү”, шул рәвешле, сугыш чорын тасвирлаудан бигрәк, һәр заманда актуаль һәм һәр дәвердә үзенчә, яңача яңгыраган кешедә кешене табу һәм раслауга йөз тота.

Сюжет үстерелешенә түгел, хис-фикер үстерелешенә нигезләнгән “Рәссам”да тасвирлы сюжет күзәтелми. Поэмада ике ассоциатив рәт барлыкка килеп, беренчесе рәссам остаханәсенә килгән гүзәл кыз, сугыш афәте чорнап

алган ил, сугыштан соң җимерелеп беткән, янгыр көтеп яткан җир белән бәйләнештә ачыла, әмма алар сюжет сызыгы барлыкка китерми, ә бәлки икенче ассоциатив рәткә күчеш ясый. Рәссам кулы киндердә тере кеше сынын тудыра, кыз аның өчен иң элек "тәнгә әверелгән илаһи пакълек", "батырлар анасы булырлык тиңдәшсез гүзәл" белән тиңләштерелә. Әмма кызның кылган гөнаһы сихри сурәтне юкка чыгара, гөнаһ сугыш белән ассоциация тудыра һәм икенче ассоциатив рәтне барлыкка китерә.

Күчеш "рәссам күңеле" аша башкарыла һәм киндергә төшерелгән сурәт рәвешендә чагылыш таба. Рәссам күңеле җир халәтен билгеләүче ролен башкара һәм ассоциатив дөнья барлыкка китерә. Авторның фикер үсеше сюжет үзгәрешен тәэмин итә, реаль дөнья күренешләре белән ассоциацияләнгән хыялый күренешләр мәңгелек мәсьәләләрне билгеле бер чор рамкаларыннан чыгарып, тарихи дәвамчыллыкта күзәтергә ярдәм итә. Р. Харис чынбарлыкны икеләтә торган "проекция" алымын куллана. Бер яктан, берсен-берсе кысрыклап килгән катлаулы проблемалар белән тулган мәшәкатьле олы дөнья сиземле-тоемлы образлар аша реаль бөтенлегендә тасвирланса, икенче яктан, әле генә безнең күз алдыннан үткән вакыйгалар һәм күренешләр яшәешне, рухи дөньяны камилләштерү, бизәү нияте белән илһамланган рәссамның ассоциатив сиземләве, күрүе аша сынландырыла. Интеллектуаль башлангыч реаль һәм ассоциатив күренешләрнең синтезы аша гәүдәләнеш таба. Р.Харис "кеше бу дөньяның әхлаксызлыгына, пычраклыгына каршы тора аламы?" кебек сорауны проблема дәрәҗәсенә күтәрә һәм гүзәл кызның сурәтен торгызу аша "әйе" дип җавап бирә.

Р. Харисның интеллектуаль тенденция чагылышы ягыннан аерым игътибарга лаек "Ант суы" поэмасында сюжет сызыгы ике вакыт катламын берләштерә. Тарихи вакыт 985 елгы Русь һәм Болгар килешүен яктырта, Сувар патшасының хыянәте, Владимирның Болгарга яу белән чыгуын, Мөхәммәт патшаның таш белән атарга теләгән кешегә аш белән җавап бирү кирәклеген истә тотып килешү төзүелүен сурәтли. Поэмада шартлы алымнардан вакытлар кушылуы күзәтелә. Ул тарихи сюжетка нигезләнсә дә, төп фикер

интеллектуаль сюжет чылбырында җиткерелә, биредә автор-хикәяләүче образы беренче планга чыга. Төп фикер “Татар башын татар ашар” дигән халык мәкале аша ачыклана. Татар халкы үз тарихына үзе аяк чала: бер яктан халыкның үз уллары аңа хыянәт итсә, икенче яктан – халык бу мәкерне сизми кала, “Болгар патшасы йоклый. Йоклый берничә халыкның язмышына бәйле тарих”, ягъни төп фикер сюжет үстерелеше ярдәмендә түгел, ә бәлки, интеллектуаль әдәбиятка хас булганча, фикер сөземтәләре ярдәмендә ачыклана. Бу авторның матур табышы булып тора. Әлеге сыйфатлар шагыйрьнең “Һарут белән Марут”, “Бүре күзе”, “Тукайның мәхәббәт төшләре” кебек поэмаларында да дәвам итә, үстерелә.

“Интеллектуальлек” сыйфаты шагыйрнең лирикасында да үстерелә. Сәнгати чаралардан ихтыярлы чагыштырулар, көтелмәгән борылышлар, катлаулы чагыштырулар, сынландыру, янәшә кую, бер күренешнең мәгънәсен икенчесеннән табу, өченчесе ярдәмендә ачу — Р.Харисның лирик фикерләү үзенчәлеге. Шул алымнар ярдәмендә шагыйрь лирик героеның эчке халәтен җиткерә, фәлсәфи фикерләү үзенчәлеген ача. Аның лирикасында, интелектуаль шигърияткә хас сыйфатларның берсе - вакыт белән “уйнау” хас. Вакытның бирелеше ягыннан «Вакыт ага» шигыре кызыклы. Исеменнән үк күренгәнчә, шагыйрь Вакытка аеруча хас булган сыйфатны — аның үтүен күрсәтү.

Ренат Харис аккан суны аккан Вакытны тәңгәлләштереп, Кеше гомере һәм Мәңгелек вакытны каршы куя һәм Мәңгелекнең дәвамлылыгын, өстенлеген искәртә.

Вакытның үзгәрә алу сәләте һәм бу үзгәрүнең кеше файдасына булмавы авторда бер үк вакытта чарасызлык һәм сагыш хисләре дә уята. Вакыт образына мөнәсәбәттә төп фикер формалаша: Вакыт кешегә тәэсир итү, аны үзгәртә алу көченә ия. Шул рәвешле, Вакыт – кеше гомеренең узу билгесе генә түгел, ә шул гомер дәвамында аң үсешен чагылдыру мөмкинлеге дә (“...Чәчләремдә - карадан акка...”).

Р. Харис өчен хас Вакыт образы кеше белән тиңләштерелә, хәтта кайбер очракларда Кеше Вакыттан өстен куела. “Яшь Вакыт” шигыре аеруча үзенчәлекле. Әлеге шигырьдә Вакыт – Кеше мөнәсәбәтләренең яңа төре ачыла:

Биредә циклик Вакыт чагылыш таба һәм ул кеше гомерен этапларга бүләргә ярдәм итә. Инде олы яшькә җиткәч, зирәк лирик герой үзенең гомере узып баруын һәм картайганын аңлый. Ул кешенең мөмкинлекләре Вакыт белән чагыштырганда гаять чикле икәнлеге турындагы хакыйкатькә ирешә. Һәм әлеге хакыйкать лирик геройда сызлану хисен уята. “Чиксез кодрәт” әсәрендә Вакыт чагыштырулар аша бирелә. Чагыштыру объектлары итеп шырпы (*Караңгыдан котылып була*), кояш (*Төнгә каршы котылып* була) һәм учак (*...ягып котылып була суыктан*); дару (*дару белән чигереп була үлемне...*) алына. Болар янәшәсендә Вакыт — мәңге җиңелмәслек, мәңге югалмаслык Куәт, чөнки Вакыт барлык элементларның функциясен үти ала: кояш яктылыгын, җан җылысын бирә ала һәм иң мөһиме – Вакыт дәвалый.

Биредә дини фәлсәфә шигырьдә Вакыт – Алла янәшәлеге тудырылып, Вакытның көче яңа баскычка күтәрелә. Вакыт образының яңа сыйфаты ачып ачыла: аның өлештән бөтенгә һәм бөтеннән өлешкә күчә алу мөмкинлеге.

Шулай итеп, Р. Харис иҗатында интеллектуаль тенденция реаль һәм ирреаль катламнарның синтезы, ассоциатив рәтләр барлыкка китерү, вакыт таләпләреннән читкә тайпылу, фольклор элементларына мөрәҗәгать итү һәм автор-хикәяләүче образын беренче планга чыгарып, универсаль кануннарны эзләү омтылышы кебек сыйфатлар белән билгеләнә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Р.Харис иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?

2. Шагыйрьнең “Ат иярләү” поэмасында интеллектуаль тенденциягә хас нинди алымнар урын ала?

3. “Рәссам” поэмасында интеллектуаль тенденциягә хас нинди алымнар урын ала?

4. “Ант суы” поэмасында интеллектуаль тенденциягә хас нинди алымнар урын ала?

5. Шагыйрьнең лирикасында нинди мотивлар урын ала, образ-детальләр нинди функция башкара?

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т.Н. Шәхесне гасырлар тудыра / Т.Н. Галиуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 192 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык) / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

3. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

4. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.428-435

5. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

## Тема 3. З.Мансуров иҗаты (1949)

**Лекция 3**

**Аннотация.** Лекциядә З.Мансуров иҗатына хас төп үзенчәлекләр билгеләнә, чор әдәбиятына алып килгән яңалыклары, традицияләрне дәвам итүе тикшерелә. Реализм юнәлешен баетуы поэмалары, лирик әсәрләре мисалында раслана.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, тематика, реализм, поэтик алымнар, мифологик сюжет һәм образ.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың

үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. З.Мансуровның туксанынчы еллар лирикасында мотивлар бирелеше.
2. “Ике егълау” поэмасында катламнар синтезы.
3. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасына хас үзенчәлекләр.
4. “Хозер Ильясны эзләү” поэмасында модерн алымнар.

Билгеле булганча, сиксәненче-туксанынчы еллар чигендә поэзия яңа үсеш сукмакларын барлый башлый: Зөлфәт, Л.Шагыйрьҗан, Р.Зәйдулла, Г.Морат, Р.Аймәт, Р.Сүлти һ.б. модернистик эзләнүләр юлына керә, әлегә зурдан кубып постмодернистик шигърият турында сөйләргә иртәрәк булса да, Сөләйманның аерым шигырьләре постмодернизмның беренче билгеләрен хәбәр итә. Бүгенге поэзиядә әлеге юнәлеш, агымнар бергә берегеп үсә-үзгәрә, теге яки бу юнәлешкә мөнәсәбәтле шагыйрьнең иҗатында да башка агым, метод билгеләре күренә. Зиннур Мансуровның соңгы еллар иҗаты да әлеге сыйфат үзгәрешләрен үзендә тоя.

Шагыйрьнең иҗатында 1990 нчы еллар аерым урын тота, шушы чорда язылган шигырьләрне татарның бәйсезлеге, киләчәге, язмышы өчен сызлану берләштерә, җәрәхәт милли фаҗига эчтәлегенә төреп бирелә ( “Төрмә эчендәге читлек”, “Киек каз юлы”, “Тартар”, “Баш”, “Беренче киселгән ярымай”, “Татар бугазы” һ.б.). Бу төркем шигырьләрдә төп эчтәлек аерым символик образ, метафора, детальләр аша гомумиләшә. Мәсәлән, “Төрмә эчендәге читлек” шигырендә шундый образлар тезмәсе итеп төрмә, читлек һәм кош образлары алына. Читлек эчендә бәргәләнгән кош образында бәйсез, хөр булып яшәргә хыялланган татар халкы гомумиләштерелсә, төрмә хөкем сөргән система, коллыкны максат иткән идеологияне символлаштыра, соңгысының асылын ачып бирүгә кан эчүче черки, тәмуг, иблис авы кебек метафора, чагыштырулар

да ярдәмгә килә. Шундый халәттәге тормыш-яшәеш, үз чиратында, лирик герой күңелендәге сызлануга сәбәп төсен ала.

“Рояльнең кара телләре” шигырендә романтик шигърияткә хас антитезалар белән очрашабыз. Шигырь романтик контрастларга корылуы белән аерылып тора. Көзге төн, кара болыт, кара язмыш – ак шомырт чәчкәләре каршылыгы, кара рояль телләре – “Карурман” янәшәлеге аша автор халыкның кара язмышын чагылдыра, аның үткәне, киләчәге өчен сызлана. “Илбакча һәм колонист”, “Ай кызына төбәлгән уй”, “Баш” кебек шигырьләрне тугандаш Кырым татарлары язмышы өчен әрнү, борчылу бер үзәккә җыя.

Тарихи темага язылган “Ике егълау” поэмасы да - әнә шул төркемгә кергән әсәрләрнең берсе. Татарның дәүләтчелеген югалту тарихын сурәтләгән шигъри, эпик әсәрләр иҗат итү белән мавыккан чорда язылса да, поэма милли тема-проблеманы үзенчә бәяли һәм чишә. Милләт язмышы биредә Сөембикә фаҗигасен яктырту аша чагылдырыла. Сөембикә һәм Ярославнаның егълашулары, “диалогы” нигезендә композицион җәһәттән үзенчәлекле төзелгән поэма төгәл ике – вакыйгалар һәм хис катламына аерыла. Беренче – вакыйгалар катламы – Сөембикә һәм Ярославнаның егълашу сәбәпләрен ача. Бу диалог үзе үк символик яңгырашка ия, ул ике халыкның үзара эчке кичерешләрен уртаклашуын да гәүдәләндерә, ике арадагы фаҗигале каршылык кебек тә кабул ителә. Сәяси-дини әһелләр куерткан конфликтлы ситуация рус һәм татарларның холык-фигыльләрендә, эш-гамәлләрендә чагыла. Урысларның һәрвакыт башлап татарга яу чабуы, коллыкка төшерүе, хәрәмләшүе беренчесен гаепләү булып яңгырый.

Татар шигъриятендә еш кулланылучы, билгеле алымнардан саналган төшләр, хәтта төсләр дә әсәр тукымасына табигый төстә шул максаттан чыгып кертелә. Гадәттә булачак вакыйгаларны, киләчәк фаҗигане искәртүче мәгънәсендә йөргән төш биредә, барыннан да бигрәк, ул ике арадагы каршылыкны ачып бирү вазифасын үзенә беркетә. Сөембикә төшендә энҗе-мәрҗәннәр белән саташса, Ярославнаның күргән төшләре кара төсләр белән бәйләнә: кара кошлар, җиргә кара яулыгын япкан әнкәсе. Каралык аларның үз

кайгысын ачып бирү белән бергә, татар дөньясына китергән хәсрәтен дә гәүдәләндерә. Сөембикә түшендәге энҗе-мәрҗәннәрнең дә үз мәгънәви чишелеше бар. Урта гасырларда ук киң әдәби әйләнешкә кергән энҗе символик образы күз яше мәгънәсендә йөри, аның семантикасы күз яшенең дә кыйммәтле хәзинә булуын белдерүгә юнәлтелә. Әнә шулай образның күпмәгънәлелеге поэмада ике катлам эчтәлек тудырырга - татар дәүләтенең данын, зурлыгын, бөеклеген һәм шуны югалту белән бәйле милләт фаҗигасен чагылдырырга ярдәм итә.

Әсәрнең үзәгендә торган милләт фаҗигасе бик күп күренеш, деталь, элементлар аша көчәйтелә: Идел-Йорттагы көз күренеше, җиңелү кайгысыннан хәтта ташларның, бичураларның елавы, шәмдәлләргә шомландыргыч яшьләрнең тамуы, сусыз дала кылганнарының болытларның яшен койган бөркеткә сәҗдә кылуы һ.б. Соңгысы метафора хезмәтен дә үти. Ә.Еникидәгечә кылганнар “җил кая иссә шул якка авышучылар”, ягъни үзмаксатсыз, битараф кешеләр булып төгәлләшә. Аның сусыз дала белән янәшәлеге мәгънәне яңа төсмерләр белән баета. Милли тарих, дәүләтсезлекне гәүдәләндерүче сусыз дала белән кылганнар дәүләтсез калган татар халкының кыйбласызга әйләнүен, яраклашуын аңлатуга китерә һәм олы милли фаҗига буларак кабул ителә.

Бәгырьләрдәге Вакыт белән Хәтер бәрелеше, бердәмлеге, ягъни хронотоп әсәргә үз мәгънәсен алып керә, ул автор әйтергә теләгән фикер-идея белән кисешә. Хәтер – ул халык күргән-кичергәннәрнең күңелдәге чагылышы, вакыт агышына да карамый канында, бәгырендә саклана торганы. Көзгеле композиция ярдәмендә аның ахырда кабатлануы мәгънәне тагын да көчәйтә генә.

Каршылык шул рәвешле үстерелеп, шигъри тукымага Хәзрәти Мәрьямнең иңүе белән чишелә. Дини затның “күк дөньясыннан” җиргә төшерелүе нәфрәт белән тулы аң-акылны ачарга, җиңелүне “күк каргышы” төшү дип аңлатырга мөмкинлек бирә. Хәзрәти Мәрьямнең “Сезне гирьян иткән дошман явы – Аллаһ биргән сынау вәгъдәсе” сүзләре шуны раслау кебек яңгырый. Каргыш төшүнең башы һәр халыкның үз холык-фигыленә,

Хакыйкатьтән, милли асылларыннан ераклашуга барып тоташа, ягъни халыкларның җиңелүенә, башка бер халыктан бигрәк, иң беренче чиратта ул үзе гаепле дигән гыйбарә ассызыклана (“Искәртмиме безнең өстебезгә ябырылып торган яу үзе? Үткапчыкта гына утырадыр дошманыңның үтә явызы.”). Бу фикер Мәрьям авызынан әйттерелеп, Сөембикә тарафыннан кабатлаттырыла. **Сабырсызлык** – “Чыдамлыгын яшькә чылатмаган сабырларны сөя Аллабыз.”, **диннән, Аллаһтан ерагаю, имансызлык** – “Алыштырмый зекер әйләүләрне, гыйбадәтне андый аһ-ваһлар.”, “Үтәмисез фарыз кануннарны – унның берсен генә булса да.”, **масаю** – “Ил-суларын җәннәт мисалында күреп масайганнар кем иде?” (Хәзрәти Мәрьям) кебек ике халыкка да хас тискәре сыйфатлар саналса, Сөембикә монологы **вакланышу** – “Вакланыша торды алыплары киртә булып калкыр тау саен” , **таркаулык –** “көчен туплый алмый төрки кавем зурдан купкан дошман каршында”, **кардәшлекне сакламау –** “Безнең халык бер көн тора алмас туганара ызгыш, дау юкта...”, “Карымталар кырды кардәшлекне, онытылды ыру вәгъдәсе”, уй белән гамәлнең аерылуы, **масаю** – “Күккә сыймас мәгърур бөркет җаны яши кебек... хәзер тавыкта”, **үчләшү** – “Безнекеләр һаман бугазлаша кечтек кенә иске бер үчтән”, **мордарлык** – “Мордарлыкка баткан мирзаларым, нәрсә җене сезгә кагылган? Аллаһыны сөю тәһарәте кылынмыйдыр алай кан белән”, **мескенлек** – “Гарьсезләрең дала горурлыгын сатты юк-бар бүләк хакына; мескенләнеп сорау мисалында Мәскәүләргә китте хат кына”, кебек тулаем тискәре сыйфатларның татар холыгын шәрехләвен ассызыклый, үз чиратында алар “Аллаһ каргышы” – җиңелүгә - этәрүче көч дип алына. Шушы өлештә әсәр тукымасына автор фикере кушылып, аның үз халкын кисәтүе, җәрәхәте, әле дә булса дәвам иткән начар сыйфатлардан арынырга чакыруы булып яңгырый.

Милли дәүләтчелекне югалту вакыйгалары белән бәйле халык фаҗигасе хис катламының эчтәлеген билгели: лирик герой күңелендәге әрнү, сызлануга сәбәп төсен ала. Татарларның тискәре холкы тудырган борчылу белән

алмашыну аша сызлану үзенең югары ноктасына күтәрелә, киләчәкнең билгесезлеге аны тагын да көчәйтә.

Шагыйрь иҗатындагы икенче төркем шигырьләрне балачак, яшьлек, аның аерылгысыз юлдашы булган мәхәббәтнең югалу, үтү җәрәхәте, аларны кабат кайтару мөмкинлеге булмауны төшенү, аңлау тудырган сызлану, әрнү хисе бер бәйләмгә туплый. “Яшьлек кайтавазы”, “И балачак...”, “Пирамида”, “Туган йортта” һ.б. лирик шигырьләре шундыйлардан. “И балачак...” шигырендә төп эчтәлек бүгенгене һәм балачакны чагыштыру аша җиткерелә. Балачакның матурлыгы - аның гамьсезлегендә, беркатлылыгында, ә бүгенге лирик геройга нәкъ әнә шул сыйфатлар җитми, сабыйчакның самимилеге сагындыра.

Бу фикер үзенә бер шигъри ояны хәтерләткән, татар халкының бүгенгесе, җәмгыять, аның торышы өчен борчылып, әхлакый яктан кешелекнең өзлексез түбәнгә тәгәрәве нәтиҗәсендә туган җәрәхәтне ачып биргән өченче бәйләм шигырь-поэмаларда тагын да тирәнрәк ачыла.

Кыйсса, миф традицияләренә таянган, композицион яктан катлаулы һәм үзенчәлекле әсәрләрдән саналган “Хозер Илъясны эзләү” поэмасы берничә катламның әдәби кушылмасын тәшкил итә. Гомумән, соңгы елларда мәйданга чыккан татар поэмаларының бер хасияте булып төрле катламнарның синтезына омтылыш тора. Ул синтез еш кына дини-мифологик образлар, гыйбарә-әйтелмәләр аша уздырылган фәлсәфи уйланулар: кеше һәм гомер, яшәү һәм үлем, вакыт агышы, кеше гомеренең бәясе, яшәү мәгънәсе; сәяси-иҗтимагый фикерләр: идеология һәм милләт язмышы, система алып килгән фаҗига, милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге; әдәби-мәдәни мәсьәләләр: шагыйрь шәхесе, аның вазифа-бурычлары турында уйлануларның бер әсәр чикләрендә берләшүе белән аңлатыла. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша – интертекстуальлек (Борев Ю.) ярдәмендә ирешелә. Әлеге сыйфат-хасиятләрне “Хозер Ильясны эзләү” поэмасы да чагылдыра.

Эпиклыктан бигрәк, лирик башлангычка өстенлек биргән әсәр милли-сәяси, фәлсәфи катламнарның берлегеннән гыйбарәт. Поэмада милли-сәяси катлам иҗтимагый халәткә бәя төсен ала. ГУЛАГ, төрмә-лагерьларның бар куәтенә эшләве, меңләгән шәхесләрнең җанын кыйган шәхес культы, инкыйлаб, сансыз сугышлар, җәмгыятьтә хөкем сөргән **намус һәм намуссызлык** (“намус җаннан кадерле”ләр белән намуссызлар көрәше), **фәхишәлек** (“каруланган “кызлар” карыныннан күпме җаннар китте гарешкә”), **битарафлык** (“борчылуны белмәс бәндәләрнең бәгырендә бүген каты боз”), **яманлык** кебек күренешләр аша көчләп урнаштырылган система, идеология кире кагыла, мәгънәсез сәясәт татар милләтенә төшкән фаҗига буларак бәяләнә һәм милләтнең хәтере югалу, колга әйләндерелүе (7 баб), битараф затларга әверелүе (11 бабатагы бишек җыры идеологиягә бәя кебек аңлашыла) белән исбатлана. Милләтнең таркалуының татар авылларының юкка чыгуы белән янәшәлеге фаҗиганең икенче ягын ачып бирә. “Вөҗданның вөҗүдтән аерылуы”, буыннар арасындагы бәйләнешләрнең йомшаруы, ата-угыл мөнәсәбәтләренең катлаулануы татар фаҗигасенең өченче кыйтгасы булып аңлашыла. Поэма тукымасына кертелгән карт белән киңәш сораучы турындагы хикәят тә шушы катламга карый һәм җәмгыятьтәге халәткә бәя булып яңгырый. Яшь буынның олы буын каршындагы җавапсызлыгы тискәре сыйфат буларак бәяләнеп кенә калмый, җәмгыятьнең бәхетсезлеге әнә шуңа тоташа дигән фикерне дә ныгыта. Җәмгыятьтәге әхлакый, сәяси торыш, милләт фаҗигасе хиснең сәбәбенә әйләнеп, лирик герой тойгысы борчылу аша әрнү, сызлануга кадәр үстерелә.

Поэмадагы ике: милли-сәяси һәм фәлсәфи катламнарны тоташтыручы, чорларга бәя бирү өчен дә, фәлсәфәне, әхлакый яңгырашны тирәнәйтү өчен дә отышлы сайланган Хозер Ильяс образы Аклык, Сафлык, Мәрхәмәтлелек үрнәге, ягъни архетип буларак кабул ителә. “Аллаһ бүләге” шигыренә исә ул тормыш авырлыкларыннан сыгылган лирик геройны юатучы, аңа яхшылык теләүче ярдәмче карт сыйфатында килеп керә. Аның яшәешен бәян итүче Ак әби дә - шундый типларның берсе, корбанчылык, аклык, сафлыкны

гәүдәләндергән Акъәбиләр архетибының дәвамы булып тора. Хозер Ильяс белән янәшә дүрт символик образ килә: гөл-чәчәк, камчы, сал һәм учак. Гөл-чәчәк –Хозер Ильясның дәвамы - аның күңел, яшәеш матурлыгы билгесе. Икенчедән, аңа йөкләнгән тагын бер вазифа шагыйранә дөньяны шартлы икегә - Хозер Ильяслы үткәнгә һәм "имансыз, денсез" бүгенгегә бүлүдән гыйбарәт. Ак чәчәккә әверелүе Хозер Ильясның Җир-анадан аерылмаган зат, табигать баласы булуын да аңлата кебек. Табигать баласы булган бүгенгеләр исә - аңардан ераклашып, сукырларча идеологиягә табынучылар. Бу бәйләнеш аяусыз хәл-халәт табигый башлангычтан аерылу белән дә бәйле дигән фәлсәфәгә китерә. Сал – иминлек, муллык, рухи байлык билгесе, Хозер Ильяс кабызган учак, ут – иман ныклыгы, иман нуры, намус байлыгы, алай гына да түгел, кешелеккә рухи кыйбла, маяк символы да. Сугышлар, явызлык билгесе булып йөргән камчы образы да биредә башкачарак мәгънә төсмере белән баетыла: яхшылыкка башлангыч, фатиха кебек аңлашыла.

Хозер Ильяс яшәеше – яшәү үрнәге булып тора, ягъни автор чынбарлыкны әнә шулай үзгәртергә тели, романтик әсәрләргә хас булганча, аны үз хыялы, идеалы яктылыгында бәяләргә омтыла. Дини-мифологик образ белән бәйләнгән фәлсәфи катлам автор фикерен, идеясен үткәрә: кеше бу җиргә бары бер мәртәбә җибәрелә, ә ул тормыш исә иман, намус, вөҗдан берлеге белән бизәлергә, "Хозер Ильяс биеклегенә" омтылырга тиеш. Бу фәлсәфәне аңлауга поэмага эпиграф итеп китерелгән "Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам әйтте: бу тормыш – бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан" гыйбарәсе дә ачкыч булып тора.

Әсәр тукымасында Хозер Ильяс күзләргә сеңгән изгелек булып һәр кеше күңелендә дәвамын эзли, ягъни кешеләр күңелендәге иман, изгелек чаткыларының яктысы булып та төгәлләшә. Аның юкка чыгуы – аерым кешеләр җанындагы иман нурының югалуы, имансызлык, рухи салкынлыкның өскә чыгуы да ул. Әнә шулай Хозер Ильясның югалуы хиснең икенче сәбәбе булып тора. Иман һәм имансызлык, изгелек һәм явызлык каршылыгы аша Зиннур Мансуров җәмгыятьтә генә түгел, ә һәр кешедә барган күңел тартышын

ачып бирүгә ирешә. Ялгыш юлдан киткән кешелекне иманга кайтару аша савыктырырга ниятли һәм фикерен Хозер Ильяс образы, аңа салынган мәгънә аша җиткерә. Әсәр тукымасына шома кертеп урнаштырылгын салаватлар, аерым дини гыйбарәләр, хикәятләр дә шуңа хезмәт итә.

Поэмада урын алган фикерләр аерым шигырьләрдә дә дәвам иттерелә, үстерелә. Мәсәлән, “Исерек бал кортлары”, “Дәһрилек”, “Тагын “урыснык” турында” шигырьләре әхлаксызлык өчен сызлану төсендә язылса, “Ромашкино ромашкасы”, “Кайтавазсыз урманда”, “Ятим су анасы”, “Меңъяфрак” әсәрләре лирик геройның табигать үлә баруы, кешелекнең аңардан аерылуы нәтиҗәсендә туган кичерешләрен ачып бирә.

“Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар” поэма-руладасы әхлакый бөтенлек, бөеклекне үткәннән эзли. Шагыйрь һәм сугышчы-офицер шәхесенә багышлап иҗат ителгән поэманың бер яңалыгы булып шәхси көндәлекләрне әдәби әйләнешкә кертеп, үзара мәгънәви бәйләнгән өзекләрне авторның шәхси уйланулары белән бер үремтәдә бирү тора. Сугыш көндәлекләреннән алынган юллар төп шигъри текст белән бәйләнеп, һәр бүлекнең мәгънәви юнәлешен ачыклый. Поэма чикләрендә төрле стиль һәм жанрларның берлеге, интертекстуальлек алымы иҗтимагый, әдәби, фәлсәфи катламнарны барлыкка китерә.

Иҗтимагый уйланулар сугыш чоры вакыйгаларын – окоп сугышларын, Журовкага бару күренешләрен яңарта һәм эпик башлангычны тәшкил итә. Бу өлештә китерелгән Бакчасарай шәһәрен саткан этәч турындагы хикәят метафора хезмәтендә үз иленә тугрылык, сату-сатылу мәсьәләләрен күтәрә. Ватан сугышында кичерелгән вакыйгаларны җанландыру аша фаҗигалелек көчәйтелә, аерым образ, әдәби детальләр, хәтта төсләр дә шул максатка хезмәт итә. Мәсәлән, кара төс сугыш фаҗигасенә, үлемнең ямьсезлегенә һәм якынлыгына, язмышның котылгысызлыгына ишарә тудыра. Шулай да поэмада сугыш вакыйгаларын тасвирлау беренчел урында тормый, ә Мөҗәйнең эчке дөньясын, рухи кичерешләрен, әхлакый үсеш юлын чагылдыру үзәккә алына.

Шагыйрьлек бурычы, аның халык тормышындагы урыны, вазифасы кебек мәсьәләләр әдәби катламның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шагыйрьлек бурычы үз халкың азатлыгы өчен көрәштә дип билгеләнеп, милли көрәшче идеалы саналган Тукай бизмәне белән үлчәнә. Кол Гали, Шиһап Мәрҗәни, Каюм Насыйри кебек шәхесләрнең әсәр тукымасына кертелүе ике катлам, хәтта капма-каршы мәгънә үткәрә. Тарихи шәхесләрнең рәсемнәре дә калмау бер яктан эчке фаҗигане күрсәтсә, икенче яктан, рәсемсез дә үз эшләре белән халык хәтерендә мәңгеләшүләрен раслый.

Поэмада үлем һәм үлемсезлек, вакыт агышы, тән һәм җан сафлыгы турындагы уйланулар фәлсәфи катлам турында хәбәр итә. Әсәрнең идеясе дә шул катлам белән бәйләнештә үткәрелә. Кеше – язмыш, үлем – үлемсезлек каршылыклары яшәүнең мәгънәсе, зурлыгы турындагы идеягә алып килә. Гомер агышын шагыйрь руладага тиңли. Эпиграфта күрсәтелгәнчә, рулада – җырның бик тиз башкарыла торган өлеше. Аның эчке мәгънәсе гомер - әнә шулай бик тиз үтә торган язмыш бүләге, аны һәркем максатчан, мәгънәле үткәрергә, миссиясен үтәргә тиеш дигән фикергә китерә. Х.Мөҗәйнең гомере, бигрәк тә сугыш чорындагы кебек соң чиккәчә кысылганы, халкының үлемсезлеге, Ватан азатлыгы өчен көрәш белән аклана. Җан сафлыгы да шуңа бәйләп аңлатыла.

Үлем-үлемсезлек, яшәү-үлем каршылыгы, үлемнең үлемсезлеккә әйләнү концепциясе үлемсезлек фәлсәфәсен җиткерә. Поэмада фәлсәфә сугыш чоры поэзиясендәгечә хәл ителә. Кырыгынчы-илленче еллар шигъриятендә яшәүнең төп максаты хакыйкать дип карала, ә хакыйкатьнең төп эчтәлеге ил азатлыгы өчен көрәш, илең өчен үлү белән бәйләнеп, бетү, югалу мәгънәләрендә йөргән үлем мәңгелек яшәешнең, ягъни үлемсезлекнең башлангыч ноктасы, үлгәннән соң яшәүгә юл алу буларак аңлана башлый. “Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар” поэма-руладасында да лирик геройның вакытсыз өзелгән кыска гомерен ил гомеренә кушарга теләве үлемсезлеккә омтылуы булып аңлашыла: “Минем үлемем – минем Ватаным, минем сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без: “Безгә үлем юк!” – дибез”.

Поэманың идеясе дә яшәү мәгънәсе, аның бөеклеге, зурлыгы илгә, Ватанга, үз халкыңа хезмәт итүдә, рухи азатлыкка омтылуда дигән фикер аша үткәрелә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. З.Мансуровның туксанынчы еллар иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?
2. Шагыйрьнең "Ике егълау" поэмасында нинди мотивлар урын ала?
3. Шагыйрьнең "Хозер Ильясны эзләү" поэмасы белән хәзерге татар поэзиясенә керткән яңалыгын аңлатыгыз.
4. Шагыйрьнең "Хозер Ильясны эзләү" поэмасында нинди мотивлар урын ала?

**Әдәбият исемлеге.**

1. Галиуллин Т. Шигърият офыклары / Т.Н.Галиуллин // Татар шигрияте: 1980-2000 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б.4-30.
2. Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.
3. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б.428-435
4. Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ "Си-пресс", 2012. – С.118-123.

## Тема 4. Р.Зәйдулла иҗаты (1962)

**Лекция 4**

**Аннотация.** Лекциядә Р.Зәйдулла иҗатына хас үзенчәлекләр ачыклана, модернистик поэзия үсешендә тоткан урыны билгеләнә.

**Ачкыч сүзләр:**поэзия, модерн алым, экспрессионизм.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак

бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Р.Зәйдулланың тормыш һәм иҗат биографиясе.
2. Шагыйрь иҗатында лирик герой: үзенчәлекләре, үсеш-үзгәреш үзенчәлеге.
3. Шагыйрь лирикасында мотивлар төрлелеге.
4. Р.Зәйдулланың проза, драматургия өлкәсендәге эшчәнлеге.

Р.Зәйдулла татар укучысына иң элек заман һәм җәмгыять, милләт һәм кешеләр турында усал итеп, әрнеп, ләкин аңларга тырышудан битәр, ачыктан-ачык гаепләп, маңгайга бәреп сөйләүче, гражданлык лирикасының көчлелеге белән аерылып торучы, образлылык ягыннан, бигрәк тә символлар белән яратып эш итүче шагыйрь буларак билгеле.

Шагыйрь, прозаик, драматург һәм публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Җәлил исемендәге Республика премиясе һәм Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Ркаил Зәйдулла (Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин) 1962 елның 23 гыйнварында Чувашстанның Комсомол районы Чичкап авылында дөньяга килә. Башлангыч мәктәпне – туган авылында, урта мәктәпне күршедәге Чурачык мәктәбендә авылында тәмамлый.

Әдипнең тәүге иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре республика матбугатында 1977 елда күренә башлый. Туфан Миңнуллин яшь шагыйрьнең әдәбият мәйданында беренче адымнарын болай бәяли: “Казан дәүләт университеты студенты Ркаил Зәйдулланың беренче дүрт шигыре басылып чыккан. Яратам мин бу малайның шигырьләрен, өметем зур ул егеткә. Мин аңарда иҗат кешеләренә иң кирәкле сыйфат – тынгысызлыкны күрәм”. Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким дә әдәбиятка өметле шагыйрь килүен әйтәләр. Әдәбият галиме Т.Галиуллин “Чувашстаннан килгән сәләтле егетнең шигырьләре татар поэзиясенең киләчәгенә өмет уята”, – дип белдерә.

Ркаил Зәйдулла Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетында укып белем алганнан соң, “Яшь ленинчы”, “Татарстан яшьләре” гәзитләрендә эшли, “Ялкын” журналының даими авторына әйләнә, соңрак “Идел” журналының баш мөхәррире булып тора.

“Таланты бик яшьли ачылып, шигърият мәйданына егерме яшендә үк яңа бер дулкын булып, аны яңа төсләр, рухи ярсулык белән баетып кергән” Р.Зәйдулла иҗаты – уйлы-фикерле, фәлсәфи-публицистик яңгырашлы иҗат. Шагыйрь тормыш үзгәрешләренә сизгер, бүгенгене халыкның, милләтнең тарихи үткәне белән тыгыз бәйләнештә, үзенең дөньяга карашын, уй-фикерләрен поэтик образларда риторикасыз, ихлас күңел кайнарлыгы белән гәүдәләндерергә омтыла. Шагыйрь Илдар Юзеевның да яшь каләмдәшенә бәясе югары: “Минемчә, шигъри иҗат үзеңнән алда яшәгән шагыйрьләргә булган ихтирамнан, мәхәббәттән башлана. Ркаил дә борынгы җырчылар – Кол Гали, Мөхәммәдъярларның каберләрен эзли, бүгенгегә, киләчәккә, аларның изге зиратлары аша карый”.

Шагыйрьнең “Кояшлы күзләр” (1984), “Күрәзә” (1988), “Урыс кышын озату” (1993), “Мәгарә” (2005), “Ташка ордым башны” һ.б. шигырь җыентыклары киң катлам укучы тарафыннан ике гасыр чигендә җәмгыять кичергән кискен үзгәреш шартларында барлыкка килгән хөр уй-фикер яңарышының татар поэзиясендәге уңышлы бер чагылышы итеп кабул ителә.

Ркаил Зәйдулла шигырьләрендә иҗтимагый күренешләр шагыйрьнең үз шәхси тормышы һәм кичерешләре җирлегендә тирән мәгънәле шигъри юлларда, тәэсирле һәм яңача сурәтләү чаралары ярдәмендә ачылалар. “Урыс кышын озату” җыентыгында ул тормышка мөнәсәбәтен аныклаган, җитлеккән шагыйрь буларак яыгыш ясый. Табигате белән мәйдан шагыйре, кызу канлы, ярсуР.Зәйдулла поэзиясендә экспрессионистик алымнардан лирик геройның тышкы тирәлек белән каршылыкка керүе, тормышны караңгы буяуларда сурәтләү, тормышка аңлаешсыз, дошмани бәя бирү, хисләр киеренкелеге, лирик геройның күнегелгән тәртипләргә, сәясәткә, “үле” мәдәни хәл-халәткә, идеологиягә каршы чыгу сыйфатлары күзәтелә.

Р.Зәйдулланың гражданлык лирикасында әдип иҗатын үтәли сызучы төп мотив – *милләт фаҗигасе,милләтнең киләчәге өчен борчылумотивы* символик образ, детальләр ярдәмендә көчәйтелә. Автор фәлсәфи кыйммәт төсендә Вакыт, Тарих, Хәтер образларын милләт хәленә, татарның бүгенге яшәешенә бәя бирү өчен символлаштыра. Өметсезлек, чарасызлык кебек экзистенциаль тойгылар да милләтнең фаҗигасе якынлашу белән янәшә бирелә (“Карап торам бүген Казаныма...”, “Халкым минем төнгә кереп китә...”). Әдипнең гражданлык лирикасында милли фаҗигане туктата алмауга бәйле чарасызлык, гаҗизлек тойгысы да телсез, динсез милли ватанда калу куркынычы турындагы фикерне көчәйтү өчен хезмәт итә (“Халкым минем төнгә кереп китә...”). Р.Зәйдулла сарказм алымы белән милли үзаңны тергезүнең, милли яшәешне җанландыруның мөмкин түгеллеген дәлилли (“Урыс кышын озату”). *Милләтнең киләчәге өчен борчылу* милли идеал Тукай образын җанландырган “Йокысызлык” шигырендә аеруча ярсу яңгыратыла.Тукайны идеаллаштырган “Кавышу” шигырендә экспрессионистик алымнар ярдәмендә үлемсезлеккә ирешү белән гомерне милләткә хезмәт итүгә багышлау фикере янәшә куела.

Р.Зәйдулла поэзиясенең йөзен билгеләүче төп фәлсәфи мотив – хакыйкать мотивы “Шагыйрьләрнең каберләрен эзлим” шигырендә көчле яңгыраш ала. Әдипнең фәлсәфи лирикасында яшәү кадере хакында уйланулар яшәү мәгънәсе, тормышның чиклелеге, үлемнең котылгысызлыгы хакында уйланып сызлану(“Зиярәт”) белән көчәйтелә. Р.Зәйдулла коллык фәлсәфәсен тормыш авырлыгы, язмышның зурлыгы ярдәмендәачып сала (“Таш турында риваять”); яшәү мәгънәсен иҗат мотивы(“Йокысызлык”), кешенең үз асылын тану, табу мотивы(“Ташларгамы җанны чиксезлеккә...”) чагылдырып килә. Яшәү-үлем фәлсәфәсе дә тормышның чиклелеге, үлемнең котылгысызлыгына(“Җир әйләнә...”), газаплы тормышны үзгәртергә омтылуга (“Таш турында риваять”), яшәешнең мәгънәсе җуелуга (“Киләчәккә хат”) бәйле аңлатыла. Тормышның өзлексез агышында үзгәрмәс кыйммәтләр барлыгы турындагы фикерне әдип Вакыт, Язмыш образлары ярдәмендә көчәйтә (“Күз

яше”).Дөньяга ачулану, ләгънәт уку мотивында еш кына шәхси кичерешләр нигезли, лирик герой язмышына да ачулы була белә (“Хәсрәт”).

Р.Зәйдулланың күңел лирикасында мәхәббәт, үкенеч, өмет мотивларына еш мөрәҗәгать ителә, өмет, үкенеч, ялгызлык мотивлары яшәеш турында уйлануларны фәлсәфи дулкынга көйли. Үкенеч(“Төсләр”), бәхет(“Төнге рәсем”) мотивларыфәлсәфи уйлануларны романтик төсмер белән баета. Мәхәббәт хакында сөйләшкәндә әдипнең лирик герое моңсу, сагышлы, мондый очракта үкенеч мотивы(“Барча шигыремне сиңа багышлыйм бүген...”, “Назлы сүзләрне тыңларга...”) калкытыла. Ләкин, ни генә булмасын, ярата белмәгәннәр битараф, уйсыз-гамьсез; рухи үлемгә дучар ителгәнлек фикере дә күңел лирикасы кысаларында җиткерелә (“Үтенеч”).

Р.Зәйдулла проза өлкәсендә дә уңышлы каләм сыный, тарихи хикәяләре, балалар өчен язылган әсәрләре дә матбугат битләрендә еш дөнья күрә. Р.Зәйдулла прозасы символизм агымын тергезүе белән үзенчәлекле. Күренекле шагыйрь М.Әгъләмов “кызыклы шигырьләр, поэма белән килгән, һәйбәт шагыйрь булып җиткән Р.Зәйдулланың прозага күчүен” үзенчәлекле бәяли: “Әйбәт чәчмә әсәр – “Ил” китабын язды, бу проза гына түгел, шигъри чәчмә дә”.

Г.Камал исемендәге театр сәхнәсендә 2001 елда драматург Р.Зәйдулланың җәмгыятьтә бара торган процессларның яшь буынга тәэсир итүен, идеаллар югала баруын психологик планда тасвирлаган “Саташкан сандугач” пьесасы, 2011 елда данлыклы Буби мәдрәсәсе тарихы сәхифәсеннән беренче татар казыясы, мөгаллимә Мөхлисә Буби язмышын гәүдәләндергән “Үлеп яратты” драмасы уңыш казана.

Әдипнең шигърияте һәм драматургиясе чуваш теленә дә тәрҗемә ителә. “Саташкан сандугач” пьесасы, “Күпер» поэмасы, аерым шигырьләре белән белән чуваш укучысы да таныша ала.

Р.Зәйдулла – үткен каләмле, туры сүзле публицист. Татар милләтенең тарихи язмышы һәм бүгенге хәле, дин, тел, мәдәният, милләт алдына килеп баскан башка күп төрле мәсьәләләр аның игътибарын һәрвакыт җәлеп итә, ул

аларның берсенә дә битараф түгел, матбугат аша аларга үзенең мөнәсәбәтен белдереп килә.

Шул рәвешле, Р.Зәйдулла шигърияте – киң колачлы иҗат. Аны яңа гасыр татар поэзиясенең гыйсъянчы шагыйре дип тә, фәлсәфи лириканы яңа баскычка күтәрүче әдип дип тә бәяләп булыр иде.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Р.Зәйдулла поэзиясе ни рәвешле үсеш-үзгәреш кичерә?
2. Шагыйрь шигъриятендә нинди мотивлар аерылып чыга?
3. Р.Зәйдулла поэзиясендә лирик геройга нинди үзенчәлекләр хас, ул нинди үзгәреш кичерә?
4. Шагыйрь иҗатының йөзен билгеләүче төп сыйфатларны, стиль тенденцияләрен билгеләгез.

**Әдәбият исемлеге.**


1. Галиуллин Т.Н. Яктылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Т. Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – 319 б.
2. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык) / Д. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
3. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т.2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.
4. Йосыпова Н.М. Соңгы еллар татар поэзиясе / Н.М.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 428-436
5. Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар / Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан ун.-ты, 2011. – 120 б.


## Тема 5. Хәзерге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре

**Лекция 5**

**Аннотация.**Хәзерге татар драматургиясенең үсеш-үзгәреш юллары турында мәгълүмат бирелә, төп үсештенденцияләре ачыклана. Хәзерге татар

драматургиясендә реализм, романтизм иҗат юнәлешләре белән янәшәдә модерн агымнар, стиль тенденцияләре ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:**драматургия, стиль тенденцияләре, жанр.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Хәзерге татар драматургиясендә иҗат юнәлешләренең, агымнарның төрлелеге.
2. Соңгы еллар сәхнә әдәбиятында тематик-проблематик төрлелек.
3. Хәзерге татар драматургиясендә жанр һәм жанрформалары.
4. Хәзерге татар драматургиясендә образлар төрлелеге һәм яңалыгы.
5. Соңгы еллар сәхнә әдәбиятында мифны кабатлау (мифологизация) һәм “мифны җимерү” (демифологизация) алымнарының чагылышы.

Хәзерге татар драматургиясе берничә яссылыкта үсә-үзгәрә:

1) ***иҗат юнәлешләренең, агымнарның төрлелеге:***

Беренчедән, соңгы еллар драматургиясендәге **реалистик юнәлеш** яңа алымнарга, психологизмга, тематик төрлелеккә омтылуы белән үзенчәлекле.

Бу юнәлештәге бер төркем әсәрләрне тематик-проблематик яссылыкта *милли тема* берләштерә, аларда җәмгыятьтәге үзгәрешләргә җавап төсендә милләт язмышы, милли менталитет, гореф-гадәтләрнең сакланышы, катнаш никахлар һ.б. проблемалар калкытып куела. Шушы ук темага совет системасын фаш итү дә кушылып китә, аерым алганда идеологиянең кешене шәхес буларак таркатуда уйнаган ролен (дин әһелләрен һәм диннең үзен юк итәргә тырышу; милләтләргә карата алып барылган сәясәт; халыкларның гореф-гадәтләрен санга сукмау; эчкечелек, әләкчелекне яшәү нормасына әверелдерү

фаҗигаләренә[1]) игътибар итеlә башлый. Мәсәлән, И.Юзеевның "Ак калфагым төшердем кулдан", Т.Миңнуллинның "Шәҗәрә", "Йөрәк маем" драмалары шушы темага мөрәҗәгать итеп язылганнар.

Икенче бер төркем реалистик әсәрләрне *тарихи тема* берләштерә. Илдәге үзгәрешләр моңарчы бозып язылган тарихны төзәтергә мөмкинлек бирә, мөстәкыйльлек белән бергә сүз ирекегә кайтарыла. Тарихи шәхесләрнең күркәм образларын, милли азатлык өчен көрәш сәхифәләрен яктыртуга багышланган әсәрләр дөнья күрә. Р.Хәмиднең "Хан кызы", Р.Зәйдулланың "Хан һәм шагыйрь", Р.Батулланың "Сират күпере", "Җимерелгән бәхет", Ф.Бәйрәмованың "Атылган йолдыз" кебек фәлсәфи фикерләргә бай әсәрләрдә тарихи вакыйга-күренешләрне сурәтләү аша хәзерге заманның актуаль проблемаларына бәя бирү омтылышы алга чыга.

Милли һәм тарихи темалар белән беррәттән хәзерге драматургиянең реалистик юнәлеше *сугыш темасын* да яктырта. Әфган, чечен сугышлары Ю.Сафиуллинның "Йөзек һәм хәнҗәр", И.Мәхмүтованың "Син бит минем бергенәм", Р.Батулланың "Кояш баеганда", Т.Миңнуллинның "Эзләдем, бәгърем, сине" пьесаларында бөтен ил фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәрелеп сурәтләнә.

Икенчедән, соңгы елларда иҗат ителгән **романтик** әсәрләр кеше шәхесен, аның рухи камиллеген, яшәү мәгънәсен, бәхет, буыннар арасындагы рухи бәйләнешләрне сурәтли, әхлакый-фәлсәфи уйлануларны җиткерә. Мондый әсәрләрдә фәлсәфилекнең, психологизмның аеруча көчле булуы күзгә ташлана.

Шушы ук юнәлештә әхлакый кыйммәтләрнең кимүе, эчкечелек, матди байлыкка омтылыш кебек проблемаларны күтәргән Ф.Яруллинның "Бер көрешү – үзе бер гомер", "Кызларның кызганнары", И.Юзеевның "Эзләдем, таптым, югалттым", Г.Каюмовның "Сагынырсың әле син дә бер", И.Зәйниевның "Суган чәчәге" кебек пьесаларында романтик алымнар белән янәшәдә гротеск, ирония, сүз уйнату алымнары да кулланыла.

[1] Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр. Казан, 2007. Б.196.

Соңгы елларда иҗат ителгән бер төркем драма әсәрләрен **“яңа дулкында”** иҗат ителгән пьесалар билгели. Спектакльнең тәэсир итү көчен, эффектын арттыруга юнәлтелгән элементлар яисә төп идеяне реалистик булмаган вакыйгалар аша бирү омтылышы, җәмгыять һәм кеше арасындагы каршылыкның гаять киеренкеләнүен төрле төсмерләрдә, театр элементлары һәм метафоралар аша сурәтләүнең матур мисаллары дөнья күрде. Асылда алар, Аурупа һәм рус сәхнә әдәбиятында **“явызлык театры”**( Д.Салихов “Алла каргаган йорт”, З.Хәким “Кишер басуы”, Ф.Бәйрәмова “Вакыйга җүләрләр йортында бара”), **“көлке театры” (**Аманулла “Әлепле артистлар”, “Кылый Кирам балдагы”, З.Хәким “Мин төш күрдем”, Д.Салихов “Пуля”**)**, **“абсурд театры”** (М.Гыйләҗев “Баскетболист”, И.Зәйниев “Мәхәббәт FM”) дип аталган формаларга туры килеп, хәзерге татар драматургиясендә модернизмның мәйданга чыгуын күрсәтә.

Мәсәлән, З.Хәкимнең “Кишер басуы” драмасында мифологик катлам көчле. Әсәрнең нигезендә оча торган тәлинкәләр хакындагы миф ята һәм вакыйгалар шул нокта тирәсенә җыела. Ирония һәм гротеск алымнары ярдәмендә бүгенге авыл тормышы тәнкыйтьләнә, эчкечелек, эгоистлык, караклык һ.б. сыйфатлар билгеләнә һәм алар бөтен җәмгыятькә хас сыйфатлар булып гомумиләшә, Җир пространствосы аша иҗтимагый, сәяси бәянең калкулануы күзәтелә. Күк тормышын автор идеаль, үрнәк тормыш моделе кебек тәкъдим итә.

Ике пространство арасында торучы образ – Галия образы. Автор аны Күк һәм Җирне бәйләүче персонаж буларак кертә, Җирнең киләчәге шундый яшьләр кулында икәнлегенә өмет итә. *“Их, Фәрит, очарга иде синең белән бергәләп Галәмнәргә, ерак йолдызларга!...Син шул тракторның астыннан чыкмассың инде. Бу Җирдә миңа тынчу була башлады, Фәрит. Ерак планеталардаискиткеч гүзәл кешеләр яшидер кебек...Анда бөек мәхәббәт хөкем сөрәдер...”* репликасы Галиянең эчке дөньясын ача. Әсәрдә очу мотивы Галия һәм Фәриткә бәйле еш кабатлана. Автор бу мотив нигезенә яшәү, тормыш итү

мәгънәсен сала. Бу образлар арасындагы сызык идеаль мәхәббәт турындагы хыялны барлыкка китерә.

Зөлфәт Хәким хыял ярдәмендә чит ил планетасында яшәүче Сергач мишәрләрен Җирдә яшәүче татарлар белән очраштыра. Притон планетасы кешеләренең нәкъ менә кишер басуына төшүе автор  тарафыннан махсус уйланылган кебек. “Кишер басуы” – татарлар яши торган җәмгыять (Алсу Саттарова аны “дәүләт символы буларак кабул итә), ә кораб – “халыкның өмете, ышанычы, якты киләчәге, бердәм, тату булып яшәве, үз дәүләте өчен хезмәт итүе” кебек формалаша. Автор икенче кунак мисалында Җирнең сазлык икәнен янәдән бер кат раслап куя. Атна-ун көчендә Притон планетасыннан килгән кешенең Садри, Зәкиләр юлына төшүе, хатын-кызлар белән чуалуы моңа ачык мисал.

З.Хәкимнең “Шайтан куентыгы” (1999) трагедиясендә дә вакыйгалар XX гасыр ахырында татар авылында бара. Зөлфәт Хәкимнең әлеге әсәрендә дә ике дөнья ачык чагыла: мифик һәм реаль. Мифологик һәм реалистик катламнар бер-берсе белән параллель рәвештә бара. Реаль тормышта – авыл, Фәнзилә һәм Разим мөнәсәбәтләре, аларның әниләре, мифик тормышта Фәнзиләнең күңеленә оялаган Илгиз-Шайтан, Рамизның күңелендәге Илгизә-Шайтан урын ала.

Илгиз һәм Илгизәярыммифик, ярымреаль образлар кебек кабул ителә. Шайтан образы кеше күңелендәге кара яклар, явызлык символы буларак күтәрелә. Мифологик персонаж буларак ислам мифологиясеннән килгән үзенчәлекләрне туплаган. Автор әсәрдә явызлык һәм яхшылык көрәшен сурәтли. Разим һәм Фәнзилә тормышындагы яхшы һәм якты як – аларның сабый чактан бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре, уй-хыяллары. Моннан чыгып, Разим белән Фәнзиләнең  күңелләрендә әйбәт һәм начар башлангычларның көрәше, ягъни геройларның ике ягы («двуединая сущность») турында  сүз алып барырга мөмкин. Әсәрдә күңелләрендә ике башлангыч көрәше барган геройлар тагын бар. Ахырда төп геройларның әтиләре дә шул ук көрәш корбаннары булуы ачыклана. Драматург алар аша коллектив, җәмгыять турында сөйли, хәзерге җәмгыятьне байлык артыннан куу, эчкечелек, милли гореф-гадәтләрне,

әхлак кыйммәтләрен сакламау акылдан яздыра, үлемгә алып бара дигән идея белдерелә.

Зөлфәт Хәким пьеса дәвамында алтын балык турындагы мифны уйната. Алтын балык биредә өмет-хыяллар, якты киләчәк мотивы буларак кабул ителә.Пьеса дәвамында Фәнзилә өчен алтын балык элекеге мәгънәсен югалта. Аны тормыштагы башка төрле кыйммәтләр борчый, “шайтан куентыгы” – серле, ялтыравыклы тормыш каршылыклары үзенә тартып ала.

Әсәр ахырында да автор әсәр башындагы эпизодны кабатлый. Гүя үлем ике парны дөреслек, яктылык, аклык, хыяллар юлына алып чыга, гүя Фәнзилә белән Разим балачактагы сафлыкларына әйләнеп кайта. Әсәрдәге елга образы тормыш мәгънәсендә килә. Автор моны трагедиянең иң башында бирелгән җыр тексты мисалында раслый.

Елгадагы  Шайтан куентыгы – кешеләрне үз чоңгылына тарта торган тормышның ямьсез яклары. Бу – хәзерге заманның чиренә әверелгән эчкечелек, эти-әниләрнең барлыгын оныту, байлыкка омтылу, алай гына  да түгел, яшәүнең мәгънәсен шушы кыйммәтләр белән бутап ялгышу.

Зөлфәт Хәким җирлеккә бәйле “Шайтан куетыгы” турындагы риваятьне отышлы файдалана. Шайтан куентыгында кычкырып сөйләшергә, шайтан исемен телгә алырга ярамый. Кем дә кем әлеге кануннарга буйсынмый аңа шайтан ияләшә һәм ахыры үлем белән тәмамлана. Автор бу сюжетны әсәрнең нигезенә утыртып, вакыйгаларны ышандырырлык итеп тезә.

Кешенең аң төпкелендә төрле башлангычлар көрәшен сурәтләү әсәрнең үзәгендә тора. Әсәрдә вакыйгалар сайланышы шартлы булып, шайтан образы, кешенең галлюцинацияләр кичерү, саташу вакытын сурәтләү, алмашыну мизгелләрендә ике башлангычның тартышын күрсәтү драматургның аң төпкелендәге хәлләрне сурәтләү объекты итеп алуы хакында сөйли. Аң төпкелендә байлык һәм мәхәббәт тартыша. Эчкечелек һәм әхлаклылык каршылыгы геройлар (әтиләр, Разим) мисалында ачыклана. Моннан тыш, заман шаукымы һәм милли гореф-гадәтләр каршылыгы бар. Разимның әнисе болай ди: «*Нинди заманнар китте бит, ә. Никахсыз-нисез яши башлыйлар, ризалык*

*та, хәер-фатиха да кирәк түгел...*». Ягъни бу тартыш – шулай ук бәхетсезлеккә китерә торган бер сәбәп.

Шулай итеп, Зөлфәт Хәкимнең “Шайтан куентыгы” трагедиясе, мифологик образ, сюжетларга мөрәҗәгать итү аша укучыга мәхәббәт темасын гаять үзенчәлекле, традицион булмаган рәвештә укучысына тапшыра, заманга хас проблемаларны яктыртуга ирешә.

**2) тематик-проблематик төрлелек:**

Хәзерге татар драматургиясендә җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә милли үзаң үсү, дәүләтчелекне торгызу идеясенең киң яклау табуы *милли тематиканың* киң чагылуына китерә. Шуның белән янәшәдә драматургиядә *совет тәртипләрен фаш итү* җанлана, шактый ук тирәнәя. Иң беренчедән, 70 ел хакимлек иткән идеологиянең кешене шәхес буларак таркатуда уйнаган роленә игътибар ителә. Шулай ук *басып алу сугышлары алып баруны яклау*, милләтләрне кимсетүгә һәм юкка чыгаруга йөз тоту, хаклыкларның гасырлар дәвамында сыналган милли гореф-гадәтләрнең санга сугылмавы, туган телнең милли тормышта үз урынын саклый алмавы, эшләмәскә өйрәнү, халыкның иң күркәм сыйфатларыннан берсе булган хезмәт сөюне югалту, аерым кешеләргә генә түгел, ә тулаем халыкларның киләчәгенә яный торган аракыфаҗигаләре һ.б. тәнкыйтьләнә. Хәзерге катлаулы, каршылыклы тормышта үз-үзеңне ничек табарга? Әхлакый традицияләрне заман үзгәрешләре белән ничек яраштырырга? Рухи һәм матди байлыкның үзара мөнәсәбәте нинди булырга тиеш? Ахыр чиктә бәхет нәрсәдә, аңа ничек ирешергә?” кебек сораулар үзәккә куела.

Шулай итеп, хәзерге татар драматургиясендә түбәндәге тематик-проблематик төркемнәрне төгәлләштерергә мөмкин:

1) милләт язмышының милли менталитет, яшәү рәвеше, гореф-гадәтләр сакланышы, катнаш никахлар һ.б. мәсьәләләр белән бәйләп каралуы[2] (***Т.Миңнуллин.*** Илгизәр+Вера; ***Р.Хәмид***. Ак тамырлар иле);

[2] Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. Казан: Мәгариф, 2004. Б.228.

2) татар халкы тарихы ***Р.Зәйдулла.*** Хан һәм шагыйрь(2001), “Үлеп яратты” (2011); ***Н.Фәттах.*** Сармат кызы Сәринә(2002);

3) яшь буынның олы тормышка килүе, үз-үзен табуы, буыннар арасындагы рухи бәйләнеш, ана-бала мөнәсәбәте (***Т.Миңнуллин*** “Төш”(2010);

4) әхлакый кыйммәтләр үзгәрү, рухи кыйбланы югалту (***Ф.Бәйрәмова***“Аллалар каргышы”);

5) татар авылларының язмышы (***М.Гыйләҗев***“Баскетболист”);

6) кеше шәхесе, аның рухи һәм физик камиллеге, яшәү мәгънәсе, бәхет төшенчәләре турында әхлакый-фәлсәфи уйлану (***Т.Миңнуллин***“Эзләдем, бәгърем, сине”);

7) әфган-чечен сугышлары нәтиҗәсе (***И.Мәхмүтова*** “Син бит минем бер генәм”, ***Ю.Сафиуллин*** “Йөзек һәм хәнҗәр”(1998)).

**3) Жанр һәм жанр-формалары:**

- **драма**(*Р.Хәмид*“Көзнең соңгы яфраклары”; *Д.Салихов* “Узып барышлый”,“Туй күлмәгем – соңгы бүләгем”; *Аманулла*“Әле кичә генә яз иде”, *Т.Миңнуллин* “Төш”);

- **иҗтимагый драма** (*Ф.Бәйрәмова*“Безне онытмагыз”);

- **публицистик драма** (*Р.Мингалим*“Дүрт кешелек утыргыч”);

- **психологик драма** (*Т.Миңнуллин*“Эзләдем, бәгърем, сине”);

- **мелодрама** (*Р.Сәгъди*“Сынган беләзек”; *И.Мәхмүтова*“Син бит минем бер генәм”);

- **фаҗигале драма** (*Т.Миңнуллин* “Мулла”);

- **трагедия** (*Д.Салихов*“Чукрак”; *Ю.Сафиуллин* “Йөзек һәм хәнҗәр”; *И.Юзеев*“Бәгырь”);

- **трагедия-реквием** (*Р.Хәмид*“Ак тамырлар иле”);

- **трагифарс** (*Г.Каюмов*“Мирас”,“Упкын өстендә уен”);

- **лирик комедия** (*Т.Миңнуллин*“Йөрәк маем”);

- **сатирик комедия** (*Д.Салихов*“Капчыктагы Мәгъфия”,“Пуля”; *З.Хәким*“Мин төш күрдем”);

- **музыкаль комедия** (*Г.Каюмов*“Һинд кызы”; Д.Салихов“Хатын түгел, аждаһа”);

- **иҗтимагый комедия** (*З.Хәким*“Килә ява, килә ява”,“Чапты атым Казанга”; *И.Юзеев*“Безнең әти мировой”);

- **көнкүреш комедиясе** (*Ф.Яруллин*“Бер күрешү – үзе бер гомер”);

- **водевиль** (*Р.Вәлиев*“Әй машина, машина...”);

- **балалар өчен пьесалар** (*Р.Сәгъди* “Гүзәл Аппаксылу”)

**4) образлар төрлелеге һәм яңалыгы:**

Хәзерге сәхнә әдәбиятының күренекле вәкилләре И.Юзеев, Т.Миңнуллин, Р.Хәмид, Ю.Сафиуллин, Р.Батулла, М.Гыйләҗев, Д.Салихов, И.Зәйниев һ.б. иҗатларында мифологик, символик образлар күп кулланыла, төп фикерне җиткерү барышында алар нәкъ менә мифологик образ, символ-метафораларга бик теләп мөрәҗәгать итәләр. Әдәбият мәйданында метафора-символларның ике төрле аспектта кулланылышы күзәтелә:

1) әсәрнең төп эчтәлеге әлеге образлар аша белдерелгән вакыйга-күренешләрдә ачыла;

2) символ, метафоралар ярдәмендә әсәрдә күтәрелгән проблемалар, аерым геройларның эш-гамәлләре, характер-сыйфатлары тулылана, ачыклана.

Хәзерге татар драматургиясендә мондый образларның икенче мәгънәдә, ягъни вакыйгалар һәм алардан чыккан нәтиҗәне тулыландыручы буларак кулланылышы алга чыга. Мәсәлән, Ю.Сафиуллиның “Нигез тудыручылар”, “Йөзек һәм хәнҗәр”, Р.Батулланың “Сират күпере”, И.Юзеевның “Ак калфагым төшердем кулдан...”, М.Гыйләҗевнең “Баскетболист”, “Бичура”, Зөлфәт Хәкимнең “Су төбендә сөйгәнем” һ.б. пьесаларда күрәбез.

Хәзерге драматургиядә төп герой бирелеше дә үзенчәлекле, Алсу Саттарова билгеләгәнчә, хәзерге татар драматургиясендә герой төрле яклып сурәтләнә һәм маргинал, фаҗигале шәхес, “урталыктагы кеше”, маңкорт, максималист һ.б. буларак алга килеп баса.

5) **мифны кабатлау (мифологизация) һәм “мифны җимерү” (демифологизация) алымнарының чагылышы:**

Бу алым, нигездә, мифологик материалга мөрәҗәгать иткән әсәрләрдә урын ала. Билгеле булганча, нигезендә миф яткан әсәрләр, гадәттә, ике вазифа башкара: яки яңа миф тудыра (мифлаштыру), яки яшәп килүче мифны юкка чыгара (мифны җимерү). Мәсәлән, Зөлфәт Хәкимнең “Су төбендә сөйгәнем” комедиясендә мифны җимерү күренеше белән очрашабыз. Вакыйгалар катламы Г.Тукайның “Су анасы” поэмасына цитация итеп сайланган һәм әсәрдә төп вакыйгаларның сәбәбе дә шушы поэма тексты булып чыга. Имеш, балыкчылар Гаделша һәм Мәрдәнша Су анасын күрәләр, Мәрдәнша аңа гашыйк була һәм, авылга китерер өчен, Тукай поэмасындагыча, алтын тарагын урлыйлар. Караклыкта гаепләнеп судта йөрүләр, аннан котылу, таракны прокуратурадан алдап алу, суга ташлау, аның яңадан табылуы һ.б. шундый вакыйгалар, бер яктан, мифологик материалны үзенчәлекле файдалану булса, икенче яктан, авыл кешеләренең (җәмгыятьнең) буш, экияти эшләр белән мәшгульлеген ассызыклый. Авылдагы мәгънәсез тормышка каршы куелган бердәнбер матурлык та – Су анасы хакындагы хыял гына. Шул рәвешле, миф чынбарлыкның капма-каршысы төсендә килә, аны бәяләү хезмәтен үти.

Комедиянең үзәгендә җәмгыятькә тәнкыйди (сатирик, ироник, абсурд, гротеск) бәя ята. Вакыйгалар уртасында кайнаган участковыйның малга табынучы, алдакчы, мәкерле интриган икәнлеге ачыклана. Ул бөтен Җир шарының участковые булырга хыяллана. (*Мәгълүм ки, мине Аллаһе Тәгалә участковый итеп яраткан. Белеп торыгыз: мин бөтен Җир шарының участковые булырга хыялланам. Җир шары минем участок булгач, иншалла, планетадагы бөтен тараклар минеке булачак.*) Совет системасындагы идарәчегә, җитәкчегә пародия, дөресрәге, симулякр булып килгән Миңлебаевтан язучы идеологиянең асылына күчә.

Әсәрдәге саңгырау Нуретдин образы, илдәге тәртипләрнең кешене хайван хәленә төшерүенә мисал булып килә. Җил кайсы якка иссә шул якка авып китүче әлеге персонаж тамак ялы өчен эшли һәм яши. Гаделша һәм Мәрданша – “хәзерге” авылларда көн итүче кешелекнең типиклаштырылган образлары,эчүчелеккә бирелеп, тормыш мәгънәсен югалткан, эшсезлектән

интегүче, буйдак тормышта яшәүче ир-атлар. Авторның комедиядә мифологизмга мөрәҗәгать итүе укучыга реаль тормышның никадәр ямьсез, мәгънәсез һәм күңелсез булуын раслау өчен файдаланыла. Укучыга төрлечә аңлау мөмкинлеге калдырып, Су анасы ярдәмендә мәгънә киңәйтелә. Авылда (илдә) гашыйк булырлык, авыр эштән усалланмаган-тупаслангмаган хатын-кыз калмаган. Халисә белән янәшә куеп, язучы Мәрданшадан Су анасын идеал дәрәҗәсенә күтәртә. Шуның аша җәмгыятьнең хатын-кызга мөнәсәбәтенә сатирик бәя бирә. Әдәбият-сәнгать тарафыннан мәхәббәт хакында тудырылган мифны җимерү ирония ярдәмендә башкарыла. (*Рәзе Халисә белән, кинодагы шикелле маткр итеп, озак итеп үбешеп була? Яисә, әнә теге, моннан сигез ел элек укыган китаптагы кебек, су чәчрәтә-чәчрәтә куышып, уйнап йөгереп буламы Халисә белән?!*)

Автор укучы белән уйный. Халисәне гел Су анасы урынына кертә. Мәрданша сөйгәнен өендә көткәндә дә, Зәй елгасы буенда да автор Халисә образын отышлы гына кертеп җибәрә. Гүя ул Мәрданшага синең җирдәге “Су анаң” ул – Халисә ди кебек. Моны без Су анасының репликасыннан аңлыйбыз: *Ләкин мин – әкият бит. Ә Халисә әкият түгел... Резин итек киеп, кояшта каралып, ферма тирәсендә йөрсәм, миңа да гашыйк булмас идең.*

Комедиядә авторның төп максаты илдәге пычрак, бозык якларны ассызыклап күрсәтү, шушы илдә (җәмгытьтә) яшәүче халыкның да бозылуын, рухи дөньясының саегуын ачып салу. Автор фикере Су анасы образы аша әйттерелә: “*Сезне аерым юләрләр йортына ябып интектерергә кирәк түгел инде, сез бит барыгыз да тулар –тулмас.”*

*“Дөньяның буталчыклыгында синең дә, минем дә гаебебез юк. Буталып бетте бөтен нәрсә, адашып беттек барыбыз да. Тик шуны беләсе иде: кем гаепле икән?”* кебек Су анасы биргән сорау авторныкы булып яңгырый. Шушы урында автор ни өчен мифологик сюжетка мөрәҗәгать итүен дә шәрехләп уза: *“Сез үзегез дөньяны төрле әкиятләр белән бизәргә тырышасыз, ә үзегез әкият кебек саф дөньягызны пычратып яшисез. Болай булса, кешеләрдә әкиятнең үлүе ихтимал”.*Димәк, чынбарлыкның әкияттән ераклашуын, аның капма-

каршысына әверелүен төшенгән һәм шуны укучыга җиткергән авторны җәмгыятьтәге хайванга әйләнгән кешеләр аңында сакланып калган бердәнбер матурлыкның – экиятнең юкка чыгу куркынычы борчый. Яшәп килүче идеология экологик афәт, изелү, туктаусыз эчү, наданлык һәм тупаслык басымында яшәүче кешеләрнең аң төпкелендәге экиятне дә юкка чыгарырга мөмкин, дип кисәтә автор.

Зөлфәт Хәкимнең "Җен бутады" пьесасында мифны кабатлау күренеше белән очрашабыз. Ул автор тарафыннан ике пәрдәле трагикомик фарс дип бирелә. Биредә бик күп мифологик күренешләр, мотивлар, образлар үз мәгънәләре саклаган хәлдә әсәр эчтәлегенә кертелгән. Автор үзенең 90 еллар иҗатында әлеге алымнарны яратып куллана, шулай тормыш, яшәеш, рухи кыйммәтләр, илдәге сәяси һәм иҗтимагый торыш турында фәлсәфи уйлана. Әлеге әсәрдә дә кешенең үз асылын югалту, рухи дөньясы пычрану, инсаннарның үзара мөнәсәбәте мәсьәләләре күтәрелә.

Автор тәкъдим итә торган дөнья моделе икәү: Җир һәм Күк. Җир дә, Күк тә үз эчләрендә тагын берничә пространствога бүленә. Җирдә кеше белән параллель яшәүче җеннәр тормышы аерым яссылыкка чыга. Биредә җеннәр турындагы сюжет сызыгы шайтаннар һәм җеннәр турындагы мифларга, Ислам дине тәгълиматларына барып тоташа, шулай ук авторның үз уйдырмасы да урын ала.

Зөлфәт Хәким әсәрендә Җеннәр турындгы мифка тулысынча таяна. Аның әсәрендә дә җеннәр күлдә яшиләр, таң вакыты җиткәч кеше күзенә күренмиләр. Тик авторның төп максаты укучыны Җеннәргә ышандыру түгел, ә илдә барган экологик (*Без яши торган күлгә заводтан ниндидер шакша отход китереп ташладылар. Ике җенебез шунда ук җан бирде. Бик күпләребез аврвйлар хәзер*), иҗтимагый, кешелек проблемаларын яктырту. Автор пьесага урыс һәм татар җеннәре дигән төшенчәләрне кертеп, бер үк Татарстанда гомер итүче ике милләт вәкилләренең бер-берсенә мөнәсәбәтенең асылын ача: *Татарлар да бар. Без бит күп милләтле. Безнең күлдә, мәсәлән, татар җеннәре белән беррәттән урыс пәриләре дә бар. Ләкин без алар белән аралашмыйбыз. Чөнки алар*

*шапшак, ялкау. Мин үзем татар, исемем Хатыйп, сөннәткә утыртылган. ...Урыс пәриләре дә безне яратмыйлар. Ничава, Алла боерса, Татарстан бәйсезлек алу белән, без аларны үзебезнең күлебездән куачакбыз. Әнә Новгород сазлыкларына китсеннәр. ...Бөтен татар җеннәре урыслашып бара. Татар җеннәре урыс пәриләренә әверелеп бетсә нишләрбез! Бердәм түгел татар җеннәре.*

Җир тормышында яшәүче исерек Сәлмән аның хатыны Саимә арасындагы мөнәсәбәтләр янә илдә бер туктамый дәвам иткән гаилә мөнәсәбәтләре проблемасына барып тоташа. Кешенең бер-берсенә ышанычын югалтуы адәм балалары өчен иң газиз әйбер булырга тиешле гаиләләрне тарката, балаларны тилмереп яшәргә мәҗбүр итә.

Алда әйткәнчә, автор Җир һәм Күкне тагын берничә өлешкә бүлә. Күктә Ай һәм аборигеннар яши торган исеме билгесез планета. Әлеге мифологик, фантастик урын мөнәсәбәтләрен автор укучысына тулы бер кешелек моделен торгызып, барлык кимчелекле якларны ачып күрсәтү өчен файдалана.

Әсәргә кертелгән ай, мифологик сюжеттан чыгып, мәрхәмәтлелек, гаделлек билгесе, туры юлга күндерүче буларак формалаша.

Сәлмәннең башка планетага китүе, анда Гали, Камил һәм өч кеше яшаучы абориген белән очрашуы автор тарафыннан махсус уйланылган. Ул абориген образын өч татар образы белән чыгыштырма планда бирә. Алар кеше ашаучылар булсалар да бер-берсенә тимиләр, бердәм тормыш алып баралар. Гали, Камил, Сәлмәнне дә берләштерүче әйберләр күп, алар өчесе дә бер планетадан, өчесе дә татар. Бу кеше образлары артында безнең татарга хас үзенчәлекләр яшеренгән. Ягъни татарлар бер-берләрен ашау дәрәҗәсенә җитеп, үзләре өчен, бары үзләре өчен генә яшиләр. Бу урында “татар татарны ашар”ашар дигән әйтем бик туры килә.

Автор кеше кайда гына булмасын үзгәрми дигән идеяне дә алга сөрә. Гали ничек урлашкан ул гомере буе урлашачак, Камил ничек сугышып, кеше рәнҗетеп йөргән ул һаман шул юлда булачак. Аларның күңелләренә язылган тормыш мәгънәсе дигән программа ныклы нигезне башка юнәлештә алган.

Рухи дөньялары күптән пычранган; беркемгә, бернәрсәгә ышанмыйлар һәм беркем, бернәрсәдән курыкмыйлар. Бу кешеләрне кире программалаштырырга мөмкин түгел. Тик Сәлмән планында бу башкачарак. Сәлмән әлеге сазлыкка кереп баручы буларак тасвирлана. Аның күңелендә якты яклар бөтенләй үлеп бетмәгән, менә шулар яңадан ачылып, кешене яшәү мәгънәсен аңлау, гаилә кадере, бала хакы дигән якка алып чыга.

Моннан тыш Җен образы һәркемнең күңелендә яшәүче “МИН”е буларак та кабул ителә. Автор еш кына күпләргә билгеле “Җен бутады” сүзтезмәсен еш файдалана һәм әсәрнең исеменә чыгара. Һәрбер кеше үзен үзебез бутап яши (Сәлмәннең баласын танымавы), үз дөреслеген, үз кануннарын уйлап чыгара, аңа ышана, шулар буенча яши һәм “Гали”, “Камил” кебек типиклаштырылган образларга әйләнә.

Шул рәвешле, ике гасыр чигендә драматургиянең яңадан-яңа алымнар, тема-проблемалар, образларны әдәби мәйданга кертүе, мифологизмга мөрәҗәгать итүе, заманча фикерләргә төреп тәкъдим итүе сүз сәнгатенең яңарышын, дөнья әдәбиятына югарылыгына йөз тотуын тагын бер кат дәлилли.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Хәзерге татар драматургиясендә нинди иҗат юнәлешләре, агымнары алга чыга?

2. Соңгы еллар сәхнә әдәбиятында нинди тематик-проблематик төркемнәр аерылып чыга?

3. Хәзерге татар драматургиясендә нинди жанр һәм жанрформалары актив?

4. Хәзерге татар драматургиясендә чагылыш тапкан типик образларны һәм аларга хас сыйфатларны билгеләгез.

5. Чор драматургиясендә маргиналь герой бирелешен аңлатыгыз, аңа нинди сыйфатлар хас?

6. Соңгы еллар сәхнә әдәбиятында мифны кабатлау (мифологизация) һәм “мифны җимерү” (демифологизация) алымнарының чагылышын аңлатыгыз, алар нинди функция башкарып килә?

**Әдәбият исемлеге.**


1. Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 233б.
2. Батталова А.Д. Татар драматургиясендә йорт образының үсеш–үзгәреше (1960–2000 еллар) / А.Батталова. – Казан, 2009. – 120 б.
3. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Заһидуллина, Н.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – 2 нче китап: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.
4. Закирҗанов Ә. Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар китап нәшрияты, 2011. – 287б.
5. Закирҗанов Ә. Яңарыш юлыннан (Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре) / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2008. – 285 б.
6. Йосыпова Н. Соңгы еллар татар драматургиясе / Н.Йосыпова // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф., 2008. – Б. 436-443
7. Саттарова А.М. Яңа дулкында / А.Саттарова // Татар драматургиясе (1980-2000 еллар): Сайланма пьесалар. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2003. – Б.5-16
8. Саттарова А. Современная татарская драматургия 1985-2000 гг. Концепция эпохи и героя / А.Саттарова. – Казань: Gumanitarya, 2003. – 125 б.
9. Шәмсутова А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр / А.Шәмсутова. – Казан: Татар китап нәшрияты, 2010. – 205 б.


## Тема 6. Хәзерге татар прозасы: стиль тенденцияләре, жанрлар төрлелеге: реалистик, романтик юнәлешләр, интеллектуаль тенденция, экзистенциаль фикерләү төре, неомифологизм.

**Лекция 6**

**Аннотация.** Хәзерге татар прозасының үсеш-үзгәреш юллары турында мәгълүмат бирелә, төп үсеш тенденцияләре ачыклана. Хәзерге татар прозасында реализм, романтизм, интеллектуаль тенденция, экзистенциаль

фикерләү төре, неомифологизм стиль тенденцияләре, постмодернистик алымнар ачыклана.

**Ачкыч сүзләр:** проза, стиль тенденцияләре, жанр.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1.Хәзерге әдәбиятта реалистик юнәлешле проза.

2.Хәзерге татар прозасында экзистенциаль фикерләү төре.

3.Романтик юнәлешле прозада реалистик проблемалар.

4. Хәзерге прозада «интеллектуаль юнәлеш».

5. Неомифологизм агымы.

Хәзерге татар прозасында шартлы рәвештә биш юнәлешне аерып куярга мөмкин:

**1. Реалистик** юнәлешле проза иҗтимагый проблематиканы калкыта: К.Кәримовның “Саңгырау күке” (2000-2002), “Ком сәгате” (2003) һ.б. Прозада «кырыс реализм» җәмгыятьнең таркала баруы, деградациясе проблемаларын гәүдәләндереп формалаша.

Хәзерге прозада милли тарихка игътибар кимеми, **тарихи роман жанры** актуальлеген югалтмый (В.Имамовның “Утлы дала” (2006) һ.б.

Хәзерге прозада **тәнкыйди дискурс практикасының итератив төре** өстенлек ала, ягъни әсәрләрдә “вакыйга түгел, бәлки җәмгыятьтәге ниндидер хәл, халәт хакында фикер әйтү, аны беркетеп куярга омтылу” алга куела. Әсәрләрдә чор картинасын тудыру, заман, хакимият, системаның бөтенлекле образын укучы күз алдына бастыру максаты әйдәп бара. Реалистик әсәрләр ярдәмендә татар язучылары татар халкы үткәненең аерым бер дәверләре сурәтен яңадан тергезергә (1920-1930 еллар фаҗигасе – Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» (2003) романында, 1980-1990 еллардагы ялганга корылган хакимият

системасы Ф. Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» (2004–2006) трилогиясендә һ.б. үзәктә тора). Авторлар үзләре дә җәмгыятьнең яки җәмгыяви бөтенлекнең вәкиле булып аңлашылалар, шул бөтенлектәге әхлакый кануннарны алга куеп, үткәннәргә бәя бирәләр.

Хәзерге татар прозасында **экзистенциаль фикерләү төре өстенлекле.** М.Кәбировның “Сары йортлар сере”(2000) фәлсәфи повестенда курку фәлсәфәсе экзистенциаль яссылыкта бирелә. Автор сурәтләгән дөнья чиктән тыш гарип, чиктән тыш кешелексез булып күз алдына баса. З.Хәкимнең “Легионер” романында (2009) тарихи материал татар кешесен үз асылына кайтырга чакыру темасы белән бер үремтәдә экзистенциаль мотивлар ярдәмендә бирелә.

**Романтик юнәлешле** прозада **реалистик проблемалар** калкытыла. Гасыр ахырында иҗтимагый катлам әһәмиятле роль уйный торган, ситуацияләр иҗтимагый-тарихи да, психологик та мотивацияләнүче, **романтик реализм** төшенчәсенә туры килерлек әсәрләр иҗат ителә (Ә. Салахов «Соңгы вальс» (2003), М. Кәбиров «Мәхәббәттән җырлар кала»(2004), Р.Бәшәрнең “Адашкан кош тавышы” **(** 2003), “Акбалык” **(**2003) һ.б.).

М. Кәбировның «Мәхәббәттән җырлар кала» повестенда реалистик катламдагы хәл-вакыйгаларны романтик алымнар ярдәмендә бәяләп бара. Әсәр Кыям абзый җыры белән башланып китә, һәм шушы җыр булачак вакыйгаларның характерын билгели. Җырга һәвәс Кыям турында сөйләгәндә, автор аны «стандарт булмаган» герой дип тамгалый. Әсәр барышында очрашкан башка геройлар: Гөлзилә яки Таһир да, комендант Нәфисә һәм Ришат белән Гүзәл дә – шулай ук үзгә, талантлы, яктыкешеләр. Ләкин талант – автор аңлатуында якты кеше булу өчен иң кирәкле сыйфат түгел. Әхмәт Сабиров, Нурияләр мисалында әхлакый якның әһәмиятле булуы күрсәтелә. Төп героинядагы мәхәббәткә тугрылык сыйфаты югары күтәрелә.

Хәзерге прозада **«интеллектуаль юнәлеш»нең** асыл үрнәкләре – М. Кәбировның «Сары йортлар сере» (2002) повесте, Т. Миңнулинның «Минһаҗ маҗаралары» (2005) романы.

**Неомифологизм агымы** Н. Гыйматдинова, Г. Гыйльманов, Ф. Бәйрәмова әсәрләрендә гәүдәләнеш таба. Н. Гыйматдинованың «Аргы якта, бирге якта» (2003) повестенда сюрреалистик элементлар бар.

Шул рәвешле, хәзерге татар прозасы стиль тенденцияләре җәһәтеннән дә, жанрлар төрлелеге ягыннан да киңкырлы.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1.Хәзерге татар прозасында стиль тенденцияләрен аерып куегыз.

2.Хәзерге татар прозасында жанрлар төрлелеге.

3. Реалистик, романтик юнәлешләр.

4.Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция, экзистенциаль фикерләү төре, неомифологизм.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. –Б.4-8

2. Заһидуллина Д.Ф. XX-XXI гасыр чиге татар прозасында тәнкыйди дискурс / Татар әдәбиятын өйрәнү һәм укыту: Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференция материаллары (13 май 2009). – Алабуга: АДПУ, 2009. Б.84-89.

3. Загидуллина Д.Ф., Ибрагимов М.И. Современная татарская проза / Д.Ф. Загидуллина, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012.

## Тема 7. М.Кәбиров әсәрләрендә постмодернистик алымнар

**Лекция 7**

**Аннотация.** Хәзерге татар прозасында психологизм бирелеше үзенчәлекләре, “аң агышы” алымы, экзистенциаль мотивлар ачыклана. ачыклана. М.Кәбировның хикәяләрендә постмодернистик алымнар, “Чиксез табут” әсәре мисалында постмодернистик текстта “аң агышы” алымы, экзистенциаль мотивлар табыла.

**Ачкыч сүзләр:** “аң агышы” алымы, экзистенциаль мотивлар.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Хәзерге татар прозасында хикәя жанры: үсеш үзенчәлекләре.
2. М.Кәбиров хикәяләрендә постмодернистик алымнар. “Дүртенче үлчәм”, “Канатлы кеше”, “Елмаю”, “Мин яратам сине” хикәяләрендә деконструкция, конструктивизм, аң агышы алымнары.
3. М.Кәбиров “Чиксез табут” повестенда аң агышы алымы, экзистенциаль мотивлар.

М.Кәбировның «Дүртенче үлчәм» һәм «Канатлы кеше» – тулысы белән шартлы, татар әдәбияты өчен модерннан соң (постмодернистик) кулланыла башлаган алымнарга бай әсәрләр.

«Дүртенче үлчәм» – мәхәббәт хакында, мәхәббәтнең олылыгына мәдхия булып яңгырый. Хикәядә вакыйгалар үстерелеше түгел, хис-кичерешләр көчеше үзәккә куелган. Әсәр лирик-эмоциональ дулкында язылган, ир белән хатынның сөйләшүе шулкадәр җылы һәм самими, нәкъ менә шул сөйләшү кеше күңеленең бай һәм тирән булуын күрсәтә. Сөйләшү һәм хис үсешен күзәтеп бару – автоматик язу алымы – хикәяләүченең алар халәтен бәяләве белән үрелеп бара. Айны, йолдызларны кабызу, яшьлеккә кире кайтырга омтылу татар халык җырлары белән ассоциациягә керә.

“Канатлы кеше” хикәясе күнегелгән күзаллауны юкка чыгара, моны хикәяләүче дә ассызыклап бара. Максат кую гарип кешене тормышка кайтара, сөйләшергә, йөрергә өйрәтә. Хикәя кешенең мөмкинлекләре турында. Беренче хикәядәге кебек үк, «Канатлы кеше»дә дә дуслык һәм гаилә шәхес өчен терәк, иң олы кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә. Язучы бу фикерне кат-кат, төрле яссылыкларда кабатлый. Хикәяләр якты, кешенең бөеклеге, кешеләр арасындагы ихлас мөнәсәбәтләрнең матурлыгы хакында сөйли. Шуңа

ышандыру өчен, шартлы дөнья моделе тудыра, чиктән тыш арттырып кына калмый, күнегелгән тормыш кагыйдәләренең хакыйкать булуын шик астына ала. Бу әсәрләрдә тормыш фәлсәфәсе татар укучысы өчен якын лирик-эмоциональ башлангыч белән кушылып бирелә. Моның өчен эпик сөйләм шигъри тел чаралары белән аралаша. Эстетик яктан камил, тәэсирле, романтик пафос белән сугарылган, шартлы сурәтне әдәби концепция максатларында кулланучы хикәяләр татар әдәбиятына яңа сулыш бирүче каләм остасы килгәнлекне хәбәр итәләр.

Шул рәвешле, татар әдәбиятында хикәя үзгәрешләргә иң сизгер жанр булып кала.

М.Кәбировның “Чиксез табут” әсәрендә төп фәлсәфә – экзистенциализм, чарасызлык, биредә креатив дискурс ярдәмендә хәсрәт хисенең үсә баруын тасвирлау алга алына. “Ялгыз кеше трагедиясе” – экзистенциализм рационализмга, акыл көченә шикләнеп караудан башлана, шикләнү чарасызлыкка китерә. Чарасызлыкның сәбәбе – яшәешнең камил булмавыннан, кешенең үзен чиксезлек, галәм каршында артык кечкенә, Аллаһның бөеклеге каршында бик түбән сизүдән. <u>*Үлем, Өметнең өзелүе, Гөнаһ һәм Җәза, Хакыйкать*</u> кебек төшенчәләр – сызлану фәлсәфәсенең нигез категорияләре.

Әсәрдә газапланучы рәссам ир образы чарасыз-ялгыз халәттә тәкъдим ителә: “*Кинәт бар булмышын шом, курку, әрнү ялмап алды. Ул үзен үксез ятим итеп сизде. Һәм көтмәгәндә килгән кыргый курку белән кайдадыр йөгерергә тотынды. Башының кайсыдыр почмагында табут тактасына бәрелеп үлү, һичьгы һушын югалту өмете сүнеп бетмәгән иде әле. Аңа хәзер барыбер иде. Фәкать шушы коточкыч хәлдән котылырга гына. Котылырга”. “Олы бер шәһәрдә ул ялгыз иде. Моны уйлаудан күңеленә чиксез шом йөгерде. Үзен яклаучысыз итеп, үксез ятим бала сыман итеп тойды. Менә-менә ниндидер җанвар килеп чыгар да аңа ташланыр, адәм чыдамаслык газапларга дучар итәр төсле тоелды”.*

Ир Үлем көтә: “*Ул тирә-юнгә каранып озак торды. Үзен һәлак итәчәк афәтнең кайда яшеренгәнлеген чамаларга тырышты”.* Сюжет сызыгы бик

гади: Азамат исемле рәссам ир гаиләсен югалта. Хатыны аның җитәрлек акча алып кайтмавын сылтау итеп аерыла. Ир тулай торакка кайта, акча урлау хыялы белән яши башлый, акылдан яза. Яшәп килүче системаның гаделсезлеген тәнкыйтьләүне алга куйган автор интертекстуальлек алымы белән (Харлан Элисонның "Колак салыгыз" хикәясе) "тормышның асылын аңлатып бирә" кешенең әлеге җәмгыятьтәге урынын әйтә: *"Кечкенә дәрәҗәдә, кечкенә хезмәт белән шөгылләнеп яшәгән соры кешегә шулкадәр күнеккәннәр ки, хәтта аның барлыгы-юклыгын да белмиләр, аны бөтенләй күрмиләр".*

Газапларының сәбәбе – чарасызлык. Яшәү кешене авырлыклар белән сыный, ләкин хакыйкатьне белү фаҗигане тирәнәйтә: "*Ул ярлы тормышны яхшы белә, акчасызлык, хәерчелек аның тәмам үзәгенә үткән, мәңгегә дә онытылмаслык булып хәтеренә уелып калган иде"*. Әсәрдә иҗтимагый-әхлакый проблематика (ярлылык яисә матди байлык артыннан куу, азгынлык, мәхәббәтнең югалуы, эчкечелек, битарафлык, кешелексезлек) яшәеш нормасына әйләнгән күренеш төсендә тәкъдим ителеп, Хәсән сүзләре белән көчәйтелә: " *Менә бу халык... Аларга синең рәсемең кирәк дисең мени?! Сәнгать кирәк дисеңме аларга?! Боларга ашарга, эчәргә булсын да... сөешергә булсын. Бу халыкның аңы маймыллыктан узган, кешелеккә барып җитмәгән бер аравыкта тотлыгып калган. Иҗат кешесен чарасыз хәлгә кую – безнең җәмгыятьнең иң зур осталыгы. Инженерны тимер-томыр арасына ыргыт – ул яңа техникага утырып килеп чыгачак. Сәнгать кешесен тормыш сазлыгына ташла – ул сазлыкны чишмә итәчәк. Тормышның ходай исәпкә алмаган тишек-тошыкларын без талантлар белән ямыйбыз"*. Шул яшәеш кешене чарасызлык алдында калдыра, өметсез итә, сызлану чыганагына әверелә, ди автор.

Ләкин автор төп гаепне кешенең үзеннән эзләтә, кеше үзе генә тормышы, сайлаган юлы өчен җаваплы дигән фикерне алга сөрә. Алга кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ерткычлыкка корылуы куела: "*Бер ерткыч. Бер котырган ерткыч. Ә баганага бәйләнгән кеше – ниндидер канунны бозган, шушы организмга буйсынырга теләмәгән, үзе бер организм булырга омтылган шәхес. Һәм аны юк итәләр. Бу коточкыч күренеш. Ләкин табигый күренеш.*

*Капканга эләккәч, үз аягын чәйнәп өзеп качкан комак шикелле. Чери башлаган аягын кисәргә ризалык биргән кеше шикелле. Баганага бәйләп куелган кеше – шушы халыкның чери башлаган аягы. Яки кулы. Яки башка җире. Һәм аны яндыралар. Башкалар чермәсен, теге зур организм таркалмасын өчен. Шулай тиеш".*

Чарасызлык – – яшәешнең асылына салынган хис, тормышның үзгәрүе бу канунга үзгәреш кертми, шуңа күрә хакыйкатьне табу, яшәешне танып белү мөмкин түгел: " *Ул башта кемнәрдәндер өйрәнде, өйрәнчеклек чорын узгач та иҗаттәшларының һәр уңышы өчен шатланып яшәде. Җылы сүзен дә, кирәк дип тапканда тәнъкыйтне дә кызганмады. Чөнки белә иде, ялгыш мактауга караганда, дөрес тәнкыйть күпкә файдалырак. Һәм аны ишетү дә җиңелрәк, рәхәтрәк. Ләкин тора-бара иҗаттәшларының мактауга да, хурлауга да мохтаҗ түгеллеген, гомумән, аның фикере беркемне дә кызыксындырмавын сизде. Һәм эндәшмәс булды. Күрмәс булды. Ул чакта Азамат хәерче иде әле. Баегач, аның фикерен ишетергә теләүчеләр табылды, әлбәттә, тик Азамат инде аңлый иде. "Элек сезгә минем фикер кирәк түгел иде бит, - дип уйлады ул, - Мин үзем дә кирәк түгел идем. Нигә хәзер кызыксына башладыгыз әле. Мин бит үзгәрмәдем. Шул вакыттан алып, казаныш булырлык бер картина да төшермәдем хәтта. Рәссам буларак, мин һаман шул Азамат. Кеше буларак та. Тик картиналарым гына сатыла башлады. Ә осталыгым артмады да, кимемәде дә. Мин һаман шул килеш. Нигә сезне минем фикер кызыксындыра башлады әле?" Һәм ул дәшмәде. Үз дөньясына чумды.*

*Саклану өчен шулай кирәк иде.*

*Ике дөнья.*

*Ул ике дөньяда ике кеше рәвешенә кереп яши түгелме соң?*

*Шәхеснең икегә бүленүеме бу?*

Яшәеш тәртибе алдан уйланылган, аңа буйсынырга гына туры килә, кеше Галәм каршында артык кечкенә: " *СЕЗ ҖӘННӘТТӘН КУЫЛАСЫЗ! - Сез чиркәүдән читләтеләсез!*

*- Сез партиядән куыласыз!*

*- Вазыйфагыздан бушатыласыз!*

*- Талак! Талак! Талак!*

*- Син миңа ир түгел!*

*- Син миңа бала түгел!*

*- Ата-ана хокукыннан мәхрүм итәргә!*

*- Хокукыннан мәхрүм итәргә!*

*- Иркеннән мәхрүм итәргә.*

*- Мәхрүм итәргә!*

*- Үлем җәзасы бирергә!*

*- Исемен телгә алмаска!*

*- Онытырга!”*

Димәк, тормыш-яшәешнең төп кануны – сызлану дип алдан уйланылган: *“Нинди генә дингә карасаң да, ходайга сыгынучыларның күз яшьләре, иңрәү авазлары, чиксез газаплары чәчелеп ята. Әнә чиркәүдән дә елау ишетелә”.*

Әсәр “җанының әрнүләр саклана торган өлешеннән чыккан ачы аваз тыну белән авырту да тукталган” мәлне тасвирлау белән башлана.

Алдагы хис яктылык тою белән бәйле: *“Буынсыз булып җиргә ягылганчы, ул кайдадыр балкып киткән нәни ут чаткыларын күргәндәй булды. Яктылык тузаны. Бу әллә чынлап бар иде, әллә күзенә генә күренде. Ни генә булмасын, ул табут тактасының аръягында иде... Ул күзләрен ачып-йомып алды. Бармак очлары белән күзенең ачыклыгын тикшерде. Кул сырты белән уалап карады. Бернәрсә дә күренмәде. Бөтен дөньяны алтынсу томан каплаган иде”.*

Кеше экзистенция баскычына – хакыйкатьне аңлауга таба атлый: *“...Кайдандыр ерактан ажгырып килгән көчле дулкын аны күмеп китте. Ул колакларын куллары белән каплап стенага сыенды, чүгәләде. Бөтен күзәнәкләреңнең астын-өскә китергән бу дулкынга чыдар хәл булмастай тоелган иде. Әмма, бераз өерелгәннән соң, ул тынычланып калды. Моңа кадәр*

*мин бернәрсә дә ишетмәгәнмен. Чукрак булганмын моңарчы. Ә әле... Әле колакларым ачылды да, кала шау-шуы аяктан егарлык коточкыч дулкын булып килеп керде. Димәк, мин исән.”*

Азамат исемле ир чарасызлык халәтеннән котылу юлын эзли: *“Кояшның якты нурлары күз алмаларын чиксез авырттырып кысып алды, ул ирексездән учларын маңгаена китерде, тик моның гына ярдәме тимәде. Күзләргә ком тутырган сыман иде. Әмма сызлау никадәр генә көчле булмасын, якты дөньяны күрә алу шатлыгы чамасыз иде. Ул күзләрен йома алмады, һәлак булырын да белгән килеш капкандагы сырга үрелгән комак сыман, әрнүләрен җиңеп яктылыкка үрелде. Яктылык газаплы да татлы да иде”.*

Яшәү Матурлыгын тойган кеше үзен бәхетле саный: *“Ул карашлары белән һәрбер йортны, агачларның яшел яфракларын назлап үтте. Буе җиткәннәрен үрелеп тотып, яңагын куеп иркәләнде, хуш исләрен иснәп ләззәтләнде. Җиргә иелеп үләннәрне үпте. Бар дөньяны өзелеп яратудан, җирнең матурлыгын күрә алу, тормыш сулышын, вакыт агышларын бөтен тулылыгында ишетә алу шатлыгыннан канатланган җаны ак күбәләк булып талпынды да аллы-гөлле нурлар сибеп һәм тормышны хуш исләргә күмеп утырган гөл-чәчәкләргә кунды. Ул бәхетле иде”.*

Максатка ирешеп булмавын аңлаган ир көрәшүдән туктаган, чарасызлык халәтендәге ир Үлемен көтеп сызлана, курка: *“Ул зәңгәр һаваны күрде, төрле төсләргә буялганлыктан җиргә төшкән җәйгорны хәтерләтеп торган йортларны күрде, тәрәзәләрдә чагылып киткән кояш нурын күрде, ишегалларындагы уен мәйданчыкларын, урам буйлап тезелеп киткән кибетләрне күрде. Агачларны, хәтта яфракларны сөеп үткән җилне күрде, җил искәндә нәни яшел дулкын булып тибрәнгән үләннәрне күрде. Ул күрде. Ул барсын да күрде. Ул карашлары белән һәрбер йортны, агачларның яшел яфракларын барлап тикшереп үтте. Буе җиткәннәрен үрелеп тотып, күзләренә терәп өйрәнде, шикле ис табарга теләп иснәп карады. Җиргә иелеп үләннәргә бакты. Бар дөньядан чиксез шикләнүдән, тормыш сулышын, вакыт*

*агышларын бөтен тулылыгында ишетеп тә, бер адәмне күрә алмавыннан, ялгызлыктан гаҗизләнгән җаны һаман нидер эзләп чәбәләнде".*

Хикәяләүче–герой эссенция баскычыннан экзистенция баскычына атлый: күтәрә алмаслык кайгы – югалтуларны тою, аңлау хәлендә кала:

*"Аның гомере бары тик югалтудан гына торадыр сыман тоелды.*

*Башта хәтерен югалтты.*

*Азак җирдә яшәгән кешеләрне.*

*Аннан соң хайваннарны, кош-кортларны, бөҗәкләрне...*

*Буар елан сыман бар дөньясын урап алган ялгызлык аны акырын әмма ныклы итеп кыса иде. Әйе, аңа бернинди ерткыч җанвар да янамый, әмма аның җәллады бар һәм бер иде. Ул шушы буш шәһәр иде.*

*Ул үзенең ачы кайгысыннан, чарасызлыгыннан үкереп елап җибәрде. Әмма тавышы чыкмады, бугазында төер булып калды. Күз яшьләре дә керфегенә кунмады, алар парга әверелеп йөрәгенә кадалдылар.*

*Ул хәтта рәхәтләнеп елый да алмады.*

*Ни өчен миңа шул кадәр газаплар? – дип уйлады ул,- Нинди гөнаһлар өчен? Мин шушы кадәр җәзаларга лаек булырлык нинди хәтәр гамәлләр кылдым икән? Кем икән мин?*

Иң элек ир Ялгызлыктан курку халәтеннән аны табигый халәт дип таный, елмаеп куя: ". *Ни генә әйтсәң дә кешеләрдән башка ул да ялгыз булган бит. Яшәү авазлары чыгаруы да, бәлки, Азамат хөрмәтенәдер. Бу сансыз еллар буе ялгызлык утында туңып гомер уздырган шәһәрнең уянуы, нindидер фаҗигадән соң үзенә аяк баскан бердәнбер кешене сәламләведер".*

Шул урында ялгызлыкның фаҗига икәнлеге белдерелә, автор карашы кебек кабул ителә: *"Кеше! Безгә миллион елларга беренче тапкыр КЕШЕ аяк басты. Үзе төзегән дөньяга ул кабат кайтты. Барыгыз да аны кешечә итеп, кунакчыл итеп каршылагыз. Үзенең ялгызлыгын тоярлык булмасын!"*

Азамат исеменнән Матурлыкның мәңгелек булмавы, аның җуелуы, югалуы әйтелә. Шуны аңлау, карашны үзгәртү  асылына сызлану салынган Яшәешне җиңелрәк итә – килешергә, иң мөһиме – яшәүне дәвам итәргә көч

бирә. Азамат къзгщ кщренмщс кеше картинасын яза, йорт сала: *“Үзеңне җәзага дучар ителгән бәхетсез җан итеп тоюга караганда, көтеп алынган кадерле кунак дип хис итү чиксез әйбәтрәк. Һәм чынлап та аңа күпкә җиңелрәк булып калды. Кеше әйбернең үзенчәлеген үзгәртә алмый, әлбәттә, ләкин аңа карашын үзгәртә ала. Караш үзгәрү зур нәрсә. Әйбергә ничек карасаң, ул шулай булып күренә. Әлеге хәле дә башта коточкыч газап булып тоелган иде, әмма хәзер ул ялгызлыкның да өстенлекләрен күрде. Юк, ул буар елан камауындагы бичара зат түгел иде. Ул бу шәһәрнең бердәнбер кешесе, ул бу шәһәрнең патшасы да, алласы да иде”.*

М.Кәбиров прозасында төп постмодернистик алымнар буларак кабатланган деконструкция һәм конструктивизм чынга ашырыла, йорт символына яңа тәртипләргә корылган чынбарлык мәгънәсе салына: *“Йортын төзеп бетергәч, ул канәгать елмаеп бертын карап торды да сызгырып җибәрде. Тугызар, егермешәр катлы шәһәр өйләре белән чагыштырганда, бу, әлбәттә, бик кечкенә, уенчык кына иде. Әмма нинди уенчык бит әле! Мондый йортны беркемнең дә, бер кайчан да төзегәне булмагандыр, аны төзү уе берәүнең дә башына килмәгәндер дә әле. Хәер, андый теләк туса да, бик-бик теләсә, хәтта аның гомере шушы йортны төзү-төзмәүгә бәйле булса да, бу беркемнең дә кулыннан килмәс иде.*

*Ә Азамат төзеде.*

*Бу уй аның башына беренче көнне үк, үзенең бөтен шәһәрдә бердәнбер тере зат икәнен белгәч үк, килгән иде. Әмма бу – уйлау белән үк башкарып чыгарлык җиңел нәрсә түгел иде”.*

Автор конструктивизм алымы белән фәлсәфи нәтиҗәгә алып килә: *“Кешелек дөньясын алга этәрүче ачышларны фәкать күнегелгән кануннарны бозучылар, җәмгыятьнең әнә шул чирле әгъзалары ясаган. Аларны кешелек организмыннан кисеп ташласалар да ачыш калган”.*

Шул рәвешле, автор карашынча, танып белү мөмкин булмаган Яшәешне дә, тормыш-чынбарлыкны да, матурлык һәм мәхәббәтне дә кеше үзе уйлап таба, тудыра, кора. Әсәрдә табигатьтәге матурлыкны сурәтләүгә зур урын

бирелә, һәм кеше омтылышының табигать гүзәллегенән дә матуррак булырга мөмкинлеге искәртелә. Автор тормышның, кешенең камил булмавына капма-каршы көч итеп рухның бөеклеген һәм садәлеген куя: *“Матур гына түгел, бик кыйммәт тә иде бу йорт. Ул кибетләрдән, банклардан, төрле оешмалардан ташыган акчалардан төзелгән, асылташлар белән бизәлгән иде. Аның нигезендә алтын-көмеш, стеналарында берничә кат булып беркетелгән кәгазь акчалар, түбәсендә тиенлекләр булып, монда бер генә кадак та, бер генә такта, яки башка төзү материалы да кермәгән иде. Һәм аны РӘССАМ төзегән иде. Бу йорт көннең нинди булуына карап үзгәрә, төрле төскә, төрле рәвешкә керә, яктылык билгеле бер юнәлештән төшкәндә ул бөтенләй күздән югалып тора иде.*

*Башта моны үзен күпме михнәтләр кичерергә мәҗбүр иткән акчадан, матди байлыктан көлү, мәсхәрә итү нияте белән уйлаган иде ул. Ләкин тора-бара бу нияте юкка чыкты, алдында ачылган мөмкинлекләр янында ул бөтенләй вак булып, чүп кенә булып тоелды. Хәтта үзенең шулкадәр мескен уйлар уйлый алуына ул аптырап та куйды. Кулына алган һәрбер купюра, һәрбер тиен үзенчә матур иде, һәм бу матурлыктан илаһи кодрәткә, тылсымга ия гүзәллек, могҗизауи матурлык тудырырга мөмкин иде. Шул матурлык аны үзенә суырып алды. Ул инде вак-төяк нәрсәләр хакында онытты. Теге дөньядагы уңышсызлыклары да, гаиләсен югалту, хәтерен җуюы да, бу шәһәрдә япа-ялгыз калуы да – һәммәсе дә бик кечкенә һәм мәгънәсез булып тоелды. Ул алла иде. Матурлык алласы. Йорт көннән-көнгә үзенә карап сокланырга мәҗбүр итте. Вакыт үткән саен ул үзенең яңа ягы белән, яңа сыйфатлары белән ачылды һәм хәтта Азамат үзе дә уйламаган, үзе дә күреп бетермәгән матурлык белән балкыды. Бу йорт чынлап та могҗиза иде.*

*Затлы ташлардан, акчалардан ясалган өчен генә түгел. Хәтта гади генә кәгазьләрдән, гади ташлардан да ясап булыр иде моны. Эш бөтенләй асылташларда түгел иде. Хәтта аларның алтын-көмеш-акча икәнлекләре беренче карашка күренми дә иде. Хикмәт - күңел матурлыгында иде. Шушы йорттан ургылган матурлык, наз мәхәббәт күңелеңдәге якты хисләр белән*

*кушыла да ирексездән сине дә матур булырга әйди, үзеңне иң сөекле, иң изге, иң бәхетле кеше итеп тоярга мөмкинлек бирә иде.*

*Бу йорт - бәхет машинасы иде".*

Хыял җентекләп тасвирлана, тормышка мөнәсәбәт – Яшәештә үзеңне тоюның – кешенең күңел халәтенең нигезе дип белдерелә: *"Бу йорт та аны этиседәй күреп ярата булып чыгамы?!"*

Ләкин даими Ялгызлыктан туган чарасызлыкны тою Матурлыкны кире кагу сәләтенә ия: " *"Шушы чарасызлык МАТУРЛЫКны талый, МАТУРЛЫКның ялгызлыгын тою иң ачы бәхетсезлеккә тиң иде".*

Ышаныч бетү – чарасызлык чоңгылына ташлаучы бердәнбер хакыйкать: "*Адәм баласы үз күзенә ышанмый. Үз колакларына ышанмый. Кеше кешегә генә түгел, ә үз-үзенә дә тулыснча ышанырга курка. Һәм ул Кешелек дөньясын таркатучы көчнең бер сәбәбен тапкан кебек булды. ЫШАНЫЧ ЮГАЛУ».*

Димәк, ялгызлыктан котылу чарасы юк – тормышның мәгънәсенә төшенү, яшәүнең газап булуын аңлау, Яшәешкә ләгънәт уку мизгелендә герой күзаллавында хаос, үлем котылгысызлыгын тою формалаша: кешенең өметләр белән яшәүче яртысы үлем котылгысызлыгын аңлаган икенче яртысы белән кушыла, хакыйкатькә төшенә: "*"Чиксез табут... Чиксезлектән дә зуррак афәт бармы икән?..".* Табут – яңаруны көтү, яңа юлга чыгарга омтылу мәгънәсендә символлаша. Ләкин шәхес тормышы ялгызлык һәм чарасызлыкка көйләнгән, кеше көчсез, шуңа яңару мөмкин түгел дигән караш әсәрне туоаем экзистенциаль яссылыкта укырга мөмкинлек бирә.

**Сораулар һәм биремнәр**

1. М.Кәбировның "Дүртенче үлчәм" хикәсендә постмодернистик алымнар.
3.М.Кәбировның "Елмаю", "Мин яратам сине" хикәяләрендә постмодернистик алымнар.
4. "Канатлы кеше" деконструкция, конструктивизм, аң агышы алымнары.
3. М.Кәбировның "Чиксез табут" повестенда аң агышы алымы, экзистенциаль мотивлар.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Заһидуллина Д.Ф. “Сары йортлар сере” / Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. Б.169-180.

1. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледҗлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева.– Казан: Мәгариф, 2005. – 111б.

## Тема 8. Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция. (М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повесте).

**Лекция 8**

**Аннотация.** Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция турында мәгълүмат бирелә. М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повестенда шартлы-метафорик кимәлне өйрәнү аша интеллектуальлек билгеләре табыла.

**Ачкыч сүзләр:** фәлсәфи повесть, интеллектуаль тенденция, постмодернистик алымнар.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**

1. Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденция.

2. М.Кәбировның “Сары йортлар сере” повестенда шартлы-метафорик кимәл.

3. Повестьның фәлсәфи жанрга каравы.

1990 елларга, совет хөкүмәте таркалуга бәйле, рус әдәбиятында социалистик системаны тоталитар режим буларак бәяләгән, советчыл мифны җимерергә омтылып язылган әсәрләр пәйда була. Әсәрләрдә “вакыйга түгел, бәлки җәмгыятьтәге ниндидер хәл, халәт хакында фикер әйтү, аны беркетеп куярга омтылу (дискурс практикасының итератив төре) өстенлек ала”.

М.Кәбировның “Сары йортлар сере”(2000) фәлсәфи повестенда курку фәлсәфәсе экзистенциаль  яссылыкта бирелә: “Кешеләрерткыч, кол, мескен хәлендә яшиләр.  Кешеләрне һәлакәттән берни дә беркем дә коткара алмаячак”. Автор сурәтләгән дөнья чиктән тыш гарип, чиктән тыш кешелексез булып күз алдына баса.

М.Кәбиров  “көчле кеше фәлсәфәсен үзенчә бирә: көчле кеше генә изге, якты була һәм башкаларны үзе артыннан ияртергә сәләтле.

Хикәяләүчеләр икәү – (полифонизм күренеше): хикәяләүче һәм вакыйгалар шаһиты. Вакыйгалар шаһиты – чит сөйләм. Мәдинә карчык ике хикәяләүче тарафыннан капма-каршы бәяләнә.

Төп сюжет сызыгы: Мәдинә карчык күккә аша һәм Мәрьям үлә.

Ярдәмче сюжет сызыгы: алтынчы подъездга “коткаручы” Мәдинә килеп урнаша, ләкин кешеләр аның үлемен якынайта.

Каршылык Мәдинә карчык белән сары йорттагылар арасында.

Проблемалар Мәдинә карчык белән очрашулар аркылы куела:

1) Мәдинә карчыкның кешеләргә төртеп күрсәтүе (җәмгыятьтә гади кешеләргә хезмәт шартлары тудырылмау проблемасы).
2) Мәдинә карчыкның кешеләрне үз өенә чакыруы (кешеләрдәге курку проблемасы) .
3) Авыру ирнең чиренең сәбәбе – башкаларны рәнҗетү проблемасы .

Җәмгыять гротеск формасында, антиутопия итеп сурәтләнә. Гаеп гади халыктан (“кол булып туган гарип җаннар”) җәмгыятькә күчерелә. Ләкин алып ташланмый.

Куркуның беренче нәтиҗәсе “ачлы-туклы гомер кичерүгә дә, нәсел калдыра алмауга риза булып яшәү” формалаша.

Икенче нәтиҗә – ясалма шәфкатьлелек җәелү.

Алдагысы – курку явызлык булып әверелә (ышанмау, гаепләү, мәкер кору)

Интертекстуальлек алымнары:

1. Реминисценция – чит сүз: сары йорт, алтынчы подъезд.
2. Аллюзия – Мәрьям ана турындагы миф кабатлану.
3. Ироник сүз уйнату: коммунизмның бетәчәге хакындагы өлеш.

**Сораулар һәм биремнәр:**

1. Хәзерге татар прозасында интеллектуаль тенденциянең төп билгеләре.

2. М.Кәбировның "Сары йортлар сере" повестенда шартлы-метафорик алымнарны атагыз.

3. Повестьның фәлсәфи жанрга каравын нигезләгез.

4. Повестьта постмодернистик алымнар.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Заһидуллина Д.Ф. "Сары йортлар сере" / Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. Б.169-180.

2. Заһидуллина Д.Ф. XX-XXI гасыр чиге татар прозасында тәнкыйди дискурс / Татар әдәбиятын өйрәнү һәм укыту: Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференөия материаллары (13и май 2009). – Алабуга: АДПУ, 2009. Б.84-89.

## Тема 9. Хәзерге татар прозасында концептуализм күренеше (Г.Гыйльманның "Оча торган кешеләр" әсәре мисалында)

**Лекция 9**

**Аннотация.** Хәзерге татар прозасында турында концептуализм күренеше мәгълүмат бирелә. Неомифологизмга хас булган поэтик алымнар Г.Гыйльмановның "Оча торган кешеләр" әсәре мисалында бирелә.

**Ачкыч сүзләр:** концептуализм, неомифологизм, хронотоп, сакраль, профан.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. Хәзерге татар прозасында концептуализм күренеше.
2. Мифопоэтик нигезле сюжет структурасында хронотоп бирелеше.
3. Г.Гыйльманның “Оча торган кешеләр” әсәрендә хронотоп.

Хәзерге татар прозасында концептуализм әдәби күренеш төсендә яшәп килә. Күренекле әдәбият галиме М.Эпштейн үзенең “Парадоксы новизны в развитии литературы XIX-XX вв” (М., 1988) хезмәтендә концептуализм терминына түбәндәге төшечәне бирә: “Һәр әдәби текст билгеле бер дәрәҗәдә концептуаль, ягъни ул карашлар системасы. Концептуализм исә тексттагы концептуаль нигезне әдәби катламнан аерып куя, концепт хасил итә. Вместо произведения как концепция, перед нами  “концепция как рпроизведение”.

Хәзерге татар прозасында З.Хәкимнең “Легионер”, М.Кәбировның “Елмаю”, Г.Гыйльмановның “Оча торган кешеләр” әсәрләрендә концептуализм билгеләре табыла.

Г.Гыйльмановның “Оча торган кешеләр” (2001) әсәрендә концептуализм билгеләрен табу эпик текстның структур үзенчәлекләрен аерып кую ярдәмендә башкарыла. Моның өчен хронотопик анализ юлын – “Оча торган кешеләр” әсәренең пространство ягыннан корылышын өйрәнү юлын сайладык.

Күренекле әдәбият галиме М.Бахтинның “хронотоп – тексттагы мәгънәләрне ачу юлы” дигән нәзари карашы XX йөз ахыры–XXI йөз башы татар  прозасының үсеш үзенчәлекләрен билгеләү, аерып кую өчен нигез булып тора ала. Ике гасыр чигендә мифопоэтик структураны үз иткән эпик текст вакытка бәйле бинар оппозицияләр һәм урын образының тәкъдим ителеше аша гомумиләштерүләргә, модельләштерелгән бәягә омтыла.

Билгеле булганча, мифопоэтик структурага корылган әдәби текстта дөнья сурәте  профан / сакраль  бинар оппозициясенә нигезләнеп тудырыла Язучы сакраль үзәккә юл алуны максат иткән әдәби герой эшләнешендә пространствоны  чит / үз каршылыган үтәрлек ара рәвешендә оештыра.

Сюжет "рухи арыган, ләкин гамьле" Сәүбәннең, унсигез ел кайтмый торганнан соң, туган авылында сөйгән ярын, улын табу вакыйгасын сөйләп бирүгә корыла. Пространство алышынуын күзәтү тексттагы төп мәгънәне – үз асылын югалтмаган кешенең Җирдә яшәгән вакытта бәхетле була алмавы турындагы эчтәлекне  уку мөмкинлеге бирә.

Сәүбән образы белән таныштыру барышында автор хикәяләүчене укучы белән төрлечә "сөйләштерә". Әдәби алымнардан психологизмның эчке монолог алымы белән беррәттән беренче заттан хикәяләүнең авторның укучыга мөрәҗәгате алымы да кулланыла. Димәк, хикәяләүдә өченче затта бирелгән субъектив образ белән янәшә текстның авторы да катнаша.  Сәүбәннең кичерешләре сурәте хикәяләүче һәм төп геройның уйланулары рәвешендә тудырыла. Текстта төп геройның уйланулары белән бәйле вакыт-урын көйләнеше автор-хикәяләүченеке дә: "Сәүбән тиле түгел. Ул бик яхшы аңлап яшәде. Туган җирен яраткан кеше генә бөтен дөньяны ярата ала. (Ә аның кайтканы да юк.) Туган җир бер генә, чөнки гомер дә бер генә. (Ә ул әллә ничә гомергә ия кеше кебек яши.) Иң ярлы кеше — туган җирсез кеше. (Ул иң ярлы кеше булып чыга, чөнки ул туган җиреннән баш тартырга маташа.) Читтә йөргән кеше — бер җирдә дә яшәми. (Чөнки аның кайтыр урыны, димәк, яшәр җире юк.) Туган җирен яраткан кеше генә хатын-кызны чын-чынлап сөя, ярата ала. (Димәк, ул чын сөюдән дә мәхрүм?) Ватан — мәхәббәт кенә түгел, Ватан ул — язмыш! Ә язмыш — җаваплылык дигән сүз! (Димәк, ул тормыш-яшәеш җаваплылыгыннан да баш тарткан булып чыга…) Туган җирнең чын улы булу өчен, соң дәрәҗәдә ихлас булу кирәк! (Димәк, ул ихлас тормыш белән дә яшәми?!) Иң мөһиме: Туган җирне онытып булмый, аны сагынып кына була! (Ә ул аны онытырга тырышты…)"

Кичерешләр беренчесеннән башлап гомумиләштерелеп тәкъдим ителә: “Озак еллардан соң балачакка кайту рәхәт тә, кыен да икән. Хәтта… куркыныч та! Чөнки кеше бала чагына ике очракта гына кайта: нәрсәдәндер качканда яисә бик мөһим бер әйберен эзләгәндә… Сәүбән кистереп кенә әйтә алмый: качып кайтамы ул, әллә күңеле теләгәнне эзләп кайтамы? Бу, бәлки, ул чаклы мөһим дә түгелдер. Иң мөһиме — ул кайта. Кайтмаска ант итеп киткән җиренә кайта. Бәхиллек алмыйча киткән нигезенә кайта. Саубуллашмый-нитми киткән әнкәсе янына кайта… Ни өчен кайтамы? Моның сәбәбе бар. Ул авырды, үлемнең күзенә карады… Шул үлем әҗәле аңа туры карап әйтте: “Кайт бар, авылыңа кайт, гомер, нәсел йолдызыңны рәнҗетергә теләмәсәң, нәселеңне югалтасың килмәсә, кайт, кайт!”- диде”.

Сакраль үзәккә юл аны атаудан башлана: “Сарманай авылыннан бер чакрым ераклыкта Кала-тау бар. Ә-ә-әнә ул. Бу тау итәгендә юкәләр үсә”. Текстны каймалап алган Чулпан йолдыз образы җир мәхәббәтен илаһи яшәеш ягына күчерү вазифасын башкара, реаль / трансцендентал бинар оппозициясен оештыра. Автор текст эчендә геройларны мәңге яшәү сере белән таныштыра, образның сакраль үзәк белән янәшә килүе шулай аңлашыла (сөйгән ярлар “бигрәк тә Чулпан йолдыз аша тиз “аңлашалар”). Кала-тау дип бирелгән сакраль үзәк тирәсендә нәсел-ыруны җыеп тору мәгънәсен аңлатып килгән йола белән бәйле мифопоэтик укылышлы текст урнаштырыла: “Сарманай авылы яшьләре иртә яздан башлап көз ахырына кадәр инеш буендагы Сабантуй яланына кичке уенга чыгалар. Элегрәк мондый уеннар һәр татар авылында булган. Ә менә сарманайлылар бу матур йоланы бүген дә онытмаганнар”. Текстта Сарманай авылы, Кала-тау – үткән белән бүгенге вакыт сызыгын берләштерүче сакраль үзәк буларак төгәлләшә.

Пространствоның динамик агышын әкренәйтү өчен әсәр тукымасына махсус локус-киртәләр кертелә, ягъни сюжет элементлары, символик образлар ярдәмендә эпик ретардацияләнә. Ретроспекция алымы белән сөйләнгән кичерешләрдә әрнү-сызланулар сызыгын башлап җибәрү өчен автор “таныш зәңгәр капка” детален кертеп җибәрә: “Төн пәрдәсен ертып бара торгач (бүген

йолдызлар да аз, ә менә Чулпан үз урынында, тик бераз моңсурак кына), Зәлифәләрнең капка төбенә килеп җиттеләр. Әмма, алдан ук сүз куешкан шикелле, алар бу таныш зәңгәр капканы узып киттеләр. Сәүбәннәр турысында да сүз катучы булмады, ниндидер бер яшерен көч, тылсым-гипноз бу ике яшь йөрәкне алга — хәтәр билгесезлеккә әйдәп алып китте...” Хәтәр билгесезлек – Сәүбән язмышында сынаулар башлана торган вакыт һәм урын аталышы.

Пространствоны үзгәртү ярдәмендә (Сәүбән “Казандагы Хәйдәр абыйсы янына барып сыенды”) текстта космос / хаос оппозициясе оештырыла. Сәүбәннең кайту юлын төгәл бирү өчен чиктә торган пространство детальләре – түр басу очы, ике дөнья чиген белдереп килгән басу капкасы, озын эскәмия) тәкъдим ителә: “Түр басу очында авыл капкасы күренде. “Басу капкасы” дип тә йөртәләр аны. Һаман да шул икән. Җил-яңгырдан караеп беткән ике имән багана. Алар өстенә шундый ук имән киртә сузылган. Янәшәдә генә ялгыз тупыл агачы. Сәүбән чыгып киткәндә беләк калынлыгында калган бу агач хәзер әнә колачка сыярлык булып үскән. Шунда ук озын эскәмия. Элегрәк армиягә алынган егетләр, шушы эскәмиягә тезелешеп утырып, соңгы мәртәбә тәмәке көйрәтәләр, авыл белән хушлашалар иде”. Мифопоэтик образ – балачак рухы пространство бирелешен профан / сакраль оппозициясе яссылыгында уку кирәклеген ассызыклый: “... кемдер бар анда, әнә бер малай утыра. Авыл малае. Ак күлмәктән, киң сатин ыштан-чалбардан, җирән-коңгырт чәчләре ерактан ук тырпаеп, балкып тора”.

Пространство бирелешендә түр басу очы һәм Кала-тау түбәсе, очы детальләре янәшә урнаштырыла: “Иң кызыгы һәм гаҗәбе Кала-тауның түбәсе, очы булгандыр. Дөресрәге, бу тауның түбәсе бөтенләй дә юк иде. Ниндидер могҗиза белән аның очын кисеп алып, өстен тигезләп, “сыпырып” куйганнар диярсең… Җитмәсә, Кала-тауның әнә шул өске ягына тигез, шома таш түшәлгән”. Вакыйгалар үзәгенә салынган хәтер мотивы үткәнне бүгенге белән тоташтыра, димәк, кайту юлында урынны оч дип кабатлау сакраль үзәккә юлның башын билгеләп кую өчен кирәк.

Үр тыкрыгы – пространство бирелешендә профан /сакраль чигендә тора торган әдәби детальләрне дәвам итә. Яшәеш кануны Май әби тарафыннан шул урында әйттерелә: “Туган җиргә кайткач, һәр туксан яшьлек карттан алып тугыз яшьлек балага кадәр танырлык итеп яшәргә кирәк, балам”.

Сәүбәннең кайту теләге бар, карары нык: “Шул элеккеге сукмагы буенча барды ул. Кояш баерга ике-өч сәгать бар иде әле, авыл читендәге кыр-яланнар, үр-чоңгыллар әллә каян күренеп тора... Инеш буйлап бераз баргач, сөзәк тау менәсе бар”.

Ләкин чиктә торган урын детальләре төп геройның Җирдә яшәгән вакытта сакраль үзәккә юлны югалтуын әйтеп бирәләр: “Сәүбән унсигез елдан соң беренче тапкыр җил-яңгырда төсен югалткан, инде какшап-имгәнеп беткән урам капкаларын ачып керде; аны нык кына таушалган, имгәнеп, ян-якка авыша башлаган иске йорт каршы алды. Бу караңгы, шыксыз дөньяда бердәнбер олы куаныч — ишектән үрелеп карап торучы әнкәсенең көләч йөзе иде”. Биредә иске йорт дип тәкъдим  ителгән пространство урам башындагы иясез арба детале белән ныгытыла һәм Сәүбәннең рухи халәтен атау вазифасын башкара: “Иң элек ул урам башындагы иясез ватык арбага игътибар итте. Аның бер тәгәрмәчен кемдер салдырып алып киткән. Алдагы тәртәләре дә юкка чыккан. Гарипләнеп бер якка янтайган бу арбада Сәүбән үзен таныгандай итте”.

Яшәеш чыганагы – чишмә образы бирелеше дә гомумиләштереп бәяләү вазифасын үти: “Рух чишмәсенең челтерәвек агышын Сәүбән ерактан ук ишетеп, килә-килешкә аптырап калды. Чишмә тирә-ягындагы сазлык киңәйгән, инеш, киресенчә, тарайган, янындагы таллык сирәкләнгән, аның тирәсендәге чирәмлек пычранган. Агышы шул ук, ярсып-ярсып, тулгак тоткан кебек ага. Улагы да шул, әмма шактый тузган, кителеп, яньчелеп беткән”.

Төп герой кичерешләрендә кискен үзгәрү нәкъ менә чишмә символы аша сурәтләнә: “Сәүбән йөгереп килеп чишмә алдына тезләнде, улактан агып төшкән суга учларын куйды. Аннары шул учларындагы суны үзенең битенә, чәчләренә сирпеде. Нindидер сихергә эләккән кебек, беравык телсез калып, таш сындай катып торды ул. Аның тәне буйлап ниндидер рәхәт дулкын

йөгерде. Бу дулкын берочтан Сәүбәннең җанын, бәгырен дә тылсымга төреп, сафлап, иркәләп узгандай булды… Ул шушы мизгел өчен генә булса да авылга кайтырга тиеш иде. Сәүбән моны хәзер ап-ачык төшенде”.

Мифопоэтик структураны нигез итеп алган әдәби текстта образ-детальләр, пространство бирелеше әзер калыпны таләп итә. Ак бабай, Ак әби, Май әби һ.б. образларын архетипик схемага салу очраклы түгел: “Нигъмәт карт — түбән оч белән астурамның Ак бабае. Әйе, авылларда Ак бабай, Ак әби дигән могтәбәр затлар яши әле. Алар мулла да, авыл советы да түгел. Алар — шушы төбәкнең рухи җитәкчеләре, йоланы, милли рухны, әдәпне, тарихны саклаучылар. Мондый картларны беркем дә сайлап куймый, алар бу вазифага гомер буе эшләгән изгелекләре, матур гамәлләре аркасында ирешәләр”.

Сәүбән хәзер тойган рухи бушлык халәте пространство бирелеше аша үткән / бүгенгене каршы куеп гомумиләштерелә: “Сәүбән карап-күзәтеп барды: авыл шактый үзгәргән. Таш йортлар күбәйгән. Аерым хуҗалык йортлары матурайган, әмма авыл үзе бетәшкән — урамнары чүп-чар белән тулган, елга-инеш буйларына тирес өйгәннәр. Үзгәртеп кору җилләредер инде: фермадагы элекке төзек, агарып-балкып торган биналар бушап калган, аларның тәрәзәләре ватылып, ишекләре каерылып беткән. Аның каравы авылда ике мәчет манарасы калыккан. “Мәчетләр салып кую гына иманлылык билгесе булса, эшләр бер дә әйбәт түгел”,— дип уйлап алды ул. Бөтен хуҗалык җимерелеп, элекке колхоз милке таралып-тузып ятканда, яисә инеш буйлары чүп-чар өеме белән күмелгәндә, нинди иманлылык, рухи яңару, чистарыну хакында сүз алып барырга мөмкиндер…”

Көзгеле композициядә үткән / бүгенге / киләчәк оппозициясе юкка чыга, ягъни “күктән төшерелгән кешеләр өйгән” тау ишелү – игелек белән явызлык бергә яшәгән Җирдә сакраль үзәккә – кешенең үз асылына кайту мөмкинлеге бервакытта да булмаячакны күрсәтә.

Билгеле булганча, нокталы һәм линеар пространство модельләрендә киләчәккә юнәлгән, үсештәге туры сызык рәвешендә сурәтләнгән пространство герой очрый торган нокта-киртәләр ярдәмендә ретардацияләнә (әкренәйтелә).

Киртә үтелү белән пространство агышы яңадан үз тизлеген ала. Дөнья сурәтендә үзенчәлекле нокта-локус – “дөнья чиге” - герой юлының ахыры булган серле-сихри дөнья образы урын ала. Төп герой магик топоска житүгә пространство агышы янәдән статик хәлгә күчә,  герой максатына ирешүгә пространство күчәре кире юнәлештә хәрәкәт итә башлый.

Сәүбәннең кичерешләрен сурәтләү барышында урын образының мәгънәсе төгәлләштерелә. Сакраль үзәккә юл – гармонияле, көйле тормышка омтылыш мифопоэтик нигезле эпик сюжет структурасында “вакыт тукталган мәл”не әзерли (ике Сәүбәннең мәгарәгә керү вакыйгасы кабатлану, әтисе Зәбирнең Кала-тау түбәсенә менүе): “Башта ындыр артлап кына инеш буена төшә, аннары Яман кул чокыры буйлап Кала-тауның текә ягына чыга. Нәкъ шул җирдә, стена кебек шома кыя астында урнашкан да инде “Кала-тау” дигән җанварның ыржаеп торган авызы… Сәүбән бу “җанвар”дан һич курыкмый, киресенчә, аның янында тынычланып калгандай була. Үпкә-рәнҗешләр юкка чыга, нахак сүздән тәмам изаланган, менә-менә очып чыгар төсле тибенеп яткан йөрәге дә, үз эзенә төшеп, салмак кына тибә башлый, күңеле дә үз урынына утыра, карашлары җылынып, йөзе яктырып, нурланып китә. “Җанвар авызы” дигәне тау куышы мәгарә була инде”. Тау каны – яшәеш чыганагы дип аңланган Рух чишмәсенең җәйге бер көнне кан елавы – шул гармонияле көнитештән ераклашкан Җир кешеләрен һәлакәттән кисәтү кебек шәрехләнә ала. Мәгарәгә бәйле дөм караңгы ике бүлмә детале урын образының мәгънәсен киңәйтә.

Ниһаять, Сәүбән белән Сәвиянең мәгарә эчендә калуы – пространствоның статик халәтендә  төп геройның кичерешләре эзгә салына. Сәүбән Сәвияне ярата, улы өчен кайгыра: “Сәүбән үзенең кая барасын белмичә бара. Җирнең, дөньяның үзәгенә, җан җиренә барган кебек бара. Язмышына барган кебек, үлеменә яисә тууына барган кебек, яшәүнең мәгънәсенә ирешәм дип бара. Бу юлда аның югалган улы — бер сәбәп яисә ым-ишарә генә, ә төп максаты бөтенләй башка — үзенең кемлеген, асылын ачыклау… Кеше үзенең кемлеген белмәсә, каян килүен, кая баруын белмәсә, аңа яшәү кыен, бик кыен. Сәүбән дә

үзе хакында бик аз белә, белгәнен дә урау юллардан йөреп, туган туфрагыннан, якыннарыннан, хәтта үз-үзеннән качып йөреп, онытып бетерә язган. Шулай да ул иң кадерле минутларын, иң газиз кешеләрен, күңеленә салып, исән-сау алып чыга алган… Калатау белән бәйле нәсел, күңел серләре, әнкәсе, Сәвиясе, малае, иң мөһиме — бала чагы… Бүген боларның барысы да аның белән, аныкы гына…" "Вакыт тукталган мәл"дә әкренәйтү образлар кабатлануы аша башкарыла (чишмә, таш стена,  коридор, сукмак, карт юкә).

Төп нәтиҗә шул: повестьта профан / сакраль бинар оппозициясе мифопоэтик структураның нигезенә салынып, идея катламында үзенчәлекле чишелеш таба: сакраль үзәкне табу "канат"лылар өчен мөмкин хәл, ләкин Җирдә моңа ирешү мөмкин дә, кирәк тә түгел. Бу – әсәрдәге яшәеш концепциясе.

**Сораулар һәм биремнәр:**

1. Хәзерге татар прозасында  концептуализм: төп сыйфаты.
2. Г.Гыйльманның "Оча торган кешеләр" әсәрендә хронотопны аңлатырга.
3. Повестьта концептуализм билгеләре.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Давлетшина Л. Х. Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI века. Казань: РИЦ "Школа", 2006. – 140 с.

2. Топоров В. Н. Миф. Ритуал. Символ. Образ : Исследования в области мифопоэтического : Избранное. М. : Изд.группа "Прогресс-Культура", 1995. 624 с.

3. Топоров В. Н. Пространство и текст // Текст : семантика и структура. – М. : Наука, 1983. С. 227-284

4. Никитина И. П. Тема художественного пространства в современной философии искусства // Система федеральных образовательных порталов "Социально-гуманитарное и политологическое образование". URL: http://www.humanities.edu.ru/db/msg/46567

## Тема 10. Хәзерге татар прозасында мифологик катламның вазифасы (Н.Гыйматдинова повестьлары).

**Лекция 10**

**Аннотация.** Хәзерге татар прозасында мифологизм турында мәгълүмат бирелә. Н.Гыйматдинованың соңгы елларда язылган повестьлары мисалында мифологик катлам турында сүз алып барыла.

**Ачкыч сүзләр:** мифологизм, мифологик мотив, мифопоэтик структура.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1. “Хатыннар сагышы” әсәрендә сакраль / профан оппозициясе.
2. “Икебезгә дә авыр” әсәрендә сакраль / профан оппозициясе.
3. “Тәкъдир” әсәрендә яшәү/ үлем бинар оппозициясе.
4. Н.Гыйматдинова повестьларында мифопоэтик структура үзенчәлеге.

Үткән XX гасыр сәнгатен мифлаштыру сәнгате дип тә атау гомумбилгеле. Д.Заһидуллина Нәбирә Гыйматдинова повестьларын төрле яссылыкта бәяли, татар әдәбиятында соңгы еллар эчендә модернизм элементларын үзенә туплап язылган әсәрләр арасында әдибәнең повестьларын иҗат агымы, сәнгати алымнарның үзенчәлекле чагылышы җәһәтеннән аерып куя.

Н.Гыйматдинова әсәрләрендә кеше ике яссылыкта: реаль тормышта да, серле-сихри һәм аңлап-танып бетереп булмый торган дөньяда да яши”,– ди Д.Заһидуллина. “Автор дөньяның кешеләр күреп-белеп бетермәгән өлешен – табигать белән бәйләнешен, кешенең аннан башка тулы канлы тыныч тормыш белән яши алмавын, Җир-анадан аерылганнарның җаннары коруын, шул “корыган”, “сусаган” җаннарны бары тик табигатьнең үз көче белән генә

дәвалап булуын сәнгатьчә матур образлар, мавыктыргыч сюжетлар, борынгы мифологик мотивлар аша ачып бирә алды”,  – ди А.Шәмсутова.

Н.Гыйматдинованың “Хатыннар сагышы” повесте болай башлана: “... Аның үз дөньясы бар иде. Бәләкәй генә, җыйнак кына дөнья... Ае-йолдызы белән... Кар-бураннары, җил-яңгыры белән... Аңа анда җиңел һәм рәхәт иде... Ул бу дөньяда кануннар төзүче патша да, шуларны карусыз үтәүче хезмәтче дә иде”. Әсәрдә дус хатыннар язмышы тасвир ителә.  Ниса Әхмәрова образы эшләнешенә игътибар итик. Язучы ханымның яшәеш фәлсәфәсе “төче ялганга караганда – ачы хакыйкать кыйммәт!”– дигән гап-гади канун: “Ниса теле белән көрәшмәде, эчке халәте белән һәр ялганга, һәр икейөзлелеккә каршы чыкты”. “Эшсезлектән арган журналистлардан”, горур хатын хәзерге җәмгыятьтә кыргый булып тоелган ялган сөймәү гадәте, китап укырга хирыслыгы белән аерылып тора: “Ниса һаман каядыр йөгерә, ул һаман кемгәдер кирәк”. “Җәмгыятьтә борын чөярлек бәләкәй генә статус – ир хатыны” булу бәхете  аңа әлегә тәтемәгән: “табигать мәрхәмәтсез: ул хатын-кызны сайлау мөмкинлегеннән мәхрүм итә, шуңа дөньяда бәхетсез хатыннар, сагышлы хатыннар күбәя”.

Бай ир хатыны Сандугач исә дустының кемгәдер кирәк булуына кызыгып карый, чөнки аның “өч кешелек гаиләсендә һәркемнең үз урыны”. Сандугач авылын, үткәнен, бәхетсез мәхәббәтен сагынып сызлана, ире Бәдри Саматовичны хезмәтче Рокыя апаның гомер буе яратып яшәвен ул бик очраклы гына белеп ала...   Икътисад бүлеге җитәкчесе Шакирә исә улын Самат Азаматовичның “акчаларына” өйләндерү хыялы белән яши. Улы “ничек инде ул, ирегеңне сат та, коллыкка төш,” – дигән фикердә тора, башка юл сайлый.

“Көн саен таң ата да, көн саен кояш бата торган” шушы кырыс чынбарлыктан качып, “караңгы белән яктылык арасында бәргәләнүче җанына урын эзләгән” кичәге түрә Бәхтияр Сәфәров белән горур язучы Нисаның урманда очрашуын күзәтик: “Хатын яланаяк иде. Сукмакны сарган кырмыскаларны сытмас өчен табанын ылыс инәсенә кадата-кадата кырыйдан атлады ул. Адәм ышанмаслык хәл! Казандагы офисның урам яктагы баскычына

кадәр сакчылар куйдырткан иң зәһәр түрә япа-ялгызы киселгән имән төбендә утыра, язучы аңа сөт белән ипи китерә... Арган... Карашы кайсыдыр агач яфрагында...”

Әсәрләрдә субъектив фикер катламын сакраль / профан оппозициясе оештыра. Өч хатынның язмышын хикәяләүче субъектив герой автор тавышын ишеттерүче буларак кабул ителә, аңлана: “Адәм баласына тынгы юк: ул гомере буе көйсез җанын көйләп яши. Яраларымны тизрәк дәвалыйм, хаталарымны тизрәк төзәтим дип өметләнә. Ә җан, үчеккәндәй, мәшәкать арты мәшәкать өстәп тора. Чөнки ул фани дөньяныкы түгел. Аны шушы ыгы-зыгылы һәм гөнаһлы Җиргә вакытлыча гына очыртып җибәргәннәр һәм җан, бу тарлыктан, бу кысанлыктан туеп, һаман каядыр билгесезлеккә ашкына”.

Табигать күренешләренең сурәте дә сакраль / профан оппозициясенә буйсындырыла. Мисалга “Икебезгә дә авыр” повестенда сюжетка керергә әзерләүче пейзаж элементына игътибар итик: “Бу төн бик караңгы иде... Әйтерсең җиһан, күктә йолдызларын кабызырга онытып, йокларга яткан. Айдан саран гына яктылык сирпелсә дә, күңел сөенер иде. Кайчагында төн кояшы бер иптәш кебек була. Тик төпсез “Тоба”ны анысы да яктырып та кинәндерми шул: яңгырлы төннәрдә дөньяга чыраен сытып, болытлар арасына чума”. Урман, бүреләр – мифологик мотивларны барлыкка китерүче символлар. Төркиләрдә изге саналган бүреләр – “җан саклар өчен Тобага төшеп утырган”, ярты гомерен чокырда уздырган Зәмзәмиянең дуслары: “Угрыларны йодрыгын селки-селки орышты ул. Бүреләр ырылдамады, гаепләрен таныган сыман, койрыкларын кысып, куак эченә шылды”. Үзен мәңгегә ялгыз иткән “бәндәләр буйсынган законнар белән, бәндәләр үтәгән гадәтләрне үтәргә ярамаган чокыр”да көн күрүче хатын сыкрана, зар елый: “Аның “өстәгеләр” белән уртаклыгы калмаган”. Повестьта герой әнә шулай серле, могҗизалы чынбарлыкта сурәтләнә, төгәлрәге, кеше күзеннән читтә торган, шом тудырган гап-гади чокырга сакраль мәгънә салына. Әтисе Хәбир күрсәткән башка чынбарлык кызын да кешеләр җәмгыятендә хөкем сөрүче явызлык, гаделсезлектән коткара, аның киләчәк язмышын билгели. “Чәчләре арыш

саламы төсендәге кызны көтеп картайган" Вәгыйзьне дә үзгә чынбарлыкның бер вәкиле итеп күрәбез.

Н.Гыйматдинова сакраль / профан оппозициясе алга чыккан әсәрләрендә лейтмотив булып дөньяны хис аша танып-белү, мәхәббәт ярдәмендә хакыйкатькә якынаю турындагы фикер тора.

Н.Гыйматдинованың "Бер тамчы ярату" повестенда диниятсез, имансыз халыкның яшәеше абсурд чигендә тасвирлана. Мондый халәттә авыл гомерен – татар яшәешен саклап калу хакында гына кайгырту дөрес. Габдерәхим дип авылга кайткан, сөйгәнен күрү бәхетенә ирешкән Рабига шул хакка мәхәббәтен корбан итә, әнисенең алкаларын - әрнү катыш бәхетен ирнең хатыны – рус кызына бүләк итеп калдыра. Автор карашы: "Көмеш Ярда тормыш уты алар мәңгелеккә күчкәч тә сүнмәскә тиеш. Димәк, авыл гомерен яшь хатынның карынындагы бала гына озайтачак".

Тормыш – уен, үлем аңа чик куя. Гомернең чиклелеге турындагы фәлсәфә әдибәнең "Тамыр" әсәрендә мәхәббәт фәлсәфәсенә бәйле тәкъдим ителә. Берсен-берсе сөйгән ярлар – тамырлары уртак парлар бу яшәештә кавыша алырмы, әмма шунысы хак: "бәндә туганнан бирле юлда. Туфрактан яралган, туфракка кайта. Ә туфрак бөтен җирдә дә туфрак! Төсе генә бүтән".

Әдибәнең "Мәхәббәттә гөнаһ бар", "Күкчәчәк", "Парлы ялгыз" әсәрләрендә җир тормышындагы әрнү-сагышлы сөю романтик, драмтик пафос белән тасвирлана. Укучы Бакир-Вәсилә, Күкчәчәк-Мирсәлим язмышлары өчен сызлана, аларның җаннары үрсәләнгәндә тыела алмый елый да.

"Тәкъдир" әсәре яшәү/ үлем бинар оппозициясен үзәккә ала. Утыз биш яшьлек талантлы артистка "әкрен генә үлеп баручы" Нәзирәнең җан халәте ул уйнаган образ – сөйгәненең Әфганстанда үлгәнлеге хакында ишеткән Нуриянеке белән тәңгәл: "Мин исә сәхнә уртасына тезләндем дә сулыгып-сулыгып еларга тотындым. Бәгыремнән актарылган авазлар, һәр хәрәкәтемне күзәткән залны тетрәндереп, бер мәлгә сулышсыз итте. Андый мизгелләр сирәк туа, бит монда ике хатынның фаҗигасе бергә кушылган иде". Ире хыянәтен кичергән Нәзирәгә язмыш мәрхәмәтле кебек, хатын, үзен җуйган хәлдә,

Саматны очрата, яшәү серен ача, ләкин “тәкъдирдә язылган роль катлаулырак” булып чыга. Нәзирә сөеклесе белән кавышканнан соң яңа, тагын да авыррак сынау кичерә. Хатынга Чечня сугышында башын салган Саматның улы нәни Саматны тәрбияләргә, тәүге мәхәббәте Илһамның таянычын тоеп яшәргә язган икән. Автор тавышы: “Бер уйласаң, тормыш үзе дә сәхнә, тик аерма шунда гына: син анда үзеңне уйныйсың”.

Н.Гыйматдинова әсәрләрендә өметләрнең өзелүен, рухи бушлыкны кичерү кешене яңа сынау – яшәүне, матурлыкны юкка чыгаручы үлемне кабул итәргә әзерли, дигән мотив алга чыгарыла. “Ачкыч” әсәрендә шул ук фәлсәфә дәвам иттерелә. Хикәяләүче сөйләме буларак тәкъдим ителгән автор тавышы: “...бәндәнең күкрәге бик-бик тар итеп яратылган. Тәкъдир бизмәнендә һәркемгә үз өлеше генә үлчәп бирелә. Шуңа канәгать бул, шуңа шөкрана кыл, димәк”. Авыл мулласы Йосыфның кан туганы Шакир авылдагы изге урынны ата-баба ядкаре Әүлия тавын бозып, йорт салдыра, таудагы суырлар адәм ыңгырашуы белән җылый. Озак та үтми, Шакир, җыйган барлык мөлкәтен комарлы уенда оттырып, йөрәк белән егыла, үлә.

Шакирны соңгы юлга озатырга килгән Илсөяр язмыш борылышы алдында: “Илсөяр артистмы, әллә тамашычымы? Тамашачы икән, кәмитчелектән туеп, залдан чык. Әгәр артист икән, аның уенны өзәргә хакы юк, ул, җебен җепкә ялгап, ахырга кадәр үз ролен башкарырга тиеш”. Автор хикәяләүче теле белән фәлсәфи проблеманы иҗтимагый мотивлаштыра, күз алдына “иман йортларының саны артып, бәндәдән иман югала башлаган замана” – XX гасырның 90 еллары килеп баса: “Илдәге үзгәрешләрдән явызланган нужа бабайның табиб, укытучы, галимә хатын-кызларны, дыңгычлап, сыйфатсыз чүпрәк-чапрак төялгән кул арбалары тарттырып, көтүләре белән урам базарларына куган көннәре иде. Дөньяда яңа төрдәге сәүдә туып маташа иде: монда әлегә берәүнең дә сату-алу тәҗрибәсе юк, монда һәммәсе дә тигез: алдашырга-алданырга, тәмәке тартырга, пыяла чәркәләрне чәкәштереп аракы эчәргә дә барысы бергә өйрәнәчәк, соңрак кына, иләктә иләнгәч, кемдер батачак, кемдер яначак, ә кемдер акчага коеначак иде”.

Илсөярнең дусты Дамирә теле белән бу хакыйкать даими кабатлана, ул кызын ялагайлану, директорга төчеләнү, ясалма елмаю, ясалма көлү, гайбәт ташу талантына өйрәтергә тырышып карый. Әмма “иҗат колы” Илсөяр ни йорты, ни гаиләсе, ни акчасы булмаган мескен булып яши. Шакир белән танышу “халыкны җырлары белән елаткан” кызны үзгәртә, ир йорт ачкычын артистка Илсөяргә васыять итә. Ләкин Илсөяр йортны инде саттым, инсафлы, тыйнак Йосыфны үземнеке иттем дигәндә, Дамирә бу изге тауны бозып, халыкны рәнҗетеп салынган йортны алудан чиркануын әйтә... Автор тавышы: “Табигатьне адәм заты гына пычрата бит. Кулы белән дә, уе белән дә”.
Милләте, газиз халкы өчен янып-көйгән Нәбирә Гыйматдинова әхлаксызлыкны, диниятсезлекне каракош дип тамгалый, ак торналарның – күңелдәге изгелекнең юкка чыгуына, “уңган халкының кырылганлыгына” сызлана, Минсаралар тавышы болынны кисеп үтә: “Татар – үз-үзен санламаган халык! Һәркайсы үзенчә бәхетле һәм бәхетсез дә”.

“Нәбирә – бәхетле язучы, татар әдипләре арасында бүген ул иң күп укыла торганы, – дип яза Ркаил Зәйдулла. Бу чыннан да шулай: аның җыентыклары китап киштәләреннән тиз арада таралып бетә. Югарыда исеме аталган әсәрдән өзек: “Халык язучыны дәрәҗәсенә бүлми, кемне яратып укый, шуның тирәсендә бөтерелә”. Аның геройлары нечкә күңелле, сизгер, хис-кичерешләргә бай, якты сагышлы, матурлыкны бәяли алыр дәрәҗәдә тәрбияле, олы мәхәббәтләрен гомер буе йөрәк түрендә саклап йөртүчеләр. Аның һәр герое: “Бәхет эше икән ул мәхәббәт”, – дип кабатлый, һәр повестенда “җиденче буын әбиләрдән кан белән күчкән хәтер чылбырының бүгенгесе белән тоташу күренеше” тасвирлана. Әдибәнең һәр әсәре яшәеш концепциясе кебек кабул ителә.

Н.Гыйматдинова повестьларында тәкъдим ителгән чынбарлык сурәте кеше гомере, аның чикләнгәнлеге, язмышның алдан билгеләнгәлеге турында уйланырга, мәхәббәтне төп кыйммәт буларак күтәрергә, милли яшәешебезне яңадан бәяләргә ярдәм итә. Әдибәнең повестьларындагы милли яшәеш

концепциясен бер героеның сүзләрен бераз үзгәртеп, “милләтемнең туфрагы кипмәсен, дисәң, коеңнан су ташып сип”, – дип атап булыр иде.

**Сораулар һәм биремнәр:**

1. Н.Гыйматдинованың “Хатыннар сагышы” ,.“Икебезгә дә авыр” әсәрендә сакраль / профан оппозициясе.

2.“Тәкъдир” әсәрендә яшәү/ үлем бинар оппозициясе бирелеше.

3.Н.Гыйматдинова повестьларында мифопоэтик структура үзенчәлеге нидән гыйбарәт?

4. Н.Гыйматдинованың башлангыч чор иҗаты белән хәзерге иҗатында мифологизм бирелеше ягыннан аерма.

**Әдәбият исемлеге**:

1. Давлетшина Л.Х. Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI в.в. – Казань: РИЦ «Школа», 2006. – 140 с.

2. Заһидуллина Д.Ф. Мирасыбыз – олы мөлкәт / Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. Б.233-245.

## Тема 11. XXI йөз башы татар прозасында реалистик роман жанры. (З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романында экзистенциаль мотив)

**Лекция 11**

**Аннотация.** Хәзерге татар прозасында роман жанры үсеше турында мәгълүмат бирелә. З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романында экзистенциаль мотив, концептуализм билгеләре аңлатыла.

**Ачкыч сүзләр:** концептуализм, экзистенциаль мотив, совет коллаборационизмы.

**Теманы өйрәнүгә методик киңәшләр.** Лекциядә темага кагылышлы төп фәнни-теоретик мәгълүмат бирелә. Шуннан соң мөстәкыйль эш буларак бирелгән сорауларга телдән җавап бирергә әзерләнү сорала. Теманың

үзләштерелү дәрәҗәсен билгеләү максатында һәр лекциядән соң сораулар һәм бирелгән тәкъдим ителә.

**Лекциянең планы**:

1.З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романы: төп сюжет сызыгы, төп геройлар бирелеше.

2. Романда тарихи вакыйга бирелеше.

3. Романда экзистенциаль мотив.

4. Романда концептуализм билгеләре.

1990 елларга, совет хөкүмәте таркалуга бәйле, социалистик системаны тоталитар режим буларак бәяләгән, советчыл мифны җимерергә омтылып язылган әсәрләр З.Хәким прозасы аша аваз салды.

З.Хәким прозасының ике – фәлсәфи һәм сатирик канаты, асылда, ике төрле әдәби фикерләү нәтиҗәсе.

XX йөз ахыры татар әдәбиятындагы яңарышны тудыручыларның берсе прозаик, драматург, шагыйрь, җырчы З.Хәким яңа гасырның беренче унъеллыгында татар прозасына Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган роман тәкъдим итте. Икенче Бөтендөнья сугышы елларында Өченче рейхның төрки-мөселман халыкларыннан булган аерым вәкилләр белән сәяси һәм сугышчан хезмәттәшлек урнаштыру омтылышы галим И.А.Гыйләҗев тарафыннан тарих фәнендә башлап һәм тирәнтен өйрәнелгән өлкә. Фәнни хезмәт басылып чыкканнан соң бер дистә ел үтүгә әлеге тема язучы Зөлфәт Хәкимнең “Легионер” дип исемләнгән драма һәм романында әдәби укылыш тапты. “Легионер” романында (2009) тарихи материал татар кешесен үз асылына кайтырга чакыру мотивы белән бер үремтәдә бирелә.

Роман “мәңгелек сагыш турындагы моң-җыр” образын тәкъдим итү белән башланып китә. Хис-кичерешләрнең гомумәһәмиятлелеген белдерүче җыр образы фәлсәфи проблеманы алып керә: “Шәфәкъ халәтенә аваздаш бу җырда гомер чикләренә кадәр сакланырлык хәсрәт белән сүз шатлыгы, моң

куанычы, хис тантанасы бар. Гади генә җыр кебек югыйсә, әмма аның яңгырашы бәгырьләрне чынбарлыктан үзе белән каядыр аулакка алып китеп, җелегеңә үтеп керә. Җыр ишетелми башлагач та, ул тәмамланмагандыр шикелле, бер яңгырагач инде ул дөнья буйлап мәңге агыладыр дип ышанасың". Хикәяләүче укучы игътибарын фәлсәфи мотивлаштырылган шәхси кичерешләр сызыгына юнәлтә: "Кемнеңдер газабы, калкулыкларны уза-уза, әрәмәләр аша, чиксезлекне дәгъвалап җәйрәгән су өстеннән очып, яшәешнең иң очына барып ялганырга тели".

Вакыйгалар бара торган урын бирелеше дә фәлсәфи проблеманы ныгыта: "Еракта, су белән күк тоташкан якта, дөнья тәмамланадыр шикелле. Чөнки бу авылның халкы инде бер "ахырзаманны" кичерде". Суның күк белән тоташуы биредә яшәешнең башланган һәм тәмамланган ноктасы буларак аңлана. Халыкара мифологиядән билгеле булганча, Дөнья суы, Дөнья елгасы – үлеләр биләмәсе белән тереләр иле арасындагы чик. П.Дьель күрсәтүенчә, "ихлас теләкләрнең иң югары дәрәҗәгә җитүен – игелек кылу омтылышын символлаштыручы су образы" романда үтәли образ булып тора. Фәлсәфи проблеманың "су төбендә калган үткәннәре белән киләчәккә алып барырдай куәт" дип куелышы романда экзистенциаль яссылыкны хасил итә: "Тау итәгенә барып сыенган авыл элекке исеме белән Кызылъяр дип аталса да, чын Кызылъярның җанын су йоткан, менә шуны һәрбер кеше белә, аңлый, әмма берни дә эшли алмый". Символик укылышта тау – Галәмнең үзәге, таяну ноктасы, текстта тау итәгенә сыенган җаннар трансцендент халәттә – үз гаепләрен таныган кешеләр илаһига омтыла.

Романда милли яшәеш моделе тергезелә. Автор татар тормышының борынгыдан үзгәрми килгән рәвешен Кызылъяр авылы сурәтенә салып бәяли: "Өч йөз хуҗалыклы Кызылъяр авылы дүрт урамнан һәм шул урамнарның икесеннән тармакланган дүрт тыкрыктан тора". Символик укылышта дүрт саны бөтенлекне, камил ритмны, гаделлек Алласын белдерә [4:469], шул рәвешле автор татар тормышының бөтен, камил көйләнеше турында хәбәр итә. Чишмә тыкрыгы – яшәеш юлы, "көмеш чишмәгә алып баручы юл"–

игелекләр кылу юлы дип тәкъдим ителә: “Һәр урамның үз коесы бар, ләкин эчәргә, аш-суга чишмә суы кирәк”.  Кече җәмгыять моделе кебек тәкъдим ителгән авыл текстта татар җәмгыятенең бирелеше, ә “су буенда төрле тарафтан һәм авылның үзеннән дә күренеп торган бер ачык урын”– ярлыкау сорау урыны яшәү һәм үлем чиген тоташтыручы пространство буларак тәгәлләшә, милли проблема фәлсәфи төсмер ала: “Су баскан тарафка карап һәркем үзенекен уйлыйдыр, күңелендә һәммәсе гаепләне эзлидер, ләкин барысының да фаҗигасе уртак булганлыктан, аерым алганда, беркем беркемгә күңелендә үпкә-шелтә сакламый, чөнки гаеп һәркемдә бар”. “Яңа” Кызылъяр авылы – буыннардан килгән рухи мирасны югалтудан туган сагышлы, хәсрәт тулы урын дип алдан искәртелә, “экзистенциаль сайлау” үткән тирәлек сурәте сюжет сызыгының чишелешен әйтеп бирә: “Афәттән качарга теләп үрмәләгәндәй, “яңа” авыл тауның итәгеннән алып өскә, калкулыкка таба салынган”. Шул рәвешле, автор үз асылын югалтып сызланучы татар кешесен гомумиләштерә, аның яшәеше газап-хәсрәтләрдән тора дигән фикер әсәрнең нигезенә салына, романның шәхси һәм иҗтимагый сызыкларын тоташтыра.

Романның төп сюжет сызыгында вакыйгалар вакыты тарихи билгеләнеш ала: 1941 елның июнь аенда башланган вакыйгалар 2005 елда тәгәлләнә.

Шәхси сюжет сызыгында билгеләнгән Яббар-Әнсар каршылыгы иҗтимагый сызыкта үзенчәлекле борылыш ала. Фатыйманы бүлә алмаган егетләргә алдан кыз бүлешергә Сәет ярдәм итә, аннары тормыш сөйгән ярларны үзе аралый.

Сәет белән Яббарның әтисе чал чәчле Нәгыйм агай образы әсәрдә тирәлек, татар яшәеше өчен җаваплы булырга тиешле ата образы кебек уйланылган. Герман сугышын йөреп кайткан карт солдатның үзәккә үтеп җан сызлавына әверелгән аяк авыртуы турында кабатлау сюжетка керергә әзерлек вазифасын башкара: “Тән ярасы көн бозылуга була, ә җан сызлавы нинди давылга?”  Текстта Сәет образы исә Нәгыймнең дәвамчысы, гадел, олпат, киңәшче кебек укыла. Яббар теле белән автор Сәетнең әтисен кабатларга тиешлеген гел искәртеп тора. Сюжет сызыгында әсирлектән, Себердән исән-

сау әйләнеп кайткан Яббарны иң беренче булып гаепләгән кешеләрнең алар булуы трагик пафосны көчәйтә, хыянәт проблемасын иҗтимагый яссылыктан гомумкешелек яссылыгына күчерә. Әсәрдә Нәгыймнең Яббарга "нәселгә мәңге юылмаслык тап төште" дигән карашы үзгәрү тарихы сөйләнә.

Иҗтимагый мотивлашкан проблемалар арасында гомумкешелек проблемасы итеп куелганнары шактый. Мәсәлән, авыл җитәкчесе Хәлиулла гаиләсе белән күрше Нәгыймнәр гаиләсе арасында каршылыкның сәбәбе җитәкчелектән курку, кимсенүнең гадәткә әйләнүен автор проблема итеп калкыта, әсәр дәвамында Әнсар-Фатыйма, Сәет-Әнсар, Әнсар-авыл кешеләре һ.б. сызыкларда кабатлый. Автор үз фикерен әсәр тукымасында геройлар монологы итеп урнаштыра. Мисал өчен, авторның совет властеның талауга корылган сәясәтенә мөнәсәбәте Нәгыйм монологында бирелә, аның портреты аша көчәйтелә: "Сәвит влачы кырып-себереп талагач, хәтта хәер сорашсак та бернинди оятын күрмим! – диде Нәгыйм нәфрәт белән. Аның чыгып торган яңак сөякләре агарып китте. Ап-ак чәчле кешенең чырае агару нык тәэсир итә, бер кешенең кыяфәтендә ак төснең күзгә күренеп күбәюе аңлатып булмый торган көчле тәэссоратка ия". Яшь-җилкенчәк егетләрнең сугышып кайтуыннан соң Сәетнең сугыш башлануы турында хәбәр итүе авторның тәэсирлелекне арттырырга омтылышы кебек тә аңлана, сюжет сызыгының борылачагын да күрсәтә. Автор "мактаулы" совет армиясенә, яшәп килүче идеологиягә мөнәсәбәтен Хәлиулла-Нәгыйм диалогына урнаштыра: "Нәгыйм авыл җитәкчесенең чыраена туп-туры карап:

– Без ач-ялангач, – диде. – Теге сугышта да без ачлы-туклы идек. ...

– ...бу сүзләреңне башка кешегә әйтмә, яме. Алып китүләре ихтимал..

– Син бит монда влач. ... Син монда иң куркыныч кеше. ...

– Мин коммунист. Миңа өстән кушалар" .

Сугыш башлаучыларга мөнәсәбәтне дә автор күршеләр диалогы аша белдерә, "нимескә" ләгънәт укыган Хәлиуллага җавабында Нәгыйм: "Хәленнән килсә, барысы да сугыша, күрше" , – ди.

Сюжет сызыгында вакыйгалар Әнсарның Яббар турында ямьсез хәбәр алып кайтуы белән дәвам итә. Биредә Әнсар-Фатыйма, Хәлиулла-Нәгыйм мөнәсәбәтләрендә мәкер, үч алу проблемалары куела. Фатыйманың Нәсимә киңәше белән "акыллы, төпле, зур кеше булырга торган" Әнсарга кияүгә чыгуында буйсыну, курку, ихтыярсызлык проблемалары атала. З.Хәким татар хатын-кызларына хас булган җәмгыятьнең гаделсез яклары белән килешеп яшәүне, яраклашырга омтылып бәхетле булырга теләүне милли яшәешне гарипләндерүче яклар дип бәяли. Сөйгән ярына хыянәт иткән һәм бу адымына аклау эзләгән Фатыйма монологында проблема итеп бирә: "Әгәр якты йөз күрсәтмәсәм яисә читләтеп узарга тырышсам, ачуланма. Ирем көнләшкәнгә генә түгел... Мин авыл халкының ихтыярына буйсынырга мәҗбүр инде. Авыл сиңа ничек караса, мин дә шулай карарга тиеш булам. Татарның гап-гади хатын-кызы мин". Фатыйма һәм Роза образлары аша бирелгән хыянәт проблемасы романда татарның гап-гади кызы аша чишелеш таба. Фатыйманың кызы Сөнбел образы ярдәмендә хатын-кызның яраткан кешесенә карата чын дус та, кайгыртучан хатын да булырга тиешлеге, үткәннәргә ихтирамлы булу аша киләчәкне кайгырту бурычы автор фикере кебек яңгыратыла.

Яббарның әсир төшүе, легонерлык тарихы текстта төп геройның искә төшерүе кебек оештырыла. 15,17 нче бүлектәге тарихи мәгълүматлар И.Гыйләҗев хезмәтеннән күчереп алына һәм укучыга үзгәрешсез тәкъдим ителә. Төп герой язмышына төреп, З.Хәким әсәрдә вакыйгага карата үз мөнәсәбәтен белдереп кенә калмый, авторның бер максаты – әдәбият сөючегә, киң катлам укучыга әсирләрдән төзелгән көнчыгыш легионнар тарихын төгәл фактларга таянып, кыскача сөйләп-аңлатып бирү.

Бөек Ватан сугышы елларында туган ил өчен көрәшеп, үз илләрендә сатлыкҗан дип игълан ителгән гади кешеләрне аклау максатын да куеп, З.Хәким тәнкыйди дискурс практикасының итератив төренә мөрәҗәгать итә, ягъни "вакыйга түгел, җәмгыятьтәге нindидер халәт, хәл турында фикер әйтә, аны беркетеп куярга омтыла": "Без үзебезгә дә, үзебезнең язмышка да,

үзебезнең туган туфрагыбызга да хуҗа түгел! Без туган ил дибез, ә үзебезнең туган җиребезне саклый алмыйбыз. Каһарманнарыбызны да, сатлыкҗаннарыбызны да үзебез билгеләмибез, тегендәгеләргә карап хәл итәбез, алар бизмәнендә үлчәп бәялибез. Без Ватан өчен сугыштык, әмма без үз Ватаныбызның хуҗалары түгел. Безне дә, Ватаныбызны да кемнәрдер үз мәнфәгатьләре өчен файдаланалар. Без зур, бөек төшенчәләр белән сату-алу итәбез, ә бер-беребезнең кадерен белмибез. ... Күпме корбан биреп туган якны яклый алмыйбыз, хәлебездән килми" .

Үз энесен сатлыкҗан дип гаепләгән Сәет һәм Яббарга ике тапкыр хыянәт иткән Әнсар үз йөзләрен югалтып, хакыйкатьне аңлауга килгән татар кешеләре образлары кебек укылалар. З.Хәким буйсынып, ярашып яшәргә күнеккән омтылышсыз татар кешесен гаепләми, тәнкыйди бәя тулысынча иҗтимагый мотивлаша. Авторның максаты – татар укучысын җәмгыятьтәге хәлләрне бәяләргә өйрәтү, уйланырга чакыру, мөнәсәбәт тәрбияләү. Тарихи фактларның күпләп бирелүе (романда Куйбышев ГЭСы турында фактик мәгълүматлар да бар) авторның максатын күздә тоткан очракта үзен аклый. Әнсарның Вәсимгә атап әйткән сүзе авторның яңа буын татар укучысына нәсихәте кебек яңгырый: "Син тарих факультетында укыйсың, тарихчы булачаксың, күп нәрсәне эзләп, казып табачаксың, аңлаячаксың. ... Сез яңа буын, безне вакыты җиткәч аңларсыз".

Романның үзәгенә куелган җәмгыятькә тәнкыйди бәя Яббар монологларына да салына. Нык ихтыярлы, нечкә күңелле, гадел, якты омтылышлы егет авылдашлары, туганнары хыянәте алдында югалып кала, үзенә кул салырга уйлый, ләкин ныклыгын җуймый: "Мин бүтән беркайчан да, беркем алдында да акланмаячакмын! Кешене аңларга теләмәүләре аркасында анда лагерьлар тутырук. Анда тикшерүчеләр нәкъ менә син хәзер миңа ышанмаган шикелле ышанмыйлар. Бәлагә дучар булган миллионлаган кешеләрнең сүзенә колак та салмыйлар, хөкемгә тарталар, таптыйлар, бетерәләр, юк итәләр", – ди ул Әнсарга. Партизаннар отрядына эләккәч, немецны атуы һәм, үзен гаепле сизеп, дошман кешене күмеп куюы, Куйбышев

ГЭСына китеп эшли башлагач, кайтып, Әнсарга авылны су басканчы чара күрергә кирәклеген кисәтүе дә аның кешелеклелеге, кайгыртучанлыгы хакында сөйли. Яббар – буыннар хакыйкатен җиткерүче образ буларак үстерелә. “Авылыңның, бабаңнарның, анаңның каберләрен су астында калдыргач, син, гомумән, кешеме соң”!” – дип Сәеткә әрнүе авторның әхлакый кануннарның нигезен билгеләве кебек аңлана. Яббарның су астында калган әнисе күмелгән зиратка көймәдә юл алуы мифологик укылышлы. Мифларда вафат булган кеше, үләләр дөньясына эләгү өчен, көймәдә суны кичеп чыгарга тиеш булган, дигән ышану бар, шуңа күрә кайбер халыкларда мәетләрне көймәдә җирләү йоласы да яшәп килгән. Көймәдә киткән Яббарның югалуы – яшәү һәм үлем чигенең тоташуы кебек кабул ителә, автор тәкъдим иткән фәлсәфи проблеманың чишелеше кебек тә аңлана. Яббар белән Фатыйманың оныгы Мөнәвир теле белән автор фикере әйтелә: “Ул Яббар атлы кеше батмаган. Агып та китмәгән. Ул бүгенге көнгә кадәр туып-үскән авылын, әнкәсенең каберен, уйнап үскән болын-кырларын эзләп йөри. Кешеләр үз куллары белән ясаган диңгездә – вәхшилек, битарафлык диңгезендә ерак бабалары күмелгән зиратны мәңге эзләп йөриячәк ул”. З.Хәкимнең Яббары татар кешесенең гасырлар дәвамында уелган мәгълүмат-кануннарын, буыннардан килгән ныклы нигезен – гармониягә омтылышын, юлын күзәтеп торырга, бәяләргә тиешле символик укылышлы образ кебек тамгалана. Укучы Яббар образына салынган яшәешнең бөтенлеген саклап торучы беркайчан да югалмаячак әхлакый кануннарны укый. Яббарның оныгы милли яшәеш турындагы хакыйкатьне җиткерүче буларак тәкъдим ителә. Татар кешесе үз асылын югалтмас өчен хәтерен-байлыгын сакларга, илаһига омтылышын – горурлыгын җуймаска тиеш, ди З.Хәким.

**Сораулар һәм биремнәр:**

1.З.Хәкимнең Бөек Ватан сугышы елларында совет коллаборационизмы темасына караган “Легионер” романын сөйләгез (төп сюжет сызыгы, төп геройлар бирелеше).

2. Романда тарихи вакыйга нинди фәнни материалга нигезләнеп бирелә?

3. Романда экзистенциаль мотив.

4. Романда концептуализм билгеләрен (яшәеш концепциясен) аерып күрсәтегез.

**Әдәбият исемлеге:**

1.Гилязов И.А. На другой стороне (Коллаборационисты из поволжско-приуральских татар в годы Второй мировой войны) / И.А.Гилязов.– Казань, 1998.–252 с.

2.Заһидуллина Д.Ф. XX-XXI гасыр чиге татар прозасында тәнкыйди дискурс // Татар әдәбиятын өйрәнү һәм укыту: Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференция материаллары (13 май 2009).– Алабуга: АДПУ, 2009. – Б.84-87.

3. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

4. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1т. (А-Г) / Фатих Урманче.– Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

**Фәнни хезмәтләр, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар һәм информацион чыганаклар**

**а) Төп әдәбият (основная литература):**

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Галиуллин Т. Шигърият баскычлары / Т.Галиуллин. – Казан: Мәгариф, 2002. – 229 б.

Галиуллин Т. Шәхесне гасырлар тудыра / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 192 б.

Галиуллин Т., Йосыпова Н. Басынкы елларның дәртле шигърияте / Т.Н.Галиуллин, Н.М.Йосыпова // Татар шигрияте: 1960-80 нче еллар. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.3-26.

Даутов А. Илдар Юзеев шигъриятендә романтизм / А.Даутов. – Казан: ”ИНТЕЛПРЕСС” нәшр., 2002. – 152 б.

Закирҗанов Ә. Яңарыш юлыннан / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. – 303 б.

Закирҗанов Ә. Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар китап нәшрияты, 2011. – 287б.

Заһидуллина Д., Закирҗанов Ә., Йосыпова Н., Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. Теория. Тарих / Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Н.Йосыпова, Т.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 364 б.

Заһидуллина Д. Яңа дулкында / Д.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.107-123.

Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 1: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

Заһидуллина Д., Йосыпова Н. XXгасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

Йосыпова Н.М. XX гасыр татар шигъриятендә символлар / Н.Йосыпова. – Казан, 2011. – 120 б.

Лейдерман Л., Липовецкий М. Современная русская литература: В 3-х кн. Кн.2: Семидесятые годы (1968-1986): Учебное пособие / Л.Лейдерман, М.Липовецкий. – М.: Эдиториал УРСС, 2001. – 288с.

Литературная энциклопедия терминов и понятий. – М.: НПК «Интелвак», 2001. – С.159-161.

Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т.6: 60-90 еллар әдәбияты. – Казан: “Раннур” нәшр., 2001. - 544 б.

Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская поэзия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.118-123.

Юсупова Н.М., Ибрагимов М.И. Современная татарская драматургия / Н.М.Юсупова, М.И.Ибрагимов // Национальные литературы республик Поволжья (1980-2010 гг.): коллективная монография. – Барнаул: ИГ “Си-пресс”, 2012. – С.124-133.

**б) ярдәмче әдәбият (дополнительная литература):**

Әхмәдуллин А. Күңелләрне уятыр / А.Әхмәдуллин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 223 б.

Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә / А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. – 239б.

Галиуллин Т. Шагыйрьләр һәм шигырьләр / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1985. – 208 б.

Галиуллин Т. Дәвамлылык / Т.Галиуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 168 б.

Галиуллин Т. Безнең заман— үзе җыр / Т.Галиуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.— 208б.

Галиуллин Т. Илһам чишмәләре. Монография / Т.Галиуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.— 365б.

Гамбәр Н. Ике урман арасы / Н.Гамбәр // Казан утлары. – 1997. - №1. – 48-52 б.

Гафиятуллина Н. XX гасыр татар шигъриятӗндә Тукай / Н.Гафиятуллина. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2002. – 152 б.

Есин А. Принципы и приемы анализа литературного произведения / А.Есин. – М.: Флинта, Наука, 1999. – 248 с.

Закирҗанов Ә. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – Б.60-63.

Зөлфәт. Чытырманда былбыл сайрый... // Ике урман арасы. – Казан, 1995. – 7-22 бб.

Ковский В. Литературный процесс 60-70-х годов / В.Ковский. – М.: Искусство, 1983. – 336 с.

Компанеец В. Русская социально-философская проза 1970-80-х годов. Нравственный и психологический аспекты изображения человека / В.Компанеец. – Саратов, 1994. – 228 с.

Латынина А. За открытым шлагбаумом: Литературная ситуация конца 80-х / А.Латынина. – М., 1991. – 160 с.

Мөхәммәдиев Р. Якутлар табыладыр вакыт белән. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Р.Миңнуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. – 216 б.

Нигматуллина Ю. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 1997. – 192 с.

Нигматуллина Ю. “Запоздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 2002. – 176с.

Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес. — Казан: Мәгариф, 2002. — 235 б.

Современная русская советская литература. Литературный процесс 50-60-х годов. – М.: “Просвещение”, 1987. – 218 с.

Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. – М.: ИМЛИ РАН, «Наследие», 2001. – 624с.

Урманче Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь / Ф.Урманче. — Казан: РИЦ “Школа”, 2002. – 260 б.

Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А – Г) / Ф.И.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

Шайтанов И. Поэзия 70-90-х годов. Обзор. Новое в поэзии / И.Шайтанов // Русская литература XX века. – М., 1994. Ч.2. – С.277-303.

Шакирова Г. Драматургия Туфана Миннуллина 80-90-х годов (тематика и проблематика. Жанровая разновидность. Методика изучения в школе): Автореф.дисс.канд.филол.наук. - Казань. - 2000. - 19 с.

Шарипов М. Драматургия Туфана Миннуллина. Проблема героя и его художественное воплощение: Автореферат дисс....канд.филол.наук. - Уфа. - 1989. - 22 с

Шәрәфиев Р. Безне кемнәр аңлар? / Р.Шәрәфиев // Казан утлары.— 2000.— №7.— 139-144б.

Юзиев Н. Шигъърият дөньясы / Н.Юзиев. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. – 312 б.

Юсупова Н. Тылсымлы сүз остасы / Н.Юсупова // Казан утлары. – 2007. - №1. – Б.137-142

Явчуновский Я. Драма на новейшем рубеже. Драматургия 70-80-х годов: конфликты и герои, проблемы поэтики / Я.Явчуновский. – Саратов, 1989.

1. **Информацион чыганаклар, интернет-ресурслар**

(Рекомендуемые информационные ресурсы в Интернете):

- www.wikipedia.ru Универсальная энциклопедия «Википедия»
- www.feb-web.ru Фундаментальная электронная библиотека «Русская литература и фольклор»
- www.ksu.ruЭлектронная библиотека и материалы сайта КФУ
- www.slovari.ru Электронные словари

## Терминологик сүзлекчә

**Авангардизм –** 1910-50 еллар реалистик булмаган әдәбиятындагы бертөркем агымнарның җыелма атамасы.

**Автор** – әдәби иҗатның субъекты, бербөтен әдәби әсәр иҗат итүче.

**Аллегория** – образ төре, конкрет җанлы табигать сурәте аша читләтеп әйтү.

**Архетип** – теләсә нинди әдәби төзелеш нигезендә ятучы, гомумкешелек кыйммәтенә ия фундаменталь башлангыч мотивлар, образларның аталышы.

**Әдәби бәйләнеш** – бер яки бертөркем әдәби күренешнең башка бер яки бертөркем әдәби күренешкә тәэсире, әдәби әсәрләр арасында охшашлану, бәгланыш.

**Жанр** - әдәби әсәрнең тарихи барлыкка килгән, чынбарлыкның эстетик концепциясен белдерүче төре.

**Интертекстуальлек** – текстның чит цитаталардан һәм реминисценцияләрдән төзелүе – терминын француз филологы һәм постструктуралистик юнәлеш теоретигы Ю.Кристева кертә.

**Иҗат юнәлеше** – әдәби барышта формалаша торган иҗат бердәмлеге, үзенчәлекле идея-эстетик принципларга таянып, тормыш-чынбарлыкны рухи-гамәли танып-белү, аңлату һәм сурәтләү.

**Иҗат агымы** – билгеле бер тарихи чорда яшәгән бертөркем язучылар иҗатындагы фәлсәфи фикер яки иҗтимагый позиция, әдәби-эстетик караш һәм стиль охшашлыгыннан туган берәмлек.

**Лирик герой –** лирикада автор образы, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ.

**Мотив**- әсәрдәге тотрыклы эчтәлек–форма компоненты.

**Миф** – дөньяның килеп чыгышы, кешенең барлыкка килүе, аллалар һәм патшаларның, каһарманнарның батырлыгы хакында бик борынгы сөйләүләр. Ул – борынгы кешенең тормышны һәм үз-үзен күзаллавы, гаять әһәмиятле, ләкин аңлаешсыз, серле тоелган табигый, физиологик, иҗтимагый күренешләрне шәрехләве.

**Символ** – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория, тулысынча шартлы образ.

**Текстлар очрашуы** – бер әсәр эчендә төрле әзерлектәге укучыларга адресланган, һәрберсе мөстәкыйль тарих булып укылырлык берничә текстны бергә кушарга, урнаштырырга мөкинлек бирә һәм әсәрне төрлечә шәрехләргә юл калдыра торган постмодернизм поэтикасына хас күренеш.